# ШУРА

№50
2025




## «И Раббым! Гыйлememне арттыр»

«Та Һа» сүрәсе / 114 аять

# ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Дини гыйлем алуның әһәмияте . . . . . . . . . . . 14
Тормышыңны бозма . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Үлем — иң олуг нәсыйхәт . . . . . . . . . . . . . . 24
Сабыр итү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Хәләл ризык белән туклан . . . . . . . . . . . . . 41
Үзеңне алдарга ирек бирмә . . . . . . . . . . . . . 45
Сәламәтлек — Аллаһыдан әманәт . . . . . . . . . 50
Әниләребезгә итагать итик . . . . . . . . . . . . . 55
Аллаһының мәхлуклары турында уйлану . . . . . . 60
Никахка әзерләнүнең әһәмияте . . . . . . . . . . . 67
Коръәндә сөйләнгән пәйгамбәрләр тарихының хикмәте нәрсәдә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Гөнаһларның башы — хәмер . . . . . . . . . . . . . 78
Яңа ел — хисап вакыты . . . . . . . . . . . . . . . 83

НӘСЫЙХӘТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Ата-ананың хаклары һәм аларны үтәү әдәпләре . . . 88
Истигъфар кылуның әдәпләре . . . . . . . . . . . . 91
Йорт салуга караган әдәпләр . . . . . . . . . . . . 94
Күрше хакы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Тәмугның баскычлары . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Җәннәтнең дәрәҗәләре . . . . . . . . . . . . . . . 103

НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН? . . . . . . . . . . . . . . 111
ИЮНЬ-СЕНТЯБРЬ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Хамматов Л. Г.

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Хәмидуллин Р. Ә.
Мөбарәков Б. Р.
Фәизов И. Ә.

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Маннанова Р. Р.

**ДИЗАЙНЕР:**
Хәйретдинов И. Р.

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гарифуллин И. Ф.

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
shutterstock.com/ru/g/3dkeremA.

**«ШУРА» дини альманах, № 50** **12+**

сентябрь–декабрь 2025
рабигыль-ахыр–раҗәб 1447

Альманах Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 номеры белән теркәлде.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел.: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Химград территориясы, 201 нче йорт, 1006 нчы бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 17.09.2025
Чыгу көне: 03.10.2025


*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*


**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهٰذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلٰهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ۞ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ۞ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

________________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ
تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞
أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞
اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ
الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّه حَمْدَ الْكَامِلِيَنَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِيَن وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ
وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ
عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:
إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞
اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ
إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا
بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَاهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وَهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдииййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү’миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әнсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйндәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẓәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхӟүл мән хәӟәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә'мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ӟил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәӟәккәрүүн. Вәләӟикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

[2] Өч тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ______________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуүҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*10 октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Дини гыйлем алуның әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһым, ошбу җомга вәгазен хәерле вә файдалы кыл, сөйләүчегә — тел ачкычлары, тыңлаучыларга зиһен ачкычлары биреп, динебезне дөрес аңларга вә дөрес аңлатырга насыйп әйлә һәм ярдәм ит, йә Раббым!

Җәмәгать, мин иртәгә, медицина университетында, аннан ординатурада укымыйча, ак халат киеп кенә, табиб булдым дисәм, кайсыгыз миңа дәваланырга килә? Яки очучы (пилот) фуражкасын киеп, өйрәнмичә генә, иртәгә Төркиягә ярты бәясенә генә алып барам дисәм, кайсыгыз утырып китә минем белән очкычта? Ә без, җәмәгать, түбәтәй киябез дә, мөселман булдым диябез. Табиб булыр өчен ак халат кию җитмәгән кебек, динебезне өйрәнмичә, түбәтәй киеп кенә, сакал үстереп кенә мөселман була алмый адәм баласы.

Җәмәгать, Аллаһының Илчесе сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм безне кисәтеп әйтә: «Гыйлем алу һәрбер мөселман вә мөслимәгә фарыз!» — ди[1]. Фарыз дип әйтә, кардәшләр. Гыйлем алу, галимнәрдән, хәзрәтләрдән гыйлемне таләп итеп алу фарыз ди! Кайсыбыз бүген үти бу фарызны? Кайсыбыз остаз-укытучылар артыннан «өйрәт мине» дип сорап йөри? Ә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм моны фарыз ди! Җәмәгать, кайсыбыз үзе теләп бара дини белем алырга?

Хөрмәтле кардәшләрем, һәрберебез хәзер үзенә эчтән генә сорау бирсен: «Мин динемне, Ислам динен, беләмме»? Һәм шулай ук эчтән генә

[1] Имам Ибне Мәҗә.

үзегезгә җавап бирегез. Бирдегезме? Яхшы, тикшереп карыйк. Аллаһы Тәгалә кем Ул һәм нинди сыйфатларга ия? 99 исем-сыйфатын искә алып атап чыга алабызмы? Ким дигәндә боларны белмәсәк, без динебезне беләбез дип әйтергә нинди хакыбыз бар? Аллаһыбызны таныйбыз дип әйтергә? Ярый, алга таба: намазның ничә фарызы, вәҗибе бар, ниндиләр? Ислам нәрсә ул? Иман, ихлас нәрсә? Шартлары нинди?

Җәмәгать, кардәшләрем, ә боларны белү безгә фарыз бит! Мөселман кешесенә белемне бишектән алып ләхеткә тикле алу, эзләү, өйрәнү фарыз! «Бишектән ләхеткәчә гыйлем таләп итегез!» — динебез, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, галимнәребез моңа өнди.

Ә без бүген нинди мөселманнар? Вакытыбызны нәрсәгә сарыф итәбез? Мөселман булу бик зур бәхет булу белән, бик зур җаваплылык та. Безгә карап, безнең нинди әхлак, белем дәрәҗәсенә ия булуыбызны күзәтеп, Исламда булмаган кешеләр динебезне бәяли. Алар безнең сүзләребезгә түгел, безнең гамәлләребезгә, үзебезне тотышыбызга, абруебызга игътибар итә!

Сәхабәләрнең радыяллаһу ганһүм феноменына, могҗизасына күз салыйк, җәмәгать. Кабатланмас дәрәҗәдәге нык иман, ихласлылык, тәкъвалыкның сере, сәбәбе нидә? Алар дингә өндәсәләр, халык авыллары, шәһәрләре, дәүләтләре белән Ислам динен кабул итә торган булган. Нигә? Ислам дине 610 елда тарала башлый һәм 300 елда Җир шарының яртысын диярлек яулап ала. Ничек? Боларның барчасының да сәбәбе бер — ул гыйлем! Сәхабәләрнең бик гыйлемле булуы, диннәрен, шәригатьне яхшы белүе нәтиҗәсе. Нигезле вә төпле, төгәл гыйлем ихласлылык вә тәкъвалык башлангычы, этәргече булып тора да! Исламны алга сөрүче, үстерүче көч — ул кылыч та түгел, җәмәгать, мылтык та түгел, ә гыйлем! Һәм бүген Исламның үсүе вә таралуы өммәтебезнең гыйлем дәрәҗәсе белән турыдан-туры бәйле; аны үзебездә булдыру һәм камилләштерү, башкаларга тапшыру Аллаһы юлындагы безнең көндәлек вазифабыз, бурычыбыз булып тора, газиз дин кардәшләрем.

Ничек уйлысыз, ий Ислам әһелләре, ни өчен Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә гыйлем алучыга вә таратучыга чиксез күп әҗер-саваплар вә җәннәт бакчаларын вәгъдә иткән? Дөрес, гыйлем алу вә тарату, әхлаклы булу динебезнең асылы булганга күрә! «Кем дә кем Аллаһы диненең бер мәсьәләсен өйрәнсә, ул аның өчен мең рәкәгать өстәмә намаз укудан хәерлерәк!» — дип өйрәтә безне Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм[1]. Хәзер санап алыйк, кардәшләр, 1000 рәкәгать намаз, кыска сүрәләр белән вә тиз укылса, кимендә бер көн вакытыгызны ала, ә диндәге бер теманы өйрәнү? Бер сәгать чамасы. Үзебезгә кагыйдә буларак һәр көн динебезне бераз булса да өйрәнергә сүз бирсәк һәм моны башкарсак, күпме әҗергә ия була алабыз. Шундый ук мәгънәдәге берничә хәдис билгеле. «Бер сәгать дини гыйлем алу төнне гыйбадәттә үткәрүдән хәерлерәк, ә көн дәвамында динне өйрәнү өч ай тоташтан ураза тотудан да өстен!»[2]

Имам әл-Хатыйбта килә: «Ислам динен өйрәнүчене Аллаһы Тәгалә дөнья мәшәкатьләреннән азат итәр һәм көтмәгән җирдән Үзе ризыкландырыр!» Кардәшләрем, гыйлем алучыга Аллаһыбыздан күпме әҗер, күпме нигъмәт, бәрәкәт, ярдәм вә мәгъфирәт әзерләп куелганын белеп тә, караңгылыкта калуны сайлыйбызмы? Яки, тормышыбызда бераз булса да нәрсәнедер үзгәртеп, Аллаһыбызга якыная башлыйбызмы?

Җәмәгать, шулай ук гыйлем алу юлында булган кешенең Раббысы каршындагы дәрәҗәсен дә ассызыклап билгеләп үтәсем килә. Әбү әд-Дәрдә радыяллаһу ганһедән риваять ителә, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Белем алырга дип юлга чыккан кешегә Аллаһы Тәгалә җәннәткә юлын җиңеләйтер, шул кешегә фәрештәләр канатларын җәеп торырлар, аңа ризалыкларын белдереп, барлык җир, су вә һавада яшәүчеләр белән бергә аның өчен дога кылырлар!» — дип өйрәтә безне. Башка хәдистә: «Белем алырга дип юлга чыккан кеше Аллаһы юлында тырышучы дип саналыр, һәм,

---

[1] Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе риваяте.

[2] Әд-Дәйләми радыяллаһу ганһе риваяте.

өенә әйләнеп кайтканчы, шул хәлдә булыр, ә бу ният белән үлемен каршы алса, шәһит үлеме белән үлгән дип хисапланыр!» — диелә[1]. «Гыйлем алырга омтылу Аллаһыбыз каршында намаздан, уразадан, хаждан һәм җиһадтан өстенрәк!» — дип әйтә торган булган пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм[2].

Йә җәмәгател-мөслимин, инде күп калмады, тиздән мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә дәресләр, укулар башланачак, Аллаһы боерса. Күпмебез аларга язылыр, кушылыр икән? Күпмебез аларны тиешенчә тәмамлар? Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләнең ризалыгына ирешергә, Аның яклавында, саклавында, рәхмәтендә, бәрәкәтендә булырга теләүче — һәрберебез!

Кардәшләрем, бүгенге көндә, мәгълүмат чоры (информационный век) үзенең таләпләрен алга сөргәндә, безнең динебезгә хезмәтебез сүз вә каләм белән булырга тиеш. Ә без бу юлда тырышабызмы? Каршыбызда зур җаваплылык, җәмәгать: Ислам динен кешеләргә өйрәтү, тарату, туры юлны сайларга өндәү — безнең бурычыбыз. Һәм бу бурычыбызны, вазифабызны Раббыбыз каршында тиешлечә үтәр өчен, иң элек динебезне үзебезгә өйрәнү шарт!

Халкыбыз мең елдан артык Ислам динендә, әлхәмдүлилләһ. Монгол яуларын да күргән бабаларыбыз, дин югалмаган. Явыз Иван сынавын да кичкән халкыбыз, дин бетмәгән. Петр I сәясәтен татыган, дин туктамаган. Инкыйлаб (революция) — руханиларны атып, асып, манараларны кисү, мәчетләрне ябулар — динебез исән калды. Аннан соң тарихның иң куркыныч сугышларының берсе — Бөек Ватан сугышы, дин беттеме? Юк, бетмәде, туктамады, Аллаһыга шөкер! Хәзер без, бер мизгелгә булса да, күз алдыбызга китерик: бу дин, Ислам дине, бездә туктаса, бездә бетсә, Кыямәт көнендә Аллаһыбызга без ни дип әйтә алабыз? Җәмәгать, ничек акланачакбыз, динебез бездә туктап калса?

---

[1] Имам әт-Тирмизи.

[2] Имам әт-Табарани.

Газиз мөселман кардәшләрем, беркайчан да онытмыйк: диннең бетүе гыйлем югалудан башлана, дин гыйлемсез яши алмый, гыйлемсез дин таралмый. Һәм бу мәсьәлә безнең турыдан-туры җаваплылыгыбыз!

Кардәшләрем, исегезгә Аллаһы Тәгаләнең мондый сүзләрен төшерәсем килә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِن تَنصُرُوا اللَّهَ يَنصُرْكُمْ وَيُثَبِّتْ أَقْدَامَكُمْ ﴿٧﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сез Аллаһыга** [Аның диненә, пәйгамбәренә һәм китабына] **ярдәм итсәгез, Ул да** [дошманнарыгызга каршы] **сезгә ярдәм итәчәк һәм аяк табаннарыгызны нык итәчәк».**

«Мөхәммәд», 47:7

Һичшиксез, Аллаһы Тәгалә беркемгә дә мохтаҗ түгел, моны яхшы беләбез, Ул — على كل شيء قدير — бар нәрсәгә дә кодрәтле! Бу аятьнең хак мәгънәсе исә: әгәр дә сез Аллаһы юлында тырышсагыз (ә иң яхшы тырышу — гыйлем алып, аны башкаларга тапшыру, дип өйрәндек), Аллаһы сезгә бар эшләрегездә Үзе булышыр һәм иманнарыгызны ныгытыр, динегезне камилләштерер! Шуны онытмыйк, кардәшләрем!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Алмаз хәзрәт Закиров,*

*Әтнә районы мөхтәсибәтенең дәгъват бүлеге хезмәткәре*

*17 октябрь вәгазе,*

*рабигыль-ахыр аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Тормышыңны бозма

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрне юктан бар итүче Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, мактауларыбыз булсын. Ике дөньяга рәхмәт булып җибәрелмеш сөекле Пәйгамбәребезгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешеп торсын.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бүген бик мөһим, шуның белән бергә бик куркыныч бер темага — кеше тормышын бозучы наркотиклар, электрон тәмәке һәм башка зарарлы гадәтләр турында сөйләшәсе килә.

Монда җыелган һәрбер кешегә Аллаһы Тәгалә бик зур нигъмәтләр булган сәламәтлек, акыл һәм ирек биргән. Әмма, кызганыч, күп вакытта кешеләр бу нигъмәтләрнең кадерен белмиләр, үз гамәлләре белән аларны җимерәләр. Ә Аллаһы Тәгалә моны харам кылды. Коръәндә Раббыбыз әйтә:

وَلَا تُلْقُوا بِأَيْدِيكُمْ إِلَى التَّهْلُكَةِ

**«... үз кулларыгыз белән** [үзегезне] **һәлакәткә ташламагыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:195

Шулай ук бүтән аятьтә Аллаһы Тәгалә болай ди:

وَلَا تَقْتُلُوا أَنفُسَكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا

**«Үзегезне үзегез үтермәгез. Аллаһы сезгә карата Рәхимле».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:29

Хәдисләрдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кат-кат безгә үзебезгә зыян китерергә тыйды. Мәсәлән: «Үзегезгә дә, башкаларга да зарар китермәгез!»[1]

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук әйткән: «Иманлы кеше үз-үзен хур итмәскә тиеш». Янында булган кешеләр: «Ничек үз-үзен хур итә ала?» — дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Ул үзе күтәрә алмаган сынауларга бирелеп», — дип җавап биргән[2]. Бу хәдиснең мәгънәсенә карап: кеше гөнаһ эшләрне эшләп, үзе авыр хәлгә калуга үзе гаепле булып тора.

Наркодиспансерларга эләккән кешеләр арасында сораштыру үткәргәннәр. Бу сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, наркоманнарның 95 %: «Минем гомерем бетте. Гаиләм мине онытты». «Электрон тәмәке начар түгел дип уйлаган идем. Хәзер үпкәм җимерелгән, акчам беткән!» «Үз тормышымны юкка югалттым!» — дип үкенәләр икән.

Бер 15 ел наркоман булган кеше, интервью биргәндә, үзе турында сөйли:

**Журналист:** «Гаиләгез наркотик турында белгәч, моңа ничек карады?»

**Наркоман:** «Минем гаиләм юк инде… Мин анамның дүртенче баласы. Наркотиклардан соң алар барысы да минем белән аралашудан туктадылар. Мин аларны югалттым. Бер олы сеңлем генә миңа ышанычын саклады һәм саклый да, аның ире дә мине калдырмады. Без хәзер дә аралашабыз».

**Ж.:** «Син дәваланып карадыңмы? Клиника, табибларның йогынтысы бармы?»

**Н.:** «Әлбәттә! Ләкин мин үземне тота алмый калдым. Барлык бу табиблар… бәлки берәрсенә ярдәм итәләрдер, ләкин миңа түгел. Бәлки моның

[1] Имам Ибне Мәҗә, имам Әхмәд.

[2] Имам әт-Тирмизи.

да үз файдасы бардыр, ләкин миңа ярдәм итә алырлык белгечләр туры килмәде».

**Ж.:** «Бу бәладән ничек котылдың соң?»

**Н.:** «Берничек тә. Мине төрмәгә утырттылар. Юк, наркотиклар өчен түгел».

**Ж.:** «Ә нәрсә өчен?»

**Н.:** Эй, мин күңелемне ачып, еларга җыенмыйм… бу минем өчен яраклы ысул түгел. Бу еллар эчендә күпме ачык сөйләшүләр, күңел газаплары, авырту, җәфалар булды — боларның берсе дә миңа ташларга ярдәм итмәде. Мине башка эш өчен утырттылар… 10 елга. Шулай итеп ташладым. Төрмәдә беркем дә минем авыруым белән кызыксынмады. Шулай итеп ломканы кичереп чыктым».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән:

«Дин вә дөнья өчен иң зарарлы нәрсә — хәмер»[1].

Статистикалар күрсәткәнчә, начар гадәтләр аркасында гаиләләрнең 78 % таркала; 92 % очракта начар гадәте булган кеше эшеннән куыла һәм 65 % очракта ул җинаять кылып, җаваплылыкка тартыла.

Газиз дин кардәшләрем, бу куркыныч гадәтләргә үзебез, балаларыбыз дучар булмасын өчен, нәрсә эшли алабыз?

Беренчедән, намазны өйрәнеп, аны вакытында үтәгез! Кемдер монда бәйләнеш тапмаска мөмкин, әмма намаз кешене явызлыктан саклый.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ

**«Намаз әшәкелекләрдән дә, гаеп саналганнардан да саклый».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

[1] Имам әл-Бәйһакый.

Икенчедән, яман «дуслардан» ераклашыгыз! Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә: «Кеше дусларының дине буенчадыр»[1].

Өченче киңәш — гаиләгез белән күбрәк вакыт үткәрегез! Алар — Аллаһы биргән әманәт. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә болай ди: «Һәрберегез — күзәтүче һәм һәрберегез үз күзәтүе астындагылар хакында җавап бирәчәксез... Ир — өе әһелләре өстеннән күзәтүчедер, һәм ул алар хакында җавап бирәчәк».

Ата-аналарга тагын мондый киңәшләр бирергә мөмкин:

— Балалар спорт белән шөгыльләнсен.

— Үсеп җиткән ул һәм кызларны иртәрәк гаиләле, никахлы итәргә тырышырга.

— Балаларны өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтү.

Хөрмәтле кардәшләрем! Әгәр дә сез яки якыннарыгыз мондый начар гадәтләргә ия булса, кире кайтырга мөмкинлек бар! Аллаһы Тәгалә Рәхимле, Ул бөтен гөнаһларны гафу итә ала. Тәүбә ишекләре һәрвакыт ачык. Тәүбә итәргә, яңа тормыш башларга мөһим. Табиблар ярдәменә дә мөрәҗәгать итегез.

Тәүбә итегез! Намаз белән Аллаһыга якынаегыз, явызлыктан ераклашыгыз!

اللَّهُمَّ اجْعَلْنَا مِنَ التَّوَّابِينَ وَاجْعَلْنَا مِنَ الْمُتَطَهِّرِينَ

«Аллаһым, безне тәүбә итүчеләрдән һәм пакьленүчеләрдән ит!»

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел

[1] Имам әт-Тирмизи.

тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Габделхәким хәзрәт Сафарханов,*

*Яшел Үзәннең «Тынычлык» мәчете имам-хатыйбы*

*24 октябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Үлем — иң олуг нәсыйхәт

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне акыл нигъмәте белән бүләкләп, барлык мәхлуклардан өстен кылган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәгаләнең хәбибе һәм хак Илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Рухи яктан пакьләнеп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, Аллаһы Раббыбыз барчабызга Үзенең чиксез сәламен, рәхмәтен һәм бәрәкәтен насыйп итсен!

Адәм баласы ничек кенә бәхетле, сау-сәламәт, матур гомер итмәсен, бу тормышның ахыры бар. Чөнки Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә, галәмнәрне бар кылганда, аларның ахырын да булдырды: һәр эшнең, һәр гамәлнең азагы булган кебек, адәм балалары гомеренең дә ахыры бар, һәм ул үлем дип атала. Фәкать Аллаһы Үзе мәңгелек! Шуңа күрә бу дөньяда Аның кануны белән яшибез һәм бакыйлыкка да Аллаһының әмере илә күчәбез. Фани дөньяга кеше үзенең нинди кыяфәттә булачагыннан һәм нинди гамәлләр кылачагыннан хәбәрдар булып килми; кайда, кайчан үләчәгебез турында да бездә бернинди

мәгълүмат юк, барысы да Аллаһы әмере вә теләге белән башкарыла. Әмма һәрберебезгә кайчан да булса бу дөньядан китәчәгебез мәгълүм.

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ۗ

**«Һәрбер җан үлемне татыячак».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Үлгәннән соң безне ни көтә? Үлдек тә, бетте, Аллаһы Тәгалә каршында җавап бирәсебез юк, дип уйлаучылар ни дәрәҗәдә ялгыша? Гомумән, нәрсә ул үлем? Адәм баласы гомеренең кайсы да булса бер мизгелендә мәетне соңгы юлга озату мәшәкатьләрендә катнашмый калмый. Кемдер кадерле әти-әнисен югалта, газиз баласын җирли, якын туганнары, дуслары белән мәңгегә хушлаша. Мәрхүмне салкын ләхеткә куеп, өстенә туфрак сибеп, караңгы кабергә иңдерү аеруча куркыныч кебек тоела шул! Үлемне ниндидер бер югалту, бетү дип кабул итәбез, билгесезлектән куркабыз... Чөнки хакыйкый гыйлем юк.

Тормышларыбыз бигрәк тә бай, җитеш булганда, беребезнең дә үлем турында искә төшерәсе килми, дөнья ләззәтеннән аерылырга теләмибез. Шуңа күрә үлемнән соң булачак тормыш хакында һәр заманда зур-зур галимнәр, фәлсәфәчеләр гел уйлана килделәр: кабердә, ахирәттә ни көтә адәм баласын? Аллаһыдан килгән изге китапларда (Тәүрат, Зәбур, Инҗил, Коръән) бу хакта мәгълүмат бар. Шушы китапларга таянып, үз фаразларын корып, илаһият белгечләре могҗизаи сүзләр әйттеләр. Әгәр адәм баласы, Аллаһының барлыгын вә берлеген танып, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләреннән йөз чөерми, иманлы тормыш белән яшәсә, үлемнән куркуы азаер һәм үлемнең фәкать тән өчен булуын аңлар иде. Ә җаныбыз исә — мәңгелек! Бер мәртәбә Аллаһының чиксез рәхмәтләре аша шушы җаныбыз аналарыбыз карынына иңдерелде, җан кергәнче әле без мәет идек. Аннан соң якты дөньяга чыктык, ягъни тудык. Икенче төрле әйткәндә, башта

мәет булдык, аннан соң тереләдек, фани дөньядан бакыйлыкка күчкәндә исә янә мәет булачакбыз. Безнең бу дөньядагы үлемебез — ахирәт өчен туу ул. Ягъни, Кыямәт көнендә барчабыз терелеп, җыелып, Аллаһы янына кайтачакбыз. Үлем белән тереклек җан һәм тәннең берләшүенә яки аерылышуына бәйле. Шуңа күрә галимнәр адәм баласы ике үлем, ике тереклек кичерә, дип әйтәләр. Соңгы тереклек — мәңгелек, Раббысы янында кеше мәңгегә калачак.

Адәм баласының тәне, билгеле бер сәбәпләр аркасында җанны тотып тора алмый торган хәлгә җитеп зәгыйфьләнгәч, бу тәннән җан аерыла. Үлем сәгате якынлашкач, һәр кеше күз күреме ераклыгында үлем фәрештәсен күрер. Әгәр кеше иманлы, гомерен изге гамәлләр кылып үткәргән булса, аңа фәрештә ак йөзле булып күренер, үзеннән хуш исләр килер. Үлем фәрештәсе артында берничә фәрештә ак кәфенлек тотып торырлар. Адәмнең җаны чыга башлауга, аяклары суынганда, үлем фәрештәсе дә аңа якынаер. Иң авыры — җан бугазга килеп терәлгәндә. Үлем фәрештәсе инсанның янына ук килеп утырыр һәм иманлы бу бәндәгә: «Чык Аллаһының рәхмәтенә», — дияр. Мондый кешенең җаны суга тыгып алган инәдән су тамчылары аккан кебек, тәннән җиңел аерылыр. Тик шулай да җан чыгуы авыр, һәм аның тәннән аерылу мизгелен җиңеләйтүче чара динебездә бар — ул «Йәсин» сүрәсен уку. Хәдистә килә: «Йәсин»не укыгыз, ул җан чыгуны җиңеләйтер».

Җан чыкканнан соң, аны ак кәфенлеккә төрәләр, һәм үлем фәрештәсе бу җанны җиде кат күкләргә, Аллаһы тарафына күтәрә. Күкнең һәр катында бу җан өчен ишекләр ачык булыр. Җиденче катына менеп җиткәч, Аллаһы Раббыбыз җанның кемнеке булуын сорар. Фәрештәләрдән тулы җавап ишеткәч, моның исемен изге китапка языгыз, дияр. Шуннан соң җан чыккан җиренә кире кайтарылыр һәм күмгәнчегә кадәр тәне өстендә торыр. Үзе белән хушлашырга килгән якыннарын, туганнарын, дусларын ул күрә, хәтта юатмакчы да була, әмма аның тавышын ишетмиләр. Җан авазын фәкать кошлар, хайваннар ишетә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм

әйтә: «Әгәр җан тавышын ишетсәләр, кешеләр шунда ук иманга килерләр иде», — ди. Әмма ишетмибез...

Аллаһыга иман китермичә яшәгән кешенең үлем сәгате сукканда, аның да күзенә үлем фәрештәсе күренер. Ләкин инде башка — куркыныч кара йөзле, ямьсез кыяфәттә килеп басар. Артындагы фәрештәләр дә ак түгел, ә бәлки кара кәфенлек тотып торырлар. Җаны бугазына килеп терәлгәч, үлем фәрештәсе моның да аяк очына килеп утырыр һәм: «Чык Аллаһының газабына», — дип дәшер. Сарык йонына буталып эләккән кармакны азаплана-азаплана алган кебек, бу кешенең дә җаны тәненнән тиз генә аерылмас. Хәтта «Йәсин» уку да булыша алмас, чөнки Коръән — иман китергән бәндәләргә генә ярдәмче вә таяныч. Кара кәфенлек белән бу җанны күккә күтәрерләр, әмма беренче катында ук ишекләр бикле булыр, ачылмас... Аллаһының әмере илә җан хәерсезләр исемлегенә язылып куелыр; беренче кат күкнең ишеге төбеннән үк кире борылыр һәм, җәсәде ләхеткә иңдерелгәнче, тәне өстендә көтеп торыр. «Тизрәк кабергә салыгыз!» — дип кычкырыр, чөнки белә: әле аны кабердә дә зур сынаулар көтә. Гомумән, мәетне күмүне ашыктырырга кирәк, тән өчен иң хәерлесе шушы булыр. Кайбер диннәрнең тәгълиматы буенча, мәсәлән индуизм буенча, үлгән кешенең тәнен утта яндырып, көлен елга өстенә сибәләр. Болай эшләү зур гөнаһ. Аллаһыдан башка беркемнең дә башка берәүнең тәнен утта яндырырга хакы юк!

Әлбәттә, ничә еллар җир йөзендә тән эчендә яшәгән җан үзенең яңа халәтенә тиз генә ияләнә алмый. Ул үзенең бар икәнен сизә, тәнен күрә, тотмакчы була — кулы юк, басмакчы була — аягы юк... Гакылыбызга сыймаслык яңа хәл! Дөньяга яңа туган сабый да бик авырлык белән ияләшә бит: көнтөн елый, сәбәбе дә юк кебек, ә үзе көйсезләнә. Аннан акрын-акрын гына тәпи йөреп китә, сөйләшә башлый. Шуның кебек җан да икенче дөньяны танырга өйрәнә.

Димәк, үлем — яңа бер киңлеккә, яңа тормышка күчү. Монда инде фани дөнья белән ахирәтне аерып торучы тормыш — бәрзах — башлана. Шуңа күрә

галимнәр адәм баласы дүрт гомер кичерә дип әйтә: анасы карыны, фани дөнья, бәрзахи тормыш, ахирәт. Бу дөньядан тәнебезне калдырып китү аның киләсе тормышта кирәк булмавын аңлата. Ана карынында баланың яшәешен соңгылык (плацента) тәэмин итеп тора, ул булмаса, бала бер генә минут та яши алмый. Анадан тугач исә аның кирәге калмый. Балам соңгылыктан башка ничек яшәр, дип ана кеше еламый бит; шуның кебек мәетнең җәсәде өстендә дә: «Нишләр икән ул салкын кабергә кереп яткач», — дип өзгәләнү дөрес күренеш түгел. Безнең татар халкы элек-электән җеназа үткәргәндә зур түземлелек, сабырлык саклаган, үзен тыйнак тоткан. Мәрхүмнәр өстендә тавышланып елау безнең халыкка хас гадәт түгел, мөмкин кадәр бабайларыбыздан үрнәк алу тиешле.

Инде җан күбрәк мәгълүматлы, бөегрәк бәрзахи тормышка күчте. Галимнәрнең әйтүенә караганда, ана карыны белән җир йөзендәге дөньяның зурлыгын, киңлеген чагыштырганда, нинди искитмәле аермага тап булсак, бәрзахи тормыш белән бу дөнья арасында да шундый ук аерма икән! Ахирәтне бәрзах белән чагыштырсак, зурлык ягыннан янә шул рәвешле үк аерма күзалланыр. Аллаһының кодрәте чиксез! Бу тормыш турында Коръәндә дә, хәдисләрдә дә мәгълүмат бик аз. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә Аллаһы Тәгалә «әл-Исра» сүрәсенең 85 нче аятендә болай дип дәшә:

وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الرُّوحِ ۖ قُلِ الرُّوحُ مِنْ أَمْرِ رَبِّي وَمَا أُوتِيتُم مِّنَ الْعِلْمِ إِلَّا قَلِيلًا ﴿٨٥﴾

> **«Алар синнән рух хакында сорыйлар. Әйт: «Рух — Раббымның** [«Бар бул!» дигән] **әмереннән** [яратылган нәрсәләрдән]**. Сезгә исә гыйлемнән аз бер өлеш кенә бирелде».**
>
> «Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:85

Адәм баласын кабергә салып, яныннан иң соңгы кеше 40 адым җир киткәч, ике фәрештә — Мөнкир белән Нәкир — килеп, сорау ала башлар.

Бу вакытта җан тәнгә кире кайта, әмма күкрәккә хәтле генә иңә, ул тоя, күрә, ишетә. Әлбәттә, колак һәм күз белән түгел, башка рәвештә. Хәдистә мәетләрнең өстә йөргән аяк тавышларын ишетеп ятулары хәбәр ителә. Әлеге ике фәрештә фәкать өч сорау бирер: «Раббың кем? Динең нинди? Пәйгамбәрең кем?» Адәм баласы дөньялыкта бу сорауларга җавапны өйрәнеп, белеп яшәсә дә, әгәр тормышын Аллаһы кануннары нигезендә кормыйча, имансыз яшәп, имансыз китә икән, ул җавапларны әйтә алмас. Шуннан башланыр кабер газаплары... «Раббым — Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә, динем — Ислам дине, пәйгамбәрем — Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм», — дигән җавапны иман белән яшәп, дөньялыктан шулай ук иман белән киткәннәр генә әйтә алыр.

«Кабер газабыннан котылу өчен, дүрт нәрсәне үтәгез, дүрт нәрсәдән тыелыгыз», — диде Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм. Беренчесе — биш вакыт намазны вакытында үтәү, икенчесе — зәкят түләү, өченчесе — Коръән уку, дүртенчесе — күп итеп тәсбих кылу, ягъни Аллаһыны зикер итү. Шушылар каберне киңәйтер вә нурландырыр. Тыелырга кушканнары түбәндәгеләр: ялганлау, хыянәт, сүз йөртү, бәвелдән (сидектән) пакьләнмәү. Соңгысы турында аеруча кисәтә Расүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сакланыгыз бәвелдән, кабер газабының күбесе бәвелдән сакланмавыгыз сәбәпле». Киемгә бер тамчы бәвел тию һәм аннан пакьләнмәү дә кабер газабына илтергә мөмкин. Шуның өчен мөселманның кешелек сыйфаты нәҗестән пакь кием кию булыр.

Хәзрәти Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе каберлекләр янында туктап, озак елап торган булган. Моны күреп, мөселманнар гаҗәпкә калган: «Ни булды, җәһәннәмне искә алганда да күз яшьләреңне тыя идең бит, монда ник елыйсың?» — дигәннәр. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Дөреслектә, каберлекләр — ахирәт йортларының берседер. Әгәр аннан котылсаң, аннан соңгысы кабердән җиңелрәктер, әгәр котылмасаң, аннан соңгысы кабердәгедән авырррактыр», — дип әйткән. Кайберәүләр, дөнья рәхәтенә

яки, киресенчә, авырлыгына чыдый алмыйча, үз-үзләренә кул сала. Имеш, аның башына күтәрә алмастай сынаулар төшкән. Дөрес түгел: Аллаһы Тәгалә инсаннарга сынауны рухи халәтенә, әзерлегенә карап бирә, күтәрә алмастай йөк белән беркемне дә йөкләми. Адәм баласы, үләм дә, котылам, дип уйлап, бик нык ялгыша һәм тагы да хәтәррәк хәлләргә килеп эләгә. Болар барысы да хакыйкый гыйлем юклыктан килә шул, кызганыч. Бүген илебездә мордар китүчеләр саны елдан-ел артып тора. Әгәр кабер газабы, бәрзах тормышы, ахирәт хакында хәбәрдар булсалар, дөньялыкта сыналган сынаулары болар алдында бик кечкенә булып калырлар иде! Җан — ул Аллаһы тарафыннан адәм балаларына тапшырылган әманәт, аны күз карасыдай саклау тиешле.

Әл-Хәмед бине Мәхмүд ән-Нәгъвәли риваять кыла: «Ибне Габбас радыяллаһу ганһе янында утырганда, бер кавем килде һәм: «Без хаҗ кылырга чыккан идек, юлда бер иптәшебез үлде. Аны далада күмәргә дип, кабер илә ләхет әзерләдек. Мәетне ләхеткә индерергә торганда, ни күрик: анда еланнар бөгәрләнеп ята! Монысын ташлап, тиз генә икенче урында казыдык, анда да кара еланнар тулган иде. Өченче кабер белән дә шул хәл килеп чыкты. Инде иптәшебезне кайда күмик? Сезнең янга киңәш сорап килдек», — диделәр. Хәзрәти Габбас болай дип әйтте: «Бу еланнар — аның кылган гамәледер. Барыгыз, каберләрнең берсенә күмегез. Валлаһи, бөтен даланы казып чыксагыз да, еланнардан котыла алмассыз, кавеменә хәбәр бирегез». Бу кешеләр иптәшләрен җирләп, кайтып, хатыныннан сорыйлар: «Иреңнең нинди гамәле бар иде?» Хатын болай җавап бирә: «Ирем бодай сатучы булды, әмма бер өлеш бодай орлыгы салса, калганын башка орлыклар белән катыштыра иде». Менә бу хыянәт була инде! Безнең заманда да кайбер сәүдәгәрләр үзләрен әлеге кешедән ким тотмый. Тизрәк баю, акча туплау өчен, халыкны кычкыртып талыйлар, үлчәүләрендә гаделлек юк. Мәгәр хыянәт дигәндә, сәүдә өлкәсен генә күздә тотмыйбыз. Ул булырга мөмкин хәләл җефетеңә, балаларыңа, туганнарыңа, иманыңа карата да.

Әлбәттә, кабер газаплары хакында күп сөйләргә була. Әмма галимнәр төрле фикер әйтә: берләре кабер газабы рух өчен генә, тән өчен түгел, ди. Икенчеләре тән дә, рух та җәзалана, дип саный. Өченче төркем галимнәр кабердә чакта җан тәнгә кире кайтмый дигән фикерне алга сөрсә, дүртенчеләре моның киресен раслый. Ничек кенә әйтсәләр дә, һәрберсенең үз дәлиле бар! Бу мәсьәләдә хакыйкый мөселман шикләнергә, ышанмаучылык күрсәтергә тиеш түгел.

Кабер газабына ышанмаучыларны икегә бүлеп карарга була. Берләре бу күренеш акылга сыймый, адәмнәрнең табигатенә хас нәрсә түгел, дип әйтә. Андыйларга җавабым шул: пәйгамбәрләр тышкы кыяфәтләре ягыннан гади кешедән бернәрсәсе белән дә аерылып тормады — борын да, күз-колаклар да үз урынында. Әмма алар фәрештәләрне күрде, ә без күрмибез. Аллаһы илчеләренә могҗизалар бирде. Мәсәлән: Муса галәйһиссәламнең таягы еланга әйләнде, Гайсә галәйһиссәлам үлеләрне терелтә иде, ә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең иң зур могҗизасы — Коръән. Шуңа күрә, әгәр кеше, акылга сыймый дип, кабер газабын инкяр итә икән, ул пәйгамбәрләрне дә инкяр иткән булып чыга, һәм шуның белән ислами милләттән дә чыккан санала.

Икенче төр ышанмаучылар бу хакта катгый дәлилләр юк, дип әйтә. Әмма, җентекләп тикшерсәк, Коръәндә дә, хәдисләрдә дә кабер газабының хаклыгын дәлилли торган мисалларны күрербез. Аларның беренчесе — «Ибраһим» сүрәсенең 27 нче аяте:

يُثَبِّتُ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا بِالْقَوْلِ الثَّابِتِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَفِي الْآخِرَةِ ۖ

> **«Аллаһы иман китергән кешеләрне дөнья тормышында да, ахирәттә дә көчле** [тәүхид кәлимәсе булган] **сүз белән** [Ислам динендә] **ныгыта».**

«Ибраһим», 14:27

Биредә ахирәт сүзе кабер дигән мәгънәгә ия. Ни өчен? Имамнар әл-Бохари, Мөслим, ән-Нәсаи, Әбү Давыдлар китергән хәдис-шәрифтән күрәбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Әгәр мөэмин кабергә яткызылса, аның янына фәрештәләр килер һәм шаһитлек кылдырыр, бу сүзне «Ибраһим» сүрәсенең 27 нче аяте исбатлый». Шушы дәлилләрне белә, ишетә торып, кабер газабы юк дип әйтеп буламы? Бу хәдисне күп галимнәр риваять кыла.

Икенче дәлил — Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең догасы. Кабер газабыннан котылу өчен, шушы доганы кылыгыз, ди Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Йә Раббым, кабер газабыннан Үзеңә сыенамын!»

Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләнең рәхмәтләре чиксез — кабер газабына бөтенләй дә дучар ителми торган кешеләр бар. Алар: пәйгамбәрләр, балигълык яшенә җитми үлгән сабый балалар, мөселманнарны дошман явыннан саклаучылар, Аллаһы юлында корбан булган шәһитләр, эч (ашказаны) авыруыннан үлеп киткән кеше (бу хакта Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисе бар: «Эчтәге авыру сәбәпле вафат кеше кабердә газапланмас»), «Тәбәрак» сүрәсен укыган кеше (Расүлебез галәйһиссәлам әйткәнне имам әт-Тирмизи китерә: «Коръәндә 30 аятьле сүрә бар, кем аны укыса, гөнаһлары кичерелер һәм ул кабер газабына дучар ителмәс»), җомга көнендә яки төнендә үлгән кешеләр (әт-Тирмизи риваятендә болай диелә: «Бер мөселман җомга көн яки кич вафат булса, кабер газабыннан имин кылыныр»).

Раббыбыз безләрне шушы әһелләрдән насыйп әйләсен, дип догада булыйк, җәмәгать. Кулыбыздан байлык, тәнебездән саулык китеп баргач кына түгел, сау-сәламәт һәм матур, бай тормышта яшәгәндә дә, үлемне һәрчак искә алыйк. Җаныбыз бит Аллаһыдан әманәт буларак бирелә, ә әманәтне кадерләп саклыйлар да, кире Хуҗасына кайтарып бирәләр — Аллаһының кануны шундый! Бу канунны бозып, үзебезгә үзебез зыян салмыйк.

Кыямәт көне килгәнче, һәр кеше үз күңеленә хисап ясасын: үлгәннән соң ни көтә мине, кылган хәерле гамәлләрем савап булып барырмы дип,

үз-үзенә сорау бирсен адәм баласы. Аллаһы Тәгалә үлем белән тереклекне кайсыбызның изге гамәлләре күбрәк булачагын сынар өчен яраткан. Үлемне һәрвакыт искә төшереп тору кирәк. Кайчан да булса бу дөньяны калдырып китәсе бар бит дип уйлау адәм баласының тормышын дөресли, иманы каршысында җаваплылыгын арттыра, адашмаска ярдәм итә.

إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ

Барыбыз да — патшасы да, колы да — кылган гамәлләребезне җыеп, Аллаһы хозурына кайтачакбыз…

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Фәнис хәзрәт Низамов,*

*Аксубай районы Яңа Дума авылы мәчете имам-хатыйбы*

*31 октябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Сабыр итү

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, вәгазьләребезнең берсендә динебезнең, иманыбызның ике өлештән торуы хакында сөйләшкән идек. Бер өлеше аның шөкер итү булса, ә икенче өлеше — сабырлык күрсәтү. Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе сөйләвенчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Иман ике өлештән торадыр. Беренче яртысы — сабырлыктан, ә икенче яртысы — шөкердән»[1]. Без нәрсә ул шөкер, шөкер кылу ничек булуы хакында сөйләгән идек, ә хәзер инде динебезнең тагын бер өлеше булган сабырлык хакында сөйләшербез.

Динебездә сабырлыкның өлеше шөкергә караганда да күбрәктер, чөнки Аллаһыга шөкер итү өчен дә сабырлык кирәк. Биш вакыт намаз уку өчен дә күпме сабырлык кирәк. Ураза тоту, зәкят түләү, хаҗга бару һәм башка күптөрле изгелекләр, итагатьләр кылу өчен дә сабырлык кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз ахырында Мөгаз бине Җәбәл исемле сәхабәсенә радыяллаһу ганһе шушы доганы кылырга кушты:

اللّٰهُمَّ أَعِنِّي عَلى ذِكْرِكَ وَشُكْرِكَ، وَحُسْنِ عِبادَتِكَ

«Аллаһым! Миңа Сине зикер кылырга, Сиңа шөкер кылырга һәм Сиңа күркәм рәвештә гыйбадәт кылырга ярдәм ит».

[1] Имам әл-Бәйһакый, имам әд-Дәйләми.

Чөнки, әгәр дә Аллаһы сиңа ярдәм итмәсә, синең Аңа шөкер кылу өчен көчең һәм теләгең дә булмас. Ялкаулык басар, онытырсың һәм вакыт та таба алмассың. Бер галим әйтүенчә, әгәр Аллаһы Үзенең колын газапларга теләсә, Ул аннан гыйбадәт кылуның ләззәтен алыр, һәм шулай итеп ул эшләгән изгелекләрен калдырыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм төннәренең күп өлешләрен намазда, кыямда үткәрә торган була. Шул сәбәпле аның аяклары шешеп, ярыла иде. Һәм бер көнне хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә, аны кызганып: «Әй Аллаһының Илчесе! Нигә син үзеңне шулай азаплыйсың?» — дип сорагач, ул аңа: «Әй Гайшә, миңа шөкер кылучы кол булмаскамы», — дип җавап биргән.

Шулай озак гыйбадәт кылу өчен, Аллаһы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә көч һәм сабырлык бирде. Без, гади кешеләргә килгәндә, төнге намаз уку түгел, хәтта кайберләребез төнлә белән уянырга да көч таба алмыйбыз. Аллаһы көч бирмәсә, аны каян алырсың? Мөселман кеше, фарызлар белән генә чикләнмичә, үз өстенә өстәмә рәвештә сөннәт гыйбадәтләрне дә йөкләргә тиеш. Әмма көче җитәрлек кадәрен генә. Ул моны үтәп бара алырмы, сабырлыгы җитәрме? Чөнки башлаган изгелекне соңыннан арып ташлап калдыру бик начар билгедер. Бәлки сиңа, төнлә белән торып намаз укыганчы, ятар алдыннан, төнге намаз дип ниятләп, ике рәкәгать укып яту хәерлерәк булыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте бит: «Аллаһыга иң сөекле гамәл — аз булса да, дәвамлы булганы».

Аллаһы Тәгалә «әл-Гаср» сүрәсендә әйтте:

وَالْعَصْرِ ﴿١﴾ إِنَّ الْإِنسَانَ لَفِي خُسْرٍ ﴿٢﴾ إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَتَوَاصَوْا بِالْحَقِّ وَتَوَاصَوْا بِالصَّبْرِ ﴿٣﴾

«[Кешеләрнең эшләре күп булган вакытка туры килгән] **Икенде намазы вакыты белән ант итәмен. Һичшиксез, кешеләр зарарда** [чөнки гомерләрен ахирәттә һич кенә дә файда китермәячәк бозык теләкләрен канәгатьләндерүгә сарыф итәләр]**. Бары иман китергән,** [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек] **изге гамәлләр кылган һәм бер-берләрен хакка өндәгән һәм бер-берләрен сабырлыкка өндәгән кешеләр булмасалар гына».**

«Әл-Гаср / Икенде вакыты», 103

Бу аятьләрдә Аллаһы хәсрәттән котылып, уңышка ирешүчеләр хакында сөйли. Уңышка ирешү өчен сабырлык кирәк. Изге гамәләр кылу өчен сабырлык кирәк, бер-береңне хаклыкка һәм сабырлыкка өндәү өчен сабырлык кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَأْمُرْ أَهْلَكَ بِالصَّلَاةِ وَاصْطَبِرْ عَلَيْهَا ۚ

**«Гаиләңә** [һәм өммәтеңә] **намазны әмер ит. Үзең дә сабырлык белән аны үтә».**

«Та Һа», 20:132

«Әл-Кәһф» сүрәсендә Раббыбыз болай ди:

وَاصْبِرْ نَفْسَكَ مَعَ الَّذِينَ يَدْعُونَ رَبَّهُم بِالْغَدَاةِ وَالْعَشِيِّ يُرِيدُونَ وَجْهَهُ ۖ وَلَا تَعْدُ عَيْنَاكَ عَنْهُمْ تُرِيدُ زِينَةَ الْحَيَاةِ الدُّنْيَا ۖ

**«Иртә-кич Раббыларына Аның ризалыгын сорап дога кылучылар белән үзеңне сабыр тот. Дөнья тормышының** [вакытлы] **зиннәтен теләп, ике күзеңне алардан алма...»**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:28

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм безгә дә мөселманнар белән бергә булырга, вакытыбызны алар белән

үткәрергә һәм бу эштә сабыр булырга чакыра. Мөселманнарны калдырып, дөньяга кызыгып, җаһилләргә ияреп йөрүдән кисәтә. Мөселманнар бергә һәм бердәм булырга тиешләр, фәкыйрьләре дә, байлары да, тазалары да, авырулары да, картлары да, яшьләре дә. Мәчет аларның барысын да берләштерә.

Башка бер аятьтә Раббыбыз сабырлыкка болай өнди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اصْبِرُوا وَصَابِرُوا وَرَابِطُوا وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٢٠٠﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сабыр итегез, сабырлыкта ярышыгыз, атларыгызны бәйдә тотып, чикләрне саклагыз һәм Аллаһыдан куркыгыз, бәлки, уңышка ирешерсез».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:200

Яки, Аллаһы безгә бердәм булырга әмер итеп, сабыр булуның әһәмиятен дә ассызыклап, болай дип әйтә:

وَأَطِيعُوا اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَلَا تَنَازَعُوا فَتَفْشَلُوا وَتَذْهَبَ رِيحُكُمْ ۖ وَاصْبِرُوا ۚ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الصَّابِرِينَ ﴿٤٦﴾

**«Аллаһыга һәм Аның Расүленә салләллаһу галәйһи вә сәлләм итагать итегез. Сүз көрәштермәгез, соңыннан куркуга төшәрсез һәм** [сезне куәтләп, артыгыздан искән] **җилегез** [нигъмәтегез, гайрәтегез] **китәр. Сабыр итегез. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Әнфәл / Табышлар», 8:46

Әгәр кешеләрнең диннәре зәгыйфьләнсә, алар төркемнәргә һәм кавемнәргә аерыла башлаячаклар, һәм көчләре юкка чыгачак. Тарихка карасак, төрле халыклар, шулар арасында мөселман өммәте дә, берләшеп, җиңүләр яуладылар, ә соңыннан, бүлгәләнеп бетеп, җиңүләрен һәм

ирешкәннәрен югалттылар. Диндә сабыр булырга һәм бердәмлекне сакларга кирәк. Югарыда китергән аятьләребез шуны күрсәтә.

Галимнәребез сабырлыкны гадәттә өч төрлегә бүләләр:

**1. Шөкер кылганда, гыйбадәт кылганда сабырлык күрсәтү.** Бу хакта алдарак инде сүз булды. Намаз уку, ураза тоту, зәкят түләү, хаҗны үтәү өчен без сабыр һәм нык булырга тиешбез.

إِلَّا الَّذِينَ صَبَرُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ أُولَٰئِكَ لَهُم مَّغْفِرَةٌ وَأَجْرٌ كَبِيرٌ ﴿١١﴾

> **«Сабыр итүчеләрдән һәм** [булган, булачак бөтен нигъмәтләре өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп] **изге гамәлләр кылучылардан тыш — менә аларга** [адәм баласы буларак кылган бөтен гөнаһларын ярлыкап] **бер мәгъфирәт һәм** [игелекләренә] **зур әҗер».**

«Һуд», 11:11

**2. Гөнаһларга кермәс өчен сабыр итү.** Эшләргә теләгән, нәфес омтылган гөнаһтан тыелып калу бик зур көч һәм сабырлык сорый. Әмма кеше үзен кулга алып, Аллаһы ризалыгы өчен гөнаһка керми, тыелып кала. Монда гөнаһтан тыелу сәламәтлеккә зыян булыр, оятка калырмын, штраф салырлар, төрмәгә утыртырлар дип түгел, ә Аллаһыдан куркып һәм Аннан оялып булырга тиешле. Бу очракта гөнаһтан тыелу изгелеккә әйләнә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә берәү, гөнаһ кылырга ният кылып, шул гөнаһтан тыелып калса, Аллаһы Тәгалә аңа камил изге гамәл эшләгән итеп яза», — дигән. Бу изгелекнең күләме тыелган гөнаһка карап билгеләнә.

Монда сабырлыкның тагы ике төрен өстәргә буладыр. Беренчесе — рәхәтлеккә, гафияткә сабыр итү. Шуңа да борынгылар: «Михнәткә түзеп була, рәхәткә чыдап булмый», — дигәннәр. Икенчесе — ул ачу чыкканда үзеңне тотып калу. Бу да зур көч сорый торган мактаулы эш.

**3. Өченче төр сабырлык — бәла-казаларга, югалтуларга сабыр итү.**

وَلَنَبْلُوَنَّكُم بِشَيْءٍ مِّنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِّنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنفُسِ
وَالثَّمَرَاتِ ۗ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ﴿١٥٥﴾ الَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُم مُّصِيبَةٌ قَالُوا إِنَّا
لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ ﴿١٥٦﴾ أُولَٰئِكَ عَلَيْهِمْ صَلَوَاتٌ مِّن رَّبِّهِمْ وَرَحْمَةٌ ۖ
وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُهْتَدُونَ ﴿١٥٧﴾

**«Без, һичшиксез, сезне бераз — курку белән, бераз — ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга,** [бакча-басуларыгызга афәтләр җибәреп] **уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз.** [Расүлем!] [Сынауларга] **Сабыр итүчеләрне** [җәннәт белән] **сөендер! Берәр бәлагә юлыкканнар: «Һичшиксез, без — Аллаһыныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!» — дип әйтәләр. Әнә шулар — Раббыларының мәгъфирәтенә һәм рәхмәтенә ирешүчеләр, һәм әнә шулар — һидаять табучылар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:155–157

Кем генә булмасын, ул кеше иманлымы, имансызмы, ул бу дөньяда төрле сынауларга, югалтуларга, авыруларга дучар була. Бу Аллаһының куйган кануны. Әмма бу авырлыклар мөэмин өчен Аллаһының рәхмәте булып килсә, имансыз өчен Аллаһының газабы булып киләдер. Ничек аңларга моны? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Мөселманга нәрсә генә ирешсә дә: талчыгумы, авырумы, шомланумы, хәсрәтме, бәхетсезлекме, кайгымы яки чәнечкеле үләннең кадалган энәсеме — Аллаһы һичшиксез моның өчен аның гөнаһларыннан кайсысын да булса гафу итәр»[1]. Мөселман кеше сабыр иткәндә, Аллаһы ризалыгы өчен дип һәм Раббысыннан әҗерләр өмет итеп сабыр итә. Шулай итеп аның сабыр итүе бер изгелеккә әйләнә.

[1] Имам Мөслим.

Аллаһы Тәгалә безне Үзенә шөкер кылучылардан кылып, көферлек кылучылардан кылмаса иде. Һәм дә сабыр итүчеләрдән кылып, өметебезне өзүчеләрдән кылмаса иде. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Марат хәзрәт Сәйфетдинов,*
*Балтачның Үзәк мәчете имамы*

*7 ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Хәләл ризык белән туклан

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Сөбеханә вә Тәгаләгә иксез-чиксез хәмде-сәна, шөкраналарыбыз, мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле Илчесе, газиз пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Ихлас күңел белән, Аллаһының әмеренә буйсынып, дога һәм гыйбадәт кылу өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, изге җомга көнебез барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!

Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ كُلُوا مِمَّا فِي الْأَرْضِ حَلَالًا طَيِّبًا وَلَا تَتَّبِعُوا خُطُوَاتِ الشَّيْطَانِ ۚ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ ﴿١٦٨﴾

**«Ий кешеләр! Җирдә хәләл,** [бөтен шик-шөбһәдән] **пакь булганнардан ашагыз. Шайтанның эзләреннән бармагыз, чөнки ул** [шайтан] **— сезнең ап-ачык дошманыгыз».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:168

Иткә килгәндә, ерткыч җанвар, үләксә һәм дуңгыз итеннән тыш, шәригать кануннары буенча чалынган куш тояклылар (пар тояклылар) һәм

кош итеннән әзерләнгән ризыклар хәләл санала. Дәвам итеп, балыкның күп төрләре, җиләк-җимеш, яшелчә, бөртеклеләр, ярмалар, бал, сөт ризыклары — болар да безнең өчен хәләл булды.

Харам турында да Раббыбыз Корьәни Кәримдә безгә җиткерә:

إِنَّمَا حَرَّمَ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةَ وَالدَّمَ وَلَحْمَ الْخِنزِيرِ وَمَا أُهِلَّ بِهِ لِغَيْرِ اللَّهِ ۖ فَمَنِ اضْطُرَّ غَيْرَ بَاغٍ وَلَا عَادٍ فَلَا إِثْمَ عَلَيْهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿١٧٣﴾

**«Чынлыкта, Ул сезгә** [шәргый юл белән ауда атылмаган яки суелмаган, үз үлеме белән] **үлгәнне,** [суйган вакытта чыккан] **канны, дуңгыз итен һәм Аллаһыдан** [тыш] **башка исем әйтелеп чалынганны гына харам кылды. Кем дә кем** [үзе кебек читен хәлдә калган бүтән бер кешегә] **бозыклык кылмыйча һәм** [гомерен коткару өчен җитәрлек] **чиктән ашмыйча,** [югарыда әйтелгән нәрсәләрнең кайсын да булса ашарга] **мәҗбүр булса, аңарда һич гөнаһ юк. Һичшиксез, Аллаһы —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:173

Әлхәмдүлилләһ, ит мәсьәләсендә мөселманнарның күбесе хәләл белән харам турында хәбәрдар. Ләкин бүгенге көндә безнең ашаган ризыгыбыз ит, яшелчә белән генә чикләнми. Кибеткә керсәк, нинди генә ризык юк! Кайберләренең исемнәрен дә, ничек кулланырга икәнен дә белмибез. Ә нәрсәдән эшләнгәне турында әйтеп тә торасы юк.

Кайбер ризыклар матур итеп ясалган, яхшы итеп төрелгән булырга мөмкин. Әмма аның составы күбебездә шик-шөбһә уята. Менә шушы шикле нәрсәләргә карата безгә ничек булырга соң? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу турыда нәрсә әйтте икән?

Әбү Габдуллаһ Ногман бине Бәшир радыяллаһу ганһе сөйләгән: «Мин Аллаһының Илчесенең болай дигәнен ишеттем: «Дөреслектә, хәләл дә билгеле, харам да билгеле. Алар арасында шикле нәрсәләр бар. Болар турында

күп кешеләрнең төгәл фикере юк. Шикледән сакланучы, динен һәм намусын саклау өчен, аннан котыла. Шикле белән шөгыльләнүче харамны кылуга да киләчәк. Чөнки ул тыюлык янында көтү көтеп, көтүе менә-менә тыюлыкка керүче көтүчегә тиң. Һәр патшаның шундый тыюлыгы бар. Ә Аллаһының тыюлыгы — Аның кешеләргә харам кылган нәрсәләре. Дөреслектә, кеше тәнендә бер ит кисәге бар. Ул яхшы булса, бөтен тәнне дә яхшы итә. Начар булса, бөтен тән дә яраксызга чыга. Ул ит кисәге — йөрәк».

Шулай ук икенче бер хәдистә хәбәр ителә: Пәйгамбәр галәйһиссәламнең оныгы Әбү Мөхәммәд Хәсән бине Гали радыяллаһу ганһүмә әйткән: «Мин Аллаһының Илчесенең болай дигәнен ишеттем: «Үзеңдә шик уяткан нәрсәне ташла, шик уятмаганына мөрәҗәгать ит».

Дин кардәшләрем, һәрберебезнең дә хәләл тормыш алып барасы, хәләл нигъмәтләр белән тукланасы килә. Ризык сайлаганда чикләрне үтмәс өчен, берничә киңәш бирәсем килә:

1. Беренчесе — ризыкның тышлыгында «Хәләл» тамгасы булганын эзләргә кирәк.

2. Икенчесе — шәхси хуҗалыктан ит алганда, Аллаһы исеме белән чалынганмы, дип белешергә кирәк. Кибеттән алган очракта, итнең «хәләл» тамгасы булып та, дуңгыз ите белән янәшә торса, монысы да шикле була.

3. Өченчесе — телефоныбызда хәләл ризыкны табарга ярдәм итә торган кушымта булдыру. Һәм ризыктагы штрихкодны кушымта аша тикшерү. (Мәсәлән: HalalGuide, Halal Food Scan, TagHalalFood, Halal Cheker.)

4. Дүртенчесе — Диния нәзарәтенең «Хәләл» комитетына мөрәҗәгать итеп, шик уяткан ризык турында сорау биреп, тикшерергә мөмкин. Шулай ук аларның сайтында (halalrt.com) хәләл-харам темасы буенча файдалы мәгълүмат алырга мөмкин.

Мөхтәрәм җәмәгать, вәгазебездә искә алынган аятьләрне, хәдисләрне, киңәшләрне ризык сайлаганда куллансак иде. Ашаган ризыгыбызга игътибар бирмәү дөрес түгел. Укыган намазларыбызның, кылган догаларыбызның

кабул булуы да ашаган ризыгыбызга бәйле. Тәнебезнең сәламәт булуы да, балаларыбызның динне яратуы да шушы ризыкка әйләнеп кайта.

Аллаһы Раббыбыз хәләлне хәләл итеп, харамны харам итеп күрергә насыйп итеп, шикле нәрсәләрне сайламаска гыйлем һәм көч бирсен. Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Риназ хәзрәт Малихов,*

*Актаныш районы Яңа Кормаш авылы мәчете имам-хатыйбы*

*14 ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-әүвәл аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Үзеңне алдарга ирек бирмә

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бүген без үзебезне, якыннарыбызны (бигрәк тә өлкән яшьтәгеләрне) финанс карақлардан (мошенниклардан) ничек сакларга мөмкин булуы турында сөйләшербез.

Бүген, ишетеп-күреп торабыз, мондый караклар торган саен көчлерәк була бара. Алар телефоннан шалтыраталар, мессенджерларда язалар, ялган сайтлар һәм рассылкалар булдыралар. Мондый һөҗүмнәргә каршы бигрәк тә өлкән яшьтәге кешеләр — әбиләребез, бабайларыбыз — көчсез. Сәбәбе дә бик гади: алар башка вакытта үскәннәр, элек өлкәннәрне алдау коточкыч гөнаһ саналган, шуңа күрә алар ят кешеләрнең сүзләренә бик тиз ышаналар.

Сбербанк бәяләвенчә, узган 2024 елда россиялеләрнең мошенниклардан күргән зыяны 295 млрд сум тәшкил иткән, ә 2025 елда бу сан 350 млрд сумга кадәр үсәргә мөмкин! Һәм илебездә финанс мошенникларның 60 % телефон ярдәмендә эш итүче караклар тәшкил итә икән. Шалтыраткач, алар еш кына үзләрен «банк хезмәткәре» яки «хокук саклау органнары хезмәткәре» дип атый. 70 % очракларда кешеләр аларга үзләре үк банк карталарының паролен хәбәр итә яки, «отышлы инвестицияләр» вәгъдәләренә, «блокировка счета» кебек куркытуларына ышанып, акчаларын күчерә. Шул рәвешле, караклар, курку һәм комсызлык кебек хис-кичерешләрдә уйнап, ялган юллар белән кешеләрнең акчаларын тартып алалар.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَكُم بَيْنَكُم بِالْبَاطِلِ إِلَّا أَن تَكُونَ تِجَارَةً عَن تَرَاضٍ مِّنكُمْ ۚ

**«Ий иман китерүчеләр! Үзара килешенгән** [һәм динебез тарафыннан рөхсәт ителгән] **сәүдә юлы белән булмаса,** [шәригать кушмаган риба, отышлы уен һәм талау кебек] **бозыклык белән арагызда** [бер-берегезнеке булган] **малларыгызны ашамагыз».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:29

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Мөселманның кулыннан да, теленнән дә башка кешеләр зыян күрмәс»[1]. Бу аять һәм хәдис намуслылыкның иманның нигезе булуын, ә караклыкның Ислам принципларына каршы килеп, алдау һәм гөнаһ булып торуын исебезгә төшерә.

«Дошманнан саклану өчен, аның кем булуын белергә кирәк» дип әйтәләр. Бүген интернет, телефон аша эш итүче караклар нинди хәйләләр кора соң? Аларның мондый киң таралган схемалары бар:

**1. Банк исеменнән шалтырату.** Кешене куркытып, алар: «Картагыздан акча салдырырга маташалар! Операцияне гамәлдән чыгару өчен, SMSтагы кодны әйтегез», — дияргә мөмкин. Ә чынлыкта бу код әлеге каракларның үзләренә акча урлау өчен кирәк.

**2. Туганың исеменнән шалтырату.** Мәсәлән, балагыз исеменнән шалтыратып: «Әни, мин һәлакәткә эләктем, ашыгыч рәвештә акча кирәк!» — дияргә мөмкиннәр. Мондый очракта бигрәк тә өлкән яшьтәгеләребез куркып калып, ярдәм итү өчен барысын да бирергә әзер.

**3. Мессенджерларда һәм социаль челтәрләрдә хатлар.** «Сезгә дәүләттән түләүләр каралган» яки «Сылтама буенча узыгыз һәм бүләк

[1] Имам әл-Бохари.

алырсыз» кебек хәбәрләр булырга мөмкин. Әмма бу сылтамалар ялган сайтларга китерә, анда исә банк карталарыгызның саннарын кертергә сорыйлар.

**4. Ялган социаль хезмәткәрләр.** Караклар өйгә килеп, үзләрен банк, пенсия фонды яки торак-коммуналь хуҗалык (ЖКХ) хезмәткәрләре дип таныштыралар. Кәгазьләргә кул куярга яки акчаны аларга «сакларга» биреп торырга тәкъдим итәргә мөмкиннәр.

Мондый каракларның ялганына бигрәк тә өлкән буын вәкилләре ышана, дидек. Ни өчен? Моның сәбәпләре түбәндәге булырга мөмкин:

— алар бер-береңә ышаныч һәм хөрмәттә тәрбияләнгән;

— техник яктан телефоннарны, интернетны аңлап бетермиләр;

— «дәүләт белән проблемалардан» куркалар һәм барысын да тизрәк төзәтергә омтылалар;

— караклар кешеләрнең курку, кызгану кебек хисләрендә уйныйлар.

Дин кардәшләрем, караклардан, ялганчылардан ничек сакланырга соң?

Беренчедән, истә тотарга кирәк: банклар үзләре беркайчан да шалтыратып код сорамыйлар. Моны шулай ук үзебезнең өлкән яшьтәге туганнарыбызга аңлатырга кирәк. Якыннарыгыз белән тормышта булган берничә мисалны тикшерегез.

Билгесез кешеләр шалтыратты икән, кардәшләрем, ашыкмагыз, кабаланмагыз, Аллаһыга сыенып, «әгузү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим» дип әйтегез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ашыгу — шайтаннан, ә тынычлык саклау — Аллаһыдан», — дип әйткән[1]. Шулай ук Расүлебез галәйһиссәлам: «Иман — ул тынычлык», — дип өйрәткән безне[2].

Икенчедән, «өч юк» дигән кагыйдәне тотарга киңәш итәләр. Ягъни:

1. Карта мәгълүматларын беркемгә дә әйтмәскә.

2. SMSтан кодларны беркемгә дә хәбәр итмәскә.

3. Акчаны беркемгә дә «саклау өчен» бирмәскә.

[1] Имам әт-Тирмизи.

[2] Имам Әхмәд.

Динебез безгә ышанып тапшырылган нәрсәләрне сакларга куша:

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَن تُؤَدُّوا الْأَمَانَاتِ إِلَىٰ أَهْلِهَا

**«Һичшиксез, Аллаһы сезгә әманәтләрне ияләренә кайтарырга әмер итә».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:58

Өченчедән, телефоннарыгызда шикле номерларны «кара исемлек»кә («черный список») кертегез, «защита от спама» кебек мөмкинлекләрне кушыгыз.

Дүртенчедән, гаилә әһелләрегез белән шартлы сүз (пароль, код) турында килешегез. Мәсәлән, әбигә оныгы исеменнән шалтыратып, акча сорыйлар. Ул: «Безнең шартлы сүзне әйт», — дигәч, караклар аны атый алмаячак. Әби шунда ук телефонны сүндереп куячак.

Бишенчедән, дин кардәшләрем, инде шикле булган бар мәгълүматны тикшерергә кирәк. Банктан SMS килде яки шалтыраттылармы? Сүндереп, кире үзегез банкның рәсми номерына шалтыратыгыз. Өлкәннәребез исә, ниндидер шикле шалтыратулар булса, башта балаларына шалтыратсын, ашыгып карар кабул итмәсеннәр. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзеңдә шик тудыра торган нәрсәләрне калдыр һәм шик тудырмый торганнарга мөрәҗәгать ит», — дигән[1].

Әйткәнемчә, дин кардәшләрем, динебездә ялганлау катгый тыелган. Ә кешеләрнең ышанучан булуы — бер сынаудыр. Коръәни Кәримдә әйтелгән:

فَاجْتَنِبُوا الرِّجْسَ مِنَ الْأَوْثَانِ وَاجْتَنِبُوا قَوْلَ الزُّورِ

**«Моннан соң нәҗес булган потлардан да сакланыгыз, ялган сүздән дә** [һәм ялган шаһитлыктан да] **качыгыз».**

«Әл-Хаҗ», 22:30

[1] Имам әт-Тирмизи.

Якыннарыбыз, туганнарыбыз — Аллаһыдан бирелгән әманәттер. Аларны ялганчылардан, караклардан саклау да безнең бурычыбыз һәм хәерле гамәл булып тора. Кеше өчен акчасын югалту — ул бит матди югалту гына түгел, ә сәламәтлегенә, тынычлыгына, ышанычына да зыян.

Йомгаклап әйткәндә, караклар куркыту, ашыктыру аша эш итәләр. Ә без белемебез, тынычлык саклау һәм гаиләбезнең ярдәме белән саклана алабыз.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

لَا يُكَلِّفُ اللَّهُ نَفْسًا إِلَّا وُسْعَهَا ۚ لَهَا مَا كَسَبَتْ وَعَلَيْهَا مَا اكْتَسَبَتْ ۗ

**«Аллаһы беркемгә дә көченнән килмәслек нәрсә йөкләми. Һәркемнең** [изге гамәлләр эшләп] **казанганы үз файдасына,** [начарлык] **кылганы да үз зарарына».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:286

Аллаһы Тәгалә мал-мөлкәтебезне саклап, өммәтебезне ялганнан сакласын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Йосыф хәзрәт Йосыпов,*

*РИИ мөгаллиме*

*21 ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Сәламәтлек — Аллаһыдан әманәт

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, вәгазебезне бүгенге көндә бик әһәмиятле һәм кирәкле булган тема — сәламәтлекне саклау мәсьәләсенә багышлыйсы килә. Халкыбызда «Аяк астына карап йөр!» дигән бик акыллы бер әйтем бар. Әлбәттә, безнең күз алдына юл, сукмак, тау-чокыр кебек нәрсәләр килеп баса. Әйтәсе сүзебез кыш айларында була торган бозлавык, кар өемнәре, түбәләрдә асылынып торган боз сөңгеләре, туңар-туңмас торган елга-күлләр турында.

Безнең бу фани дөньябыз төрле сынау-каршылыклардан тора. Табигать күренешләренең дә минутлар, сәгатьләр аралыгында төрле халәтләргә кереп, үзгәреп торганын беләбез. Адәм балалары да шул мохитнең, табигатьнең бер җан иясе бит. Һәрберебезнең бу тормышта бәхетле буласы, рәхәт яшисе, муллыкта тормыш итәсе килә. Сәламәт кеше малын табарга, хезмәт итәргә, тормышын матурайтырга, киләчәкне күтәргә ашыга. Өй бусагасын атлап чыгуга, һәрберебезне көндәлек мәшәкатьләр, сынаулар, көтелмәгән вакыйгалар саклап торганын уебызга да кертеп карамыйбыз кайчак.

Әйдәгез, бераз гына без дә бүген уйланып алыйк әле. Кышкы табигать, ап-ак карлы айлар безгә нинди сынаулар алып килә икән, һәм ул сынауларга без әзерме? Бу айларда төннәр озын, ә көннәр кыска була. Димәк, без, кешеләр, шул фасыл агымына яраклашып, үзебезнең план,

эш-гамәлләребезне дә дөрес, файдалы, сәламәтлеккә зыян килмәслек итеп җайларга тиешбез.

Әйе, үзенең кар-бураннары, бәскә төренгән агачлары, кар көртләре, шыгырдавык сукмаклары, энҗе карлары белән күңелләребезгә сафлык, аклык, пакьлек өсти бу айлар. Әмма кышкы айларның үзенә күрә усал яклары да бар. Уйлап, карап, игътибарлы булып йөрмәсәң, төрле хәвеф-хәтәрләргә дә очрарга мөмкин.

— Бозлавыклы юллар, аяк астына карап йөрмәсәң, төрле бәлаләргә китерергә мөмкин. Бу очракта юлларга игътибарлырак булу, аяк астына карап йөрү, саклык чаралары күрү сорала.

— Өем-өем кар көртләре дә юл һәлакәтләре китереп чыгарырга мөмкин.

— Елга-күлләрдәге боз өсләре бигрәк тә зур куркынычлык тудыра. Хәзерге кышларның җитәрлек дәрәҗәдә салкын булмавын, елгадагы бозларны тиешенчә туңдырып бетерә алмаганын беләбез. Бигрәк тә кыш башларында бу күренеш бик зур фаҗигаләргә китерергә мөмкин.

— Түбәләрдән төшкән өем-өем кар, боз сөңгеләре дә кеше язмышларын бик уңайсыз якка үзгәртергә мөмкин. Бу очракта саклык чараларын күрү, барасы юлыңа игътибарлы булу бигрәк тә кирәк.

— «Салкын үзәкләргә үтә» дигән әйтемне без әби-бабаларыбыздан ишетеп беләбез. Кышкы салкыннар, җил-бураннар, әлбәттә, үзәкләргә үтеп керерлек була. Шуңа күрә, кышкы зәмһәрир суыклар вакытында тиешенчә җылы киенеп, барасы юлларны күз алдында тотып, чараларын күрергә кирәк.

— Ашау-эчүгә дә зур әһәмият бирергә кирәк. Бигрәк тә кышкы суыклар вакытында иммунитетны күтәрү, тиешенчә витаминнарга бай ризыклар, яшелчәләр куллану зарур.

Сәламәтлекнең нигезе — дөрес туклану, әлбәттә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта бик күп киңәшләр биреп калдырган. Мөселманнар туклану мәсьәләсен ниндидер кирәксез, әһәмиятсез тема дип уйларга тиеш түгел. Киресенчә, бу хактагы хәдисләрне өйрәнергә, үсеп килгән яшь буынга өйрәтеп, аңлатып калдырырга тиешбез.

Кайвакыт без, адәм балалары, үз-үзебезгә шулкадәр дә нык ышанабыз, олылар сүзенә, киңәшләренә дә, Аллаһы Тәгаләдән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аркылы ирештерелгән хак сүзләргә дә колак салмыйбыз. Югыйсә сәламәтлек — Аллаһы тарафыннан бирелгән зур әманәт бит. Аны сатып та, кайтарып та, табып та булмый. Әманәтне саклау — һәрберебезнең изге бурычы.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кешеләр ике төрле нигъмәтнең кадерен белми. Берсе — вакыт, икенчесе — сәламәтлек», — дип әйткән булган. Аллаһы Тәгалә кешегә күркәм тәнен, сизгер җанын, акылын һәм иң зур нигъмәт булган саулыгын да биргән. Биреп кенә калмаган, аны саклау кагыйдәләрен Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм аркылы ирештергән.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтә:

...وَلَا تُلْقُوا بِأَيْدِيكُمْ إِلَى التَّهْلُكَةِ ۛ وَأَحْسِنُوا ۛ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ﴿١٩٥﴾

**«...Ләкин үз кулларыгыз белән** [үзегезне] **һәлакәткә ташламагыз һәм ихсан кылыгыз! Һичшиксез, Аллаһы игелек кылучыларны сөя!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:195

Бу аятьнең бер мәгънәсе шундый — безгә үз сәламәтлегебезгә зыян китермәскә, үзебезне һәлакәткә ташламаска кушыла.

Һәр адымыбыз, эшләгән гамәлләребез ниндидер бер мәгънәгә ия. Искә алган «Аяк астына карап йөр» дигән әйтем физик хәрәкәтне генә түгел, ә рухи халәтне дә күз алдында тота. Без алдагы эшләребезнең, әйтәсе сүзләребезнең, башкарыласы гамәлләребезнең нәтиҗәсен күз алдында тотып башкарырга тиешбез. Нәтиҗәле эш матур, файдалы, күркәм дә булырга тиеш.

Дөрес, без, адәм балалары, күп очракта язмышыбызны тәкъдиргә сылтарга яратабыз. Анысы шулай. Тәкъдир — Аллаһы Тәгалә кулында. Ләкин, Аллаһы Тәгалә безгә, башка җан ияләреннән аермалы буларак, аң, гакыл, зиһен биргән,

уйлап эш итәргә өйрәткән. «Атын урлаткач, абзарын бикләгән» дигән мәкаль бар халыкта. Уйланып, алдан күреп эшләнмәгән эш, әлбәттә, файда китерми. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә бер хәдисендә болай дигән бит: «(Әүвәл) Дөяңне бәйлә, ә аннан соң Аллаһыга тапшыр».

Нәрсә дә булса эшләргә телибез икән, аның ни рәвешле башкарылуы — бездән, сәбәбен без кылабыз, ә нәтиҗәсе Аллаһыдан тора. Янә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Саклан, аннары Аллаһыга тәвәккәл ит».

Димәк, мөселман өчен һәр өлкәдә, сәламәтлеге мәьәләсендә дә, тормышында корган планнарга килгәндә дә, хәвеф-хәтәрләрдән саклану, үзенә һәм якыннарына зыян китермәү, алдан әзерлек белән эш итү күркәм була.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: кыш айлары — ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән матур, саф, карлы айлар. Ләкин алар кешеләргә сынау өчен дә җибәрелгән. Чөнки бу суыклар — кешеләрнең физик яктан гына түгел, рухи яктан да тәрбиясен, күңел байлыгын, сабырлыгын сыный торган айлар. Без, мөселман кардәшләр, бер-беребезгә ярдәмләшеп, кул сузып, авыр чакларда ярдәм чаралары күрсәтеп көн итәргә тиешбез.

Нәтиҗә ясап, вәгазь башындагы фикерләрне туплап, шуны әйтә алам:

- Бозлавыкта сак булыгыз! Аяк астына карап, саклык белән йөрергә, тайгак урыннарда ашыкмыйча, кечкенә адымнар белән хәрәкәт итәргә, уңайлы аяк киеме кияргә кирәк.
- Түбәдән кар төшү куркынычы янаганда, биналар яныннан өскә карап үтәргә, кар, боз төшү ихтималы булган урыннардан ерак йөрергә.
- Салкын көннәрдә җылы киенергә. Вируслардан, өшеп авырудан сакланырга кирәк. Авыру кешеләр хәтта мәчетләргә килеп, башкаларны куркыныч астына куярга тиеш түгел, кардәшләрем.
- Ашау-эчүгә игътибар итәргә. Зарарлы булмаган, туклыклы ризык ашарга тырышырга. Туклану, спорт, чыныгу ярдәмендә иммунитетны күтәрергә мөмкин.

Газиз мөселман кардәшләрем! Сәламәтлекнең Аллаһының безгә биргән иң зур нигъмәтләренең берсе икәнен онытмыйк. Бу нигъмәтне саклыйк, хәвеф-хәтәрләрдән сакланыйк! Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә сәламәтлек, иминлек һәм бәрәкәт насыйп итсен! Барасы юлларыбызны якты, тигез, хәерле итсен! Эш-гамәлләребезне шатлык, куаныч китерерлек итеп башкарырга мөмкинлекләр бирсен! Аяк атлаган һәр мизгелебез хәерлегә булсын! Әмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Айрат хәзрәт Камалов,*

*Алексеевск районы Кыр Шонталасы авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*28 ноябрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Әниләребезгә итагать итик

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, безнең җаннарыбызга җан иңдерүче һәм җаннарыбызны алучы, безне ризыкландыручы, хәрәкәтләндерүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, олуглау-мактауларыбыз булса иде. Һәм дә Аның Расүле, иң күркәм әхлак мисалы булган остазыбыз Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Хөрмәтле җәмәгать, күбебезгә мәгълүм хәдисне искә төшерик: бервакыт сәхабәләрнең берсе Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән: «Мин кемгә күбрәк итагать итәргә тиешмен?» — дип сорый. Сөекле Пәйгамбәребез ни ди? «Әниеңә», — дип җавап кайтара. Сәхабә янә: «Ә аннан соң кемгә?» — дип сорый. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Әниеңә», — ди. Сәхабә тагын бер тапкыр: «Ә аннан соң, йә Расүлуллаһ?» — дип сорый. Җавабы — әниеңә. Инде сәхабә дүртенче мәртәбә соравын кабатлагач, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әтиеңә», — дип әйтә. Ягъни өч тапкыр рәттән Пәйгамбәребез һәркайсыбыз өчен иң кадерле, хөрмәткә һәм игътибарга иң лаек кешенең әниебез булуын ассызыклый.

Бүгенге вәгазебез дә әниләргә багышланган булыр. Безгә билгеле, Коръәндә һәм хәдисләрдә өч тапкыр кабатлау — ул без аеруча игътибар итәргә, һичшиксез үтәргә тиешле әйбернең күрсәткече. Ислам динендә әни

кешенең дәрәҗәсе һәм урыны аеруча югары. Ана 9 ай дәвамында безне карынында, йөрәге астында йөрткән, көчле авыртулар кичереп, бу дөньяга тудырган, аннан имезгән, ашаткан, караган, тәрбияләгән, көннәрен-төннәрен безгә багышлаган... Ана — балаларының тәрбиясенә иң күп вакыт сарыф иткән кеше, ул баласын иманлы, тәрбияле кеше итеп үстерим дип, зур тырышлык куя. Шул сәбәпле, әниеңне рәнҗетү, үпкәләтү — хәтта әтиеңне рәнҗетүгә караганда да зуррак гөнаһ.

«Ән-Ниса» сүрәсенең 36 нчы аятендә Аллаһы Раббыбыз безгә саваплы, хәерле гамәлләрне санап китә. Шуның бер өзеген генә китерәсем киләм:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا

«[Ий коллар!] **Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага игелек кылыгыз...»**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Күрәбез, Раббыбыз безгә ата-анага изгелек, игелек кылырга боера. Ә аларны рәнҗетү, авырлык китерү, борчуга салу, ярдәм күрсәтмәү — зур гөнаһ булып тора.

Риваятьләрдә килгәнчә, мәшһүр сәхабә хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе, әнисе янына килгән саен, аның ишеге янында тукталып, шулай дога кыла торган булган: «Әнием, сина иминлек телим! Сиңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм мәрхәмәте булсын! Мине кечкенә чагымда тәрбияләгәнең өчен Аллаһыдан сиңа рәхимлелек сорыймын».

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ۚ إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِندَكَ الْكِبَرَ أَحَدُهُمَا أَوْ كِلَاهُمَا فَلَا تَقُل لَّهُمَا أُفٍّ وَلَا تَنْهَرْهُمَا وَقُل لَّهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا ﴿٢٣﴾

**«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек** [кылырга] **әмер итте.** [Ий кеше!] **Аларның икесеннән берсе яки икесе дә синең яныңда картлыкка ирешсә, аларга** [канәгатьсезлек белдереп]**: «Уф!» — дип тә әйтмә.** [Сүз-гамәлләре сиңа ошамаса да] **Аларга кычкырма, күркәм сүз әйт».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23

Дин кардәшләрем, шушы аятькә игътибар итик. Аллаһы Раббыбыз әти-әниләребез бездән начар сүз ишетмәсеннәр, хәтта «уф» дип тә әйтмә ди. Ә бу бер кеше икенчесен рәнҗетергә мөмкин булган иң гади сүзләрнең берсе. Аларга кычкырма, ягъни аларга бернинди авырлык, начарлык китермә, аларга карата шәфкатьле, рәхмәтле бул, йомшак бул, дип боера Раббыбыз.

Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе шундый хәдис тапшырган: «Бер көнне, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм минбәргә күтәрелгәндә, өч мәртәбә «әмин» дигән. Сәхабәләр моның сәбәбен сорагач, ул: «Миңа Җәбраил галәйһиссәлам өч әйберне ирештерде. Шуңа мин «әмин» дип әйттем», — дигән. Болар: 1) берәү, Пәйгамбәр исемен ишетеп тә, аңа салаватсәлам ирештермәсә, шул кеше Кыямәт көнендә үкенечтә булыр (җәннәтнең исен дә сизмәс); 2) берәү, әти-әнисенең картлыгын күреп, аларга игелек күрсәтмәсә, шул Кыямәт көнендә үкенечтә булыр; 3) берәү, Рамазан ае килеп тә, Аллаһының ярлыкавын алмаса, шул җәннәттән ерак булыр».

Һәм шулай ук бер гыйбрәтле хикәя китерәсем килә. Картайган әни кеше үзенең улы, килене һәм оныгы белән яши башлый. Аның куллары калтырый, күзләре начар күрә, көчкә генә атлап йөри. Табын артына утыргач та, ризыгы идәнгә чәчелә, чәй ашъяулыкка түгелә. Киленнең моңа бик нык ачуы килә. Ир белән хатын, озак кына уйланганнан соң, бүлмәнең почмагында аңа аерым кечкенә өстәл куялар. Шуннан беркөнне дүрт яшьлек малаеның идәндә чыра һәм йомычкалар белән уйнап утырганын күргән әти кеше: «Нәрсә

эшлисең?» — дип сорый улыннан. Моңа каршы улы: «Мин әни белән сиңа кечкенә генә агач савытлар ясыйм. Мин үсеп җиткәч, сез почмакта шулардан ашый торган булырсыз», — ди.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хурлык, хурлык, хурлык», — дигән. Янындагы сәхабәләр: «Кемгә, йә Расүлуллаһ?» — дип сораган. Расүл Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Олы яшьтә булган ана яки атасының берсенә яки икесенә дә ирешеп, (аларны карап) җәннәткә керә алмаган кешегә (хурлык)», — дип җавап биргән. Кадерле җәмәгать, әгәр дә безнең әти-әниләребез әле исән икән, димәк, без бәхетле, чөнки без әле аларның догаларын, аларның ризалыгын ала алабыз. Аларның догалары һәм ризалыклары безнең өчен җәннәт ачкычы булырга мөмкин. Шуңа да Раббыбыз һәммәбезгә дә бу форсатны кулдан ычкындырмаска насыйп итсен!

Әлбәттә, күпме тырышсак та, әниләр алдындагы бурычны үтәп бетереп булмый. Без алар алдында гомер буена бурычлы. Алар вафат булганнан соң да, әти-әниебез турында онытырга тиеш түгелбез.

رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ ﴿٤١﴾

> **«Ий Раббыбыз!** [Колларга] **Хисап булачак көнне мине дә, ата-анамны да, барча мөэминнәрне дә ярлыка».**

«Ибраһим», 14:41

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул

тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илгиз хәзрәт Галимов,*

*Казанның «Галиев» мәчетенең икенче имамы*

*5 декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Аллаһының мәхлуклары турында уйлану

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмииин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык мактауларыбыз, хәмед-сәналәребез, шөкраналарыбыз — җирләрнең һәм күкләрнең Хуҗасы, галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Аллаһыга, шулай ук күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифәләребез, сәламнәребез, догаларыбыз Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм аның йорт әһеленә булсын! Аллаһы Раббыбызның әмерен үтим дип, пакьләнеп, тәһарәтләнеп, госелләнеп, мәчетләребезгә килгән кардәшләребез, сезгә Аллаһының сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын!

Тиз агучан тормыш, үзгәрүчән вәзгыять, җәмгыятьтәге рухи-әхлакый сыйфатларның түбән дәрәҗәдә булуы беркем өчен дә яңалык түгел. Ахырзаман алдыннан кешеләрнең шәхсиятләре белән мәшгуль булуы, Аллаһыны онытулары, Аның мәхлуклары турында фикер йөртмәве гадәти бер күренеш булып, җәмгыятьтә рухи бушлык барлыкка китерде. Бу бушлыкны адәм баласы күңел ачулар, булган малны кирәкмәгән җиргә тоту, популярлык һәм дан-шөһрәткә омтылу белән тутырмакчы була, әмма боларның берсе дә бу бушлыкны тутыра алмый. Яшәеш мәгънәсен эзләп, тирә-юньгә, барлык җанлы һәм җансыз нәрсәләргә карау, фикерләү, һәрнәрсәне бар кылучы Зат турында уйлау гына бу эчке бушлыкны, вакуумны тутырырга мөмкиндер.

Аллаһының мәхлуклары турында уйлау, фикерләү — ул элеккегеләрнең күркәм гадәте, яшәеш кагыйдәсе. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, еш кына кешеләрдән читләшеп, Хира куышлыгында җир һәм күкләрнең, галәмнәрнең төзелеше турында уйланган, Халикъ булучы Зат — Аллаһы Тәгалә — турында тирән фикер йөрткән.

Барлык кешеләргә дә тирән фикерләү сәләте бирелгән. Әгәр дә кеше бу сәләтне үстерсә, ул җәннәт белән бүләкләнәчәк. Локман Хәкимнең: «Аллаһының мәхлуклары турында фикер йөртү — җәннәткә илтүче юл», — дип әйтүе мәгълүм.

Без Галәмгә, төрле мәхлукларга, шулай ук үз-үзебезгә игътибар биреп, Коръәнне, хәдисләрне, галимнәрнең хикмәтле сүзләрен укып, фикер йөртергә тиешлебез. Аллаһы Раббүл-Гыйззә Үзенең Китабында күп урында адәмнәргә фикерләргә боера. Мәсәлән, «Әли Гыймран» сүрәсененең 190–191 нче аятьләрендә болай диелгән:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِّأُولِي الْأَلْبَابِ ﴿١٩٠﴾ الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَٰذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ ﴿١٩١﴾

«**Һичшиксез, күкләрнең һәм җирнең** [юктан] **яратылуында** [һәм аларда булган билгеләрдә]**, төн белән көннең бер-берсен алыштыруында** [сәламәт] **акыл ияләре өчен билгеләр бар** [ки, аларның һәрберсе Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген, гыйлем һәм кодрәтенең камиллеген күрсәтеп тора]**. Алар** [акыл ияләре] **аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһыны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында фикерлиләр: «Ий Раббыбыз! Син моны юкка яратмадың. Син** [юкка нәрсә дә

булса яратудан һәм юк-бар белән шөгыльләнүдән] **пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:190–191

Галәмнәрдәге һәрбер кисәкчек, һәрбер җанлы һәм җансыз затлар, әйберләр юкка гына яратылмады. Галәмнәрнең Хуҗасы булган Аллаһы Тәгалә моның турында бик күп урында Коръәни Кәримдә белдерә. Мисал өчен «Әгъля» сүрәсенең 2–5 нче аятьләренә күз салыйк:

الَّذِي خَلَقَ فَسَوَّىٰ ﴿٢﴾ وَالَّذِي قَدَّرَ فَهَدَىٰ ﴿٣﴾ وَالَّذِي أَخْرَجَ الْمَرْعَىٰ ﴿٤﴾ فَجَعَلَهُ غُثَاءً أَحْوَىٰ ﴿٥﴾

**«Ул** [һәрнәрсәне] **яратты һәм төзек итте. Ул** [барлыкларның җенесләрен, төрләрен үлчәп] **тәкъдир итте һәм** [яратылыш максатына] **юнәлдерде. Ул** [терлекләргә] **утлауларны чыгарды. Шуннан** [аның яшел хәленнән] **соң аны кап-кара чүпкә әйләндерә».**

«Әгъля / Иң өстен», 87:2–5

Һәрбер бар кылынган затның, һәрбер мәхлукның бу дөньяда үз максаты бар. Дәлил булып Хак Тәгаләнең «ән-Нәхл» сүрәсендәге 66–69 нчы аятьләрендәге сүзләре тора:

وَإِنَّ لَكُمْ فِي الْأَنْعَامِ لَعِبْرَةً ۖ نُّسْقِيكُم مِّمَّا فِي بُطُونِهِ مِن بَيْنِ فَرْثٍ وَدَمٍ لَّبَنًا خَالِصًا سَائِغًا لِّلشَّارِبِينَ ﴿٦٦﴾ وَمِن ثَمَرَاتِ النَّخِيلِ وَالْأَعْنَابِ تَتَّخِذُونَ مِنْهُ سَكَرًا وَرِزْقًا حَسَنًا ۗ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَةً لِّقَوْمٍ يَعْقِلُونَ ﴿٦٧﴾ وَأَوْحَىٰ رَبُّكَ إِلَى النَّحْلِ أَنِ اتَّخِذِي مِنَ الْجِبَالِ بُيُوتًا وَمِنَ الشَّجَرِ وَمِمَّا يَعْرِشُونَ ﴿٦٨﴾ ثُمَّ كُلِي مِن كُلِّ الثَّمَرَاتِ فَاسْلُكِي سُبُلَ رَبِّكِ ذُلُلًا ۚ

يَخْرُجُ مِن بُطُونِهَا شَرَابٌ مُّخْتَلِفٌ أَلْوَانُهُ فِيهِ شِفَاءٌ لِّلنَّاسِ ۗ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ
لَآيَةً لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٦٩﴾

**«Һичшиксез, терлектә сезнең өчен бик зур гыйбрәт бар. Без сезгә аларның эчендә тизәк белән кан арасында булган һәм эчүчеләр өчен тамактан җиңел үтә торган саф сөт эчерәбез. Хөрмә агачларының җимешләреннән һәм йөземнәрдән** [сыгып ясалган эчемлекләрдән] **шәраб һәм** [серкә, куе ширбәт, кайнатма, кипкән йөзем һәм төрле хәлләрендә кулланыла алган хөрмә төрләреннән] **яхшы бер ризык аласыз. Һичшиксез,** [фикер йөрткән] **акылияләре өчен боларда** [Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, чиксез гыйлеменә, чиксез кодрәтенә һәм тиңсез хикмәтенә күрсәткән бик зур] **билге бар.** [Расүлем!] **Синең Раббың бал кортына вәхи итте: «Тауларда, агачларда һәм** [кешеләр төзегән] **корылмаларда оялар кор. Шуннан соң, һәртөрле җимешләрдән туклан һәм Раббың җиңеләйткән юлларда йөр». Аларның карыннарыннан төрле төсле һәм кешеләр өчен шифа булган бер эчемлек чыга. Һичшиксез, боларда фикер йөртүчеләр өчен билге бар».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:66–69

Бу аятьләрне укып, аңлап, ихласланган адәм балалары үзләренең тормышларына икенче төрле карый башлый. Киткән кимчелекләре өчен гафу үтенә, калебен чистартуга юнәлтә. Тирә-юнь, табигатьне күзәтеп, кешенең фикерләү сәләте ныгый, йөрәгендәге илаһи инануы куәтләнә, гыйльми хәле үзгәрә.

Мәхлукатларның барысы да адәм баласы өчен хезмәт итә, файда китерә. Динебездә аларга мәрхәмәт күзе белән карау, зыян салмау тиешлеге Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сүзләрендә, галимнәрнең китапларында урын алуы һәркемгә дә мәгълүм. Гомумән, Ислам дине кешедә

күркәм әхлакны булдыруга зур урын бирә. Тәфәккүр (фикерләү) алымнарын кулланып, үзгәрүчән калебләрне тәрбияләргә, нәфесләрне адашудан, азгынлыктан коткарырга мөмкин. Бишер әл-Хәфи: «Кешеләр тиешле дәрәҗәдә Аллаһының бөеклеге, газәмәте, кодрәте турында фикер йөртсәләр, гөнаһ кылудан туктарлар иде», — дигән.

Дини тәгълиматларны артка куеп, үзен генә кайгырткан затлар һәм аларның балаларының бүгенге көндә үзләрен кыргыйлар кебек тотуы, мәче, эт яки башка мәхлукларны җәберләве, кыерсытуы замана шаукымы булып, интернет аша күрсәтелүе җәмгыятебезнең камил булмавын раслый. Төрле фәлсәфәче, атеистик карашлы кешеләр артыннан иярү, аларны тыңлау яхшылыкка илтмәве көн кебек ачык булса да, мөселманнар арасында да бу күңелсез хәлнең булуы безнең хакыйкый юлдан тайпылуыбызны күрсәтә.

Замана мөселманнары йортларында эт, мәче, тутый кошлар тота, аквариумда балыклар, төрле бөҗәк, сөйрәлүче затларны үрчетә. Шәригатьтә йорт хайваннары төркеменә кергән бу төр хайваннарны тоту, үрчетү турында нинди фикерләр бар соң? Аларга нинди мөнәсәбәт булырга тиеш?

Күпчелек галимнәр мәчене асрарга ярый дигән фикерне белдерәләр. Сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчесе булган; аның иң күп хәдисләрен тапшырган сәхабәсенең, күлмәк җиңендә мәче йөртү сәбәпле, кушаматы «Әбү Һөрайра» булган, ягъни «мәчеләрнең этисе». Аңа бу кушаматны Расүлуллаһ галәйһиссәлам үзе биргән.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакыт кече яшьтәге сәхаби балага: «Әй Әбү Гомайр! Ногайр ничек?» — дип сорау бирә. Ногайрның читлектә яшәүче кошчык булуын истә тотып, имам Әбү Хәнифә хәзрәтләре кошларны тотуны рөхсәт иткән.

Аквариумдагы балыкларга карап тору нәтиҗәсендә кешенең уйлау сәләте яхшыруын истә тотып, галимнәр балыкларны үрчетергә ярый дигән фикерне белдерә.

Ә кешеләрдә җирәнү хисләре уята торган бака, кәлтә, үрмәкүч, күсе һәм башкаларны үрчетү мәкруһ гамәлләрдән санала.

Йорт-җирендә кешегә зыян салырга мөмкин булган һәм Аллаһы тыйган затларны тоту рөхсәт ителми, бу төркемгә елан, хамелеон, чаян, дуңгыз кебек хайваннар керә.

Эт асрау мәсьәләсенә килгәндә, галимнәрнең төрле фикерләре бар. Кайберләре Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Эт булган йортка (фатирга) фәрештәләр керми», — дигән сүзләрен истә тотып, йортта эт тотарга рөхсәт итми. Кайберләре этне ишегалдын, каралты-кураны саклау нияте белән урамда тотарга рөхсәт итә. Хәзерге заман галимнәре сукыр кешеләрне ияртеп йөртүче махсус өйрәтелгән этләрне йортта тотарга рөхсәт бирә.

Коръәннең «әл-Маидә» сүрәсенең 4 нче аятендә болай диелә:

يَسْـَٔلُونَكَ مَاذَآ أُحِلَّ لَهُمْ ۖ قُلْ أُحِلَّ لَكُمُ ٱلطَّيِّبَٰتُ ۙ وَمَا عَلَّمْتُم مِّنَ ٱلْجَوَارِحِ مُكَلِّبِينَ تُعَلِّمُونَهُنَّ مِمَّا عَلَّمَكُمُ ٱللَّهُ ۖ فَكُلُوا۟ مِمَّآ أَمْسَكْنَ عَلَيْكُمْ وَٱذْكُرُوا۟ ٱسْمَ ٱللَّهِ عَلَيْهِ ۖ وَٱتَّقُوا۟ ٱللَّهَ ۚ إِنَّ ٱللَّهَ سَرِيعُ ٱلْحِسَابِ ﴿٤﴾

«[Расүлем!] **Синнән үзләренә нәрсәнең хәләл кылынганлыгын сорыйлар. Әйт: «**[Җирәнмәгән] **Бөтен пакь нәрсәләр сезгә хәләл кылынды. Аллаһының сезгә** [аучылык белән бәйле] **белдергән нәрсәләреннән сез этләр кебек ияләштереп өйрәткән җәнлекләр** [үзләре ашамыйча] **сезгә дип тотканнарны** [киекләрне] **ашагыз һәм алар өстендә Аллаһының исемен телгә алыгыз.** [Харамнарга төшмәс өчен] **Аллаһыдан куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһы хисапны бик тиз тота».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:4

Йорт яки ерткыч хайван булсынмы, аны сәбәпсез җәберләргә, үтерергә ярамый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Җәһәннәмгә эләккән бер хатын-кыз үзенең мәчесен бикләп, ач тотып, үтергәне сәбәпле газаплана», — дигән. Шуңа да йорт хайваннарын тотучылар, тәкәбберлектән сакланып, Аллаһының мәхлукларын тиешле дәрәҗәдә карасыннар, аларга зыян салудан курыксыннар, Кыямәт көнендә һәрбер гамәл өчен җавап бирү бар икәнен онытмасыннар иде. Аллаһы Тәгалә бернәрсәне дә болай гына бар кылмаган. Адәм баласы моның турында гел фикер йөртсен иде.

Аллаһы Раббыбыз һәрбарчабызга Үзенең мәрхәмәтен ирештерсен, яраткан бәндәләреннән кылсын, мәхлуклары турында фикерләргә акыл һәм зиһен бирсен, зирәклек һәм хикмәт белән Үзе биргән дәресләрне аңларга насыйп итсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рәис хәзрәт Нигъмәтҗанов,*

*Апас районы Кормаш авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*12 декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Никахка әзерләнүнең әһәмияте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Раббыбыз бу дөньяда бар җан ияләрен, шул исәптән кешеләрне дә, пар-пар итеп яратты һәм күңелләренә бер-берләренә тартылу хисе салды. Әмма, башка мәхлуклардан аермалы буларак, кешеләрне акыл белән дә зиннәтләде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾

> **«Бергә яшәвегез өчен үзләрегездән сезнең өчен хатыннар яратуы һәм арагызда сөю** [нәтиҗәсендә хасил булган бердәмлек] **белән бер шәфкать** [чарасы булган бала] **бирүе дә — Аның билгеләреннән. Һичшиксез, монда уйлаганнар өчен** [аңлатылып бетерә алмаслык дәрәҗәдә зур] **билгеләр бар».**

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Уйлап, фикерләп карасак, бу безнең өчен нинди зур нигъмәт. Раббыбыз, ир белән хатын арасындагы килеп чыккан хисләрне бер тәртипкә салу өчен, мөнәсәбәтләрен хәләл итү өчен, никахлашуны әмер итте.

وَأَنكِحُوا الْأَيَامَىٰ مِنكُمْ وَالصَّالِحِينَ مِنْ عِبَادِكُمْ وَإِمَائِكُمْ ۚ إِن يَكُونُوا فُقَرَاءَ يُغْنِهِمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ ۗ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ ﴿٣٢﴾

**«Арагыздан буйдакларны, колларыгыздан һәм җарияләрегездән иман һәм тәкъвалык иясе булган кешеләрне никахлагыз. Әгәр алар фәкыйрь булсалар, Аллаһы аларны Үз рәхмәтеннән** [ризык белән] **бай итәчәк. Аллаһы** [белеме һәм мәрхәмәте мәңгелек киң булган] **һәрнәрсәне Чолгап алучы,** [һәрнәрсәне] **Белүче».**

«Ән-Нур», 24:32

Никах — ул ир белән хатын арасындагы вәгъдәләшү, килешү, сүз куешу. Бу килешүдә алар, бергә яшәп, хуҗалык алып барып, балалар тәрбияләп һәм башка эшләрне башкарып, гомерләренең ахырына кадәр бергә булырга вәгъдә итәләр. Әлбәттә, бу бик җитди килешү. Шуңа күрә бу адымны ясарга ике як та бик нык әзерләнергә тиеш. Элекке заманда егет белән кызның әти-әнисе булачак килен-кияүләренең нәселенә, чыгышына, тәрбиясенә нык игътибар биргәннәр.

Хәзерге вакытта яшьләр никахлашуга бик җиңел карый башладылар. Беренчел хисләргә ияреп, тирәнтен уйламыйча, гаилә корырга ашыгалар. Шуның нәтиҗәсендә, статистика буенча, яшь гаиләләрнең яртысыннан артыгы аерылышалар. Бу аянычлы хәлнең нигезендә, минемчә, яшьләрнең гаилә тормышына җитди рәвештә әзерләнмәве тора.

Әлбәттә, гаиләнең тотрыклы булуы материаль якка да нык бәйләнгән. Көнкүреш мәсьәләләре алгы планга чыга. Дөньялыкка зур игътибар бирү, рухи ярлылык гаилә тормышына комачаулый башлый. Бу очракта рухи әзерлек беренчел булып кала. Шуңа күрә яшьләребезгә ныклы дини тәрбия бирү атаананың төп бурычы булып тора. Мәсәлән, тормышта төрле мәшәкатьләр, проблемалар килеп чыккач, аларны чишү өчен ярдәмне кешеләрдән эзли башлыйбыз. Галәмнәрнең Хуҗасы булган Раббыбызны арткы планга

калдырабыз. Ә бит без бөтен нәрсәне иң беренче Аннан сорарга тиеш. Бу инде иманыбызның зәгыйфь булуын күрсәтә.

Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә әйтте:

وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ ۚ إِنَّ الَّذِينَ يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِي سَيَدْخُلُونَ جَهَنَّمَ دَاخِرِينَ ﴿٦٠﴾

«[Ий кешеләр!] **Раббыгыз әйтте: «Миңа дога** [һәм гыйбадәт] **кылыгыз,** [сораганнарыгызны үтәп] **сезгә җавап** [һәм савап] **бирим. Һичшиксез, Миңа коллык итүдән тәкәбберләнгән кешеләр җәһәннәмгә китәчәкләр».**

«Гафир / Гафу итүче», 40:60

Иң беренче Раббыбыздан сорасак, ахыры хәерле булыр. Шуның өчен гаилә корырга ниятләгән яшьләребезгә истихара намазы укырга киңәш итик. «Йә Раббым, бу никах хәерле булса, эшебезне җиңеләйт, хәерле булмаса, киртә куй. Син барысын да Белүче!» — дип сорасыннар. Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылу иң беренче урында булырга тиеш.

وَمَن يَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ فَهُوَ حَسْبُهُ ۚ إِنَّ اللَّهَ بَالِغُ أَمْرِهِ ۚ قَدْ جَعَلَ اللَّهُ لِكُلِّ شَيْءٍ قَدْرًا ﴿٣﴾

**«... Кем дә кем Аллаһыга тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә. Һичшиксез, Аллаһы һәрнәрсә өчен** [ул әле бар булганчы] **бер үлчәм куйган».**

«Әт-Талак», 65:3

Шулай ук үзеңнең булачак парыңның динле булуына зур әһәмият бирергә кирәк. Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен тапшырган: «Хатын-кызга дүрт нәрсә аркасында өйләнәләр: малы, нәсәбе, матурлыгы, дине. Һәм сез,

зыян күрмәс өчен, динле булганын сайлагыз»[1]. Бу хәдис ир-егетләр турында булса да, хатын-кызларга да кагыла. Бары тик нык иманлы кеше генә гаилә тормышында хәләл җефетенә ышанычлы терәк, балаларына яхшы үрнәк була ала.

Булачак ир белән хатынның үз хокукларын һәм бурычларын да яхшы белүе бик мөһим. Бу гаиләнең нык булуына бик ярдәм итә, килеп чыккан аңлашылмаучанлыкларны тынычрак хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Әмма тормышта төрле хәлләр булып тора. Кайчандыр бер-берләренә карата булган хисләр суынырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә бу хәлдән дә чыгу юлын күрсәткән. Ул — талак кылу. Һәм бу эштә Раббыбыз гадел булырга әмер итә, катгый таләпләре белән Ул ир ягын да, хатын ягын да һәм балаларны да кайгырта. Бу эштә хатыннарның хокукларын бозудан, шуның белән үзебезгә дә золым кылудан безне кисәтә.

يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ إِذَا طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ فَطَلِّقُوهُنَّ لِعِدَّتِهِنَّ وَأَحْصُوا الْعِدَّةَ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ رَبَّكُمْ ۖ لَا تُخْرِجُوهُنَّ مِن بُيُوتِهِنَّ وَلَا يَخْرُجْنَ إِلَّا أَن يَأْتِينَ بِفَاحِشَةٍ مُّبَيِّنَةٍ ۚ وَتِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ ۚ وَمَن يَتَعَدَّ حُدُودَ اللَّهِ فَقَدْ ظَلَمَ نَفْسَهُ ۚ لَا تَدْرِي لَعَلَّ اللَّهَ يُحْدِثُ بَعْدَ ذَٰلِكَ أَمْرًا ﴿١﴾

**«Ий Нәби! Хатыннарны аерган чакта, аларны** [өч күрем вакыты булган] **гыйддәтләреннән соң** [пакь хәлләрендә һәм алар белән якынлык кылмыйча] **аерыгыз һәм гыйддәтне** [һич киметмичә] **санагыз. Раббыгыз булган Аллаһыдан куркыгыз** [гыйддәт вакытын озайтып, аларга зарар китермәгез]. [Зина һәм караклык кебек] **Ап-ачык кабахәт бернәрсә кылмасалар,** [үзләренең милекләре кебек булган] **өйләреннән** [гыйддәтләре тулганчы] **аларны кумагыз, алар да чыкмасыннар. Болар — Аллаһының чикләре. Кем дә кем Аллаһының**

[1] Әл-Бохари, 4802.

**чикләреннән чыкса, алар —** [үз-үзләренә] **золым кылучылар.** [Ий хатынын аерырга ниятләгән кеше!] **Син белмисең, бәлки, Аллаһы моның артыннан бер хәл чыгарып куяр** [да, нәфрәтне — сөюгә, күрәсе килмәүне тартылуга үзгәртер, ул чакта сез бик үкенерсез һәм бер-берегезгә кайтырсыз]**».**

«Әт-Талак», 65:1

Хәзерге заманда талак кылуга да җиңел карый башладылар. Ә бит монда да шаригать хөкемнәре бар. Бер талак әйткәннән соң, өч күрем вакыты үткәнче ирнең хатынын кайтарырга хокукы бар. Бу чор «гыйддә чоры» дип атала. Өч талак кылган хатыныңны кире кайтарырга теләсәң, ул башка иргә кияүгә чыгып, аерылгач кына моны эшли аласың. Хатыннар да, ирләреннән аерылсалар, я ирләре үлсә, билгеләнгән гыйддә вакыты үтмичә, кабат кияүгә чыга алмыйлар.

Кардәшләрем, бу гаилә тормышы буенча дини гыйлемнәрнең әле бик аз өлеше генә. Гаилә корыр алдыннан яшьләребезгә Ислам дине нигезләре белән танышырга, имам-хатыйб, абыстайлар белән киңәшләшергә тәкъдим итәр идем.

Гомумән алганда, бу дөнья тормышы Раббыбызның тәкъдире буенча барганын һәрвакыт истә тоту яшәешебезне аңлауны җиңеләйтә. Бу, әлбәттә, гаилә тормышына да кагыла. Үзеңә язган хәләл җефетең белән язмышның барча сынауларын да сабырлык белән үтеп, бер-береңә юл биреп, бер-береңнең хокукларын хөрмәт итеп яши алсак иде. Аллаһы Раббыбыздан яшь гаиләләргә ныклы иман, күркәм сабырлыклар сорыйбыз.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә

дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Муса хәзрәт Шәйдуллов,*

*Чүпрәле районы Кече Чынлы авылының Үзәк мәчете имам-хатыйбы*

*19 декабрь вәгазе,*

*җөмәдәл-ахыр аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Коръәндә сөйләнгән пәйгамбәрләр тарихының хикмәте нәрсәдә?

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Коръәни Кәрим — Аллаһы Тәгаләнең Сүзе, мөэмин мөселманнар өчен юл күрсәткеч. Әгәр без Коръәндәге бар аятьләрне тикшереп чыксак, аларның күпчелеген (75 %) элекке чорда яшәгән өммәтләр, халыклар турындагы гыйбрәтле хикәяләр тәшкил итүен күрербез. Бүгенге кайбер галимнәр Коръәндә китерелгән кыйссаларны санап караган, һәм 142 гә якын төрле кыйсса китерелүен әйткән.

Әлбәттә, Коръәндәге кыйссаларның күбесе Аллаһының пәйгамбәрләре белән бәйле. Барлыгы җир йөзенә 124 меңгә якын пәйгамбәр (яки нәби) җибәрелгән була. Аларның 313 расүл дә була. Расүл — ул шулай ук пәйгамбәр, әмма ул пәйгамбәрдән аерыла: аңа Аллаһыдан яңа шәригать бирелә һәм ул кешеләрне шул яңа шәригатькә чакыра. Пәйгамбәрләргә ышану — иман нигезләренең берсе. Алар — иң күркәм мәхлуклар, һәм аларга карап без тормышыбызны төзәтә алабыз. Шуңа күрә алар турындагы кыйссаларны өйрәнү, эчтәлеген белү бик мөһим. Аллаһы Тәгаләнең аларны Коръәни Кәримдә искә алуында бик күп хикмәтләр бар.

Беренчедән, пәйгамбәрләр тарихы безнең өчен үгет-нәсыйхәт булып тора. Кеше үз табигате буенча кем беләндер сокланучан, үзенә кемнедер

үрнәк итеп алучан була. Ә гөнаһсыз пәйгамбәрләр — ияргү өчен иң күркәм үрнәк, һәм без аларның тормышын үзебезгә сабак итәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә болай дигән:

لَقَدْ كَانَ فِي قَصَصِهِمْ عِبْرَةٌ لِأُولِي الْأَلْبَابِ ۗ مَا كَانَ حَدِيثًا يُفْتَرَىٰ وَلَٰكِنْ تَصْدِيقَ الَّذِي بَيْنَ يَدَيْهِ وَتَفْصِيلَ كُلِّ شَيْءٍ وَهُدًى وَرَحْمَةً لِقَوْمٍ يُؤْمِنُونَ

«**Аларның кыйссаларында** [шикләнүләрдән тәмам ерак булган] **акыл ияләре өчен** [зур] **гыйбрәт бар. Бу** [Коръән] **— уйдырма була ала торган бер хәбәр түгел. Әмма** [ул] **үзеннән алдагыларны раслау,** [дингә кагылышлы] **һәрбер нәрсәнең аңлатмасы —** [хакыйкый] **иман китергән кешеләргә** [адашудан коткаручы] **бер һидаять һәм** [ике җиһан бәхетенә илткән] **бер рәхмәт** [буларак иңдерелде]**».**

«Йосыф», 12:111

Башка аятьтә Аллаһы Раббыбыз әйтә:

فَاقْصُصِ الْقَصَصَ لَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

«**Бу кыйссаны сөйләп тор, — бәлки, алар уйланырлар** [һәм бу кешенең хәленә төшмәсләр]**».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:176

Булган вакыйгаларны, кыйссаларны өйрәнеп, нәтиҗәләр чыгарып, без бүгенге көндә азрак хаталар кыла алабыз. Юкка гына «тарих — тормыш укытучысы» дип әйтмиләр бит. Бер хикмәт иясе: «Тарих өйрәнергә теләмәүчеләрне өйрәтә», — дип әйткән. Һәм борынгы чорда яшәгән өммәтләрнең, пәйгамбәрләрнең тарихы безгә тормышны, Раббыбызның кануннарын яхшырак аңларга ярдәм итә, чөнки тарих ул кабатланып тора.

Икенчедән, пәйгамбәрләр турындагы кыйссаларның хикмәте шунда — алар Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлегенә бер дәлил булып тора. Чөнки, билгеле булганча, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм укый-яза белмәгән, ул борынгы халыклар тарихын белмәгән. Шулай итеп, Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам кыйссалар сөйләгәндә, халык моның Аллаһыдан иңдерелгән вәхи булуын аңлаган.

ذَٰلِكَ مِنْ أَنْبَاءِ الْغَيْبِ نُوحِيهِ إِلَيْكَ

**«Бу – Без сиңа вәхи иткән гаиб хәбәрләрдән».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:44

Хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителә: яһүдиләрнең галимнәре мөшрикләргә: «Мөхәммәдтән Ягъкубның гаиләсе ни өчен Шамнан Мисырга күченгәнен һәм Йосыф кыйссасы турында сорагыз», — дип әйткәннәр. Моңа җавап буларак «Йосыф» сүрәсе иңдерелә. Ул чорда гарәпләргә Тәүратта китерелгән кыйссалар таныш булмый, аларга бу тарих билгеле булмый; ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, уку-язу белмәгәнлектән, аларны кайдандыр укый алмаган.

Аллаһы Тәгалә бу хакта әйтә:

نَحْنُ نَقُصُّ عَلَيْكَ أَحْسَنَ الْقَصَصِ بِمَا أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ هَٰذَا الْقُرْآنَ وَإِنْ كُنْتَ مِنْ قَبْلِهِ لَمِنَ الْغَافِلِينَ

**«Без сиңа бу Коръәнне вәхи итүебез сәбәбе илә иң яхшы хикәяләү** [юлы] **белән белдерәбез. Моңа** [вәхи килгәнчегә] **кадәр исә син хәбәрсез кешеләрдән идең».**

«Йосыф», 12:3

Өченчедән, Аллаһы Тәгалә бу кыйссалар аша шулай ук Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә көч биргән, пәйгамбәрләрнең юлы сынау һәм

кыенлыкларга бай булуын күрсәткән. Үзенә кадәр килгән пәйгамбәрләрнең нинди сынаулар үтүен күрү сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәм иткән.

Аллаһы Тәгалә болай дигән:

وَكُلًّا نَقُصُّ عَلَيْكَ مِنْ أَنْبَاءِ الرُّسُلِ مَا نُثَبِّتُ بِهِ فُؤَادَكَ ۚ وَجَاءَكَ فِي هَٰذِهِ الْحَقُّ وَمَوْعِظَةٌ وَذِكْرَىٰ لِلْمُؤْمِنِينَ

«[Өммәтләре тарафыннан кире кагылып, бик зур җәфалар чиккән кадерле] **Пәйгамбәрләр турындагы хәбәрләрдән һәрберен синең күңелеңне** [сабырлык белән тотыру һәм] **куәтләү өчен сөйлибез. Боларда сиңа хак** [мәгълүмат] **һәм вәгазь, кешеләр өчен исә бер үгет килде».**

«Һуд», 11:120

Мәсәлән, Йосыф галәйһиссәлам кыйссасы мөшрикләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләргә бойкот игълан иткән вакытта иңдерелгән була. Мөгаен, бу кыйсса аларның күңелләрен юаткандыр. Чөнки, Йосыф галәйһиссәламне бертуган кардәшләре ничек ташлаган, хыянәт иткән булса, мөселманнарга да үз туганнары, күршеләре шулай бойкот игълан итә. Шуңа да Ибне Гата рахимәһуллаһи: «Кайгыга төшүче «Йосыф» сүрәсен ишетсә, һичшиксез җиңеллек тоячак», — дип әйткән була.

Шулай ук пәйгамбәрләр турындагы кыйссаларның бер хикмәте — һәр кеше үз тормышы өчен бер дәрес, гыйбрәт ала ала:

— әгәр син хаким, түрә икәнсең, синең өчен Сөләйман галәйһиссәламдә иң күркәм үрнәк бар, ул бар дөньяның хөкемдары булган;

— әгәр син мәгърифәтчелек яки җәмәгать өчен башка файдалы эш белән шөгыльләнәсең икән, син үзең өчен Нух галәйһиссәлам тормышыннан күп файдалар табарсың;

— әгәр ниндидер кыенлыклар, авырулар аша үтәсең икән, Әюб галәйһиссәламдә сабырлык һәм ныклык үрнәге күрерсең;

— әгәр син фәкыйрьлек белән сыналсаң, Гайсә галәйһиссәлам күркәм үрнәк булыр.

Шул рәвешле, пәйгамбәрләр кыйссаларын өйрәнүдә күп файда һәм хикмәтләр барлыгын күрәбез. Шуңа күрә бар гаиләләребез белән иң күркәм кешеләрнең тормышларын өйрәнергә омтылыйк.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*26 декабрь вәгазе,*

*раҗәб аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Гөнаһларның башы — хәмер

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактауларыбыз галәмнәрне барлыкка китереп, аннан соң да бер генә мизгелгә дә Үзенең игътибарыннан калдырмаган, кешелек, җәнлек һәм башка бик күптөрле мәхлукатны барлыкка китереп, тәрбия кылып торган Раббыбыз Аллаһыга булсын! Шулай ук әйткән салаватларыбыз сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага барып ирешсен!

Хөрмәтле җәмәгать, Бөек Раббыбыз Аллаһы Сөбеханә вә Тәгалә «әл-Маидә» сүрәсенең 90 нчы аятендә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالْأَنصَابُ وَالْأَزْلَامُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٩٠﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Хәмер, отышлы уен,** [табыну өчен] **тораташлар һәм фал уклары — шайтан гамәлләреннән булган шакшылык. Болардан ерак торыгыз, бәлки, сез** [Аллаһының газабыннан котылып] **уңышка ирешерсез».**

«Әл-Маидә / Табын», 5:90

Һәм бүген без әлеге аятьтә искә алынган олы гөнаһларның берсе — хәмер — турында сөйләшеп китәрбез. Әлеге гаиләләрне таркатучы, адәм баласын кешелек сыйфатыннан чыгаручы гөнаһ — хәмер эчү — динебездә зур

гөнаһлар исемлегендә тора. Моңа дәлил булып Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисе тора. Ул: «Аллаһы Тәгалә хәмерне, аны эчүчене, аны салып бирүчене, аны сатучыны, сатып алучыны, аны ясаучыны, аны ясатучыны, аны күтәреп йөрүчене һәм аны китерткән кешене дә ләгънәт кылды», — ди.

Ягъни, хәмерне кулланмасаң да, әмма аны җитештерсәң, сатсаң, берәр кемгә алып килеп бирсәң, хәмер булган табында катнашсаң, Аллаһы Тәгаләнең ләгънәтенә дучар буласың дигән сүз. Әлбәттә, үзен мөселман дип санаучы кеше мондый эшләр белән шөгыльләнмәс. Нәрсә соң ул Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте? Ләгънәт кылынган кешенең бер гыйбадәте дә, изгелеге дә кабул булмас, ул кешегә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешмәс, тормышында бәрәкәте булмас, җанында тынычлык булмас, гәрчә ул чын ихласлыгы белән гөнаһын танып, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кылып, һәм иң мөһиме — әлеге гөнаһка кире кайтмаса, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән ул ләгънәттән котылыр.

Исерткеч эчемлекләр һәр вакытта да, һәр җәмгыятьтә дә күп мәшәкатьләр тудыра торган булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында да гарәпләр хәмер куллана торган булалар. Һәм кайбер сәхабәләр, Ислам динен кабул иткән булсалар да, әлеге эчемлектән арына алмаган. Аллаһы Тәгалә — бөек хикмәт Иясе! Ул хәмерне кырт кисеп тыймый, ә әкренләп, җайлап кына сәхабәләргә әлеге гамәлнең аларга хәерлелек китермәвен җиткерә.

Мәшһүр галимебез Имам Әбү Хәмид әл-Газәли үзенең «Мүкяшәфәтүлкулүб» китабында хәмер гөнаһы турында түбәндәгеләрне яза:

«Аллаһы Тәгалә исерткеч эчемлекләр турында өч аять иңдергән. Беренчесе әлеге аять:

يَسْأَلُونَكَ عَنِ الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ ۖ قُلْ فِيهِمَا إِثْمٌ كَبِيرٌ وَمَنَافِعُ لِلنَّاسِ وَإِثْمُهُمَا أَكْبَرُ مِن نَّفْعِهِمَا ۗ وَيَسْأَلُونَكَ مَاذَا يُنفِقُونَ قُلِ الْعَفْوَ ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمُ الْآيَاتِ لَعَلَّكُمْ تَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١٩﴾

«[Расүлем!] **Синнән хәмер** [һәм акылны томалый торган башка нәрсәләр] **һәм отышлы уеннар** [кебек малга зарар китерә торган нәрсәләр] **турында** [Аллаһы Тәгаләнең хөкемен] **сорыйлар. Әйт: «Аларның икесендә дә** [сүз көрәштерү, бозыклык һәм ялган кебек афәтләр, зиһенне чуалту кебек зарарлар булганлыктан, куллануда] **зур гөнаһ, әмма** [икесендә дә] **кешеләр өчен** [кәеф һәм рәхәтлек, кыюландыру һәм җиңел акча эшләү кебек аз гына] **файда да бар. Әмма һәр икесендә дә гөнаһ, файдаларына караганда,** [бермә-бер] **күбрәк».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:219

Һәм элек хәмер кулланган кайбер мөселманнар, әлеге аять иңдерелгәч, аннан баш тарткан. Соңрак бер исерек кеше намаз укыганда хата җибәргән (ялгыш сүзләр әйткән). Аллаһы Тәгаләдән бу аять иңдерелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَقْرَبُوا الصَّلَاةَ وَأَنتُمْ سُكَارَىٰ حَتَّىٰ تَعْلَمُوا مَا تَقُولُونَ وَلَا جُنُبًا إِلَّا عَابِرِي سَبِيلٍ حَتَّىٰ تَغْتَسِلُوا ۚ

**«Ий иман китерүчеләр! Исерек килеш, ни әйткәнегезне белә башлаганчы, һәм, госелсез хәлдә, госел коенмыйча, юлда барган кешеләр булмасагыз гына, намазга якын килмәгез».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:43

Моннан соң да кайбер мөселманнар хәмердән баш тарткан, ә кайберләре эчүләрен дәвам иткән. Һәм шулай түбәндәге вакыйгага кадәр дәвам иткән. Бер сәхабә, хәмер эчкәч, Габдрахман бине Гауф радыяллаһу ганһегә суккан. Бу

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ирешкәч, ул, бик ачуланып, әлеге сәхабә янына килеп, кулында булган әйбер белән аңа суккан. Сәхабә: «Аллаһының һәм Аның Расүленең ачуыннан Аллаһыга сыенамын!» — дип әйткән. Шул вакытта әлеге аять иңдерелгән:

إِنَّمَا يُرِيدُ الشَّيْطَانُ أَن يُوقِعَ بَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةَ وَالْبَغْضَاءَ فِي الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ
وَيَصُدَّكُمْ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَعَنِ الصَّلَاةِ ۖ فَهَلْ أَنتُم مُّنتَهُونَ ﴿٩١﴾

> **«Шайтан хәмер** [һәм исерткеч эчемлекләр] **һәм отышлы уен белән арагызга дошманлык һәм нәфрәт салырга, сезне Аллаһыны искә алудан һәм намаздан тайпылдырырга тели. Сез** [болардан] **ваз кичмисезме әллә?»**

«Әл-Маидә / Табын», 5:91

Шул вакыттан әлеге аять белән хәмер эчү катгый тыела. Исерткеч эчемлекләрне тыйган хәдисләр дә күп. Мәсәлән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Исерткеч эчемлекләр эчәргә күнеккән кеше җәннәткә кермәс».

Башка хәдистә: «Бу тормышта хәмер эчәргә җыелган кешеләрне Аллаһы Тәгалә һичшиксез җәһәннәмдә җыячак. Һәм алар бер-берсен: «Сиңа Аллаһының рәхмәте булмасын! Синең аркада мин монда эләктем!» — сүзләре белән гаепләячәк. Һәм һәрберсе шул сүзләрне кабатлаячак», — диелгән.

«Дөреслектә, бар исертә торган матдәләр тыелган һәм бар исерткеч эчемлекләр тыелган».

Күрәбез, газиз дин кардәшләрем, динебездә хәмерне тыя торган дәлилләр бик күп, шуңа да карамастан, «әз күләмдә хәмер сәламәтлеккә файдалы» дип бәхәскә керүче кешеләр табыла. Андый бәндәләргә дә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтендә дәлил бар. Мөэминнәрнең анасы Өмме Сәләмә радыяллаһу ганһәдән тапшыралар: «Кызларымның берсе авыргач, мин аңа хөрмә җимешләреннән шәраб әзерләдем. Шул вакыт

Расүлуллаһ галәйһиссәлам кереп, моның нәрсә икәнлеген сорады. Мин моның белән кызымны дәвалавымны әйттем. Ул: «Чынлыкта, Аллаһы минем өммәтемә аңа харам булган әйбердә шифа бирмәде», — дип әйтте».

Шуңа күрә, хөрмәтле җәмәгать, шайтанның вәсвәсәләренә бирелмичә, Аллаһы Тәгаләнең ләгънәтенә кермичә, Аның кушканнарын гына үтәп, Аның тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп булсын. Барчабызга да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә булырга насыйп булсын. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рамил хәзрәт Гатиятов,*
*Теләче районы мөхтәсибәтенең яшьләр бүлеге хезмәткәре*

*2 гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Яңа ел — хисап вакыты

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе: «Сезгә хисап кылынганчы, үзегезгә үзегез хисап кылыгыз. Сезнең гамәлләрегезне үлчәгәнче, үзегез үзегезнең гамәлләрегезне үлчәгез», — дип әйтеп калдырган. Никадәр еш без бу киңәшкә колак салабыз? Һәр көн? Атнага, айга, елга бер? Әллә гомумән бу турыда онытабызмы? Олуг галимнәребез йокларга ятар алдыннан көн саен якыннарына васыятьләрен әйтә торган булганнар, бу аларга тыныч күңел белән үлемнең кечкенә энекәше (йокы) белән күрешергә ярдәм иткән. Барыбыз да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен яхшы хәтерлидер: «Кем иртәсен иминлектә, сәламәтлектә һәм бер көнлек ризыгы белән каршы алса, шул бөтен дөньяга ия кебек булыр». Ягъни, кеше йокларга ятып, вафат булса, аның тәүбәсе кылынган, хисабы башкарылган һәм ул васыятен әйтеп калдырган булыр. Әгәр иртән Раббыбыз тәкъдире белән уяныргa насыйп булса, ул бу дөньяның барлык байлыкларына ия кеше кебек уяныр. Бу Раббыбызның рәхмәте түгелмени?

Бүген, шөкер, 2 гыйнвар. Бер атна элек без сезнең белән ошбу мәчетләрдә 2025 елда күрешсәк, бүгенге җомга яңа елның беренче җомгасы булып тора. Менә бит, әлхәмдүлилләһ, нинди генә көннәр булмасын, җомгабызга килдек. Ә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселманнар өчен ике зур бәйрәм бар — Ураза гаете һәм Корбан гаете», — дигән. Әмма җомга көне алардан да бөек — Аллаһы Тәгалә каршында аның дәрәҗәсе икесеннән дә югарырак.

Расүлебез галәйһиссәлам дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрен дә аеруча хөрмәт иткән. Дүшәмбе көнне ул туган, ә пәнҗешәмбе — кешеләрнең гамәлләре Аллаһыга тапшырыла торган вакыт. «Мин аларның уразада тапшырыла алуын телим», — дип, ул ел дәвамында әлеге көннәрдә ураза тоткан.

Бүгенге көндә без сезнең белән озын кышкы ялларда. Халыкта бу көннәр яңа ел каникуллары дип йөртелә. Бу көннәр дә безнең өчен бертөрле әһәмияткә иядер: ел буе эшләгән эшләргә хисап, анализ ясый торган көннәр. 2025 елда кылган хаталарга карап, яңа елда аларны кабатламас өчен уйлыныр көннәрдер.

Кемдер «яңа ел», «яңа көн» дигән сүзләрдән шикләнергә мөмкин. Шуңа да вәгазебезнең башында ук көннәрне, елларны ничек кулланып булуын аңлатырга тырыштык: гыйбадәттә, хисапта... Шул ук вакытта, мөселман мәдәниятендә дә яңа ел дигән төшенчә бар. Һәм аны ниндидер гади генә мөселман гамәлгә кертмәгән. Икенче тугры хәлифәбез Гомәр радыяллаһу ганһе, бер айны сайлап алып, аны мөселманнар өчен елның башы дип билгеләргә дигән тәкъдим белән чыга. Озак уйлашканнан соң, галимнәребез һәм сәхабәләребез, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәдән Мәдинә шәһәренә һиҗрәт кылган көнен нигез итеп алып, елның башын мөхәррам аеннан башларга дигән карарга киләләр. Бу айның беренче булып килүенең төп максаты фәкать айлар исәбен алып бару өчен генә. Әмма шушы айлар хисабын алып бару безгә һәр датаны билгеләүгә, эшләребездә тәртип булуга китерә дә.

Кешенең тормышы тәртипсезлектә, хаоста булырга тиеш түгел. Киресенчә, без гомеребезне көннәрдән, атналардан, айлардан һәм еллардан кормыйбыз мыни? Гомер ул без уйлаганча озын түгел. Көн артыннан көн үтә, һәм һәр минут безнең хисабыбызга языла. Иртә белән уянгач, үзеңнән: «Бүген мин нәрсә эшләргә тиеш? Аллаһы Тәгалә риза булырдай гамәлләремне арттыра аламмы?» — дип сора. Кич җиткәч, уйла: «Мин бүген сүзләрем, гамәлләрем белән кемнедер рәнҗеттемме? Бүген минем күңелемдә рия, тәкәбберлек, нәфрәт калдымы?» Бу катлаулы хисап түгел. Әмма ул күңелне сафландыра, йөрәкне тынычландыра. Кайчак безнең зур гөнаһлардан түгел, ә

кечкенә, көндәлек ваемсызлыктан егылуыбыз мөмкин. Шуңа күрә һәр көнне нәтиҗә ясап, ялгышларыбызны төзәтү безне ахырда зур уңышка илтәчәк. Һәр кич — яңа башлангычка әзерлек. Әгәр бүгенге көнеңне намус белән, изгелеккә омтылып үткәрдең икән, ул көн юкка үтмәгән. Әгәр ялгыштың икән, тәүбә ит, иртәгә аны төзәтергә тырыш. Вәгаземнең башындагы сорауга кабат кайтам: кайсыбыз үзенә хисапны көн саен кылып тора?

Һәр туган көнне без мөмкинлек дип карарга тиешбез. Хәсән әл-Басри радыяллаһу ганһе хәзрәтләренең шундый сүзләре бар: «Әй кеше, син — бары тик көннәр. Бер көн үтү белән, синең дә өлешең кими». Шуңа күрә аны мөмкин кадәр файдалы итеп үткәрергә тырышыйк. Гаиләбез белән булыйк. Туганнар белән күрешик. Табигатькә чыгыйк, чана-чаңгыда да шуарга була, чөнки хәрәкәт, спорт сәламәтлеккә яхшы йогынты ясый. Бу көннәрдә кайбер мәчетләрдә интенсив курслар оештырыла. Аларга да чакырып калабыз, килегез, гыйлем алыгыз, хөрмәтле кардәшләр. Шулай ук Хәсән әл-Басри радыяллаһу ганһе мәгънәсе ягыннан мондыйрак сүзләр әйткән: «Өч көн бар: кичә, бүген, иртәгә. Кичәне син үзгәртә алмыйсың, иртәгәнең килү-килмәве билгесез. Шуңа күрә бүген белән эш ит». Ягъни, безгә Раббыбыз кайсы көнне каршы алырга насыйп итә, шул көнне файдаланыйк, гамәлләребезне, гыйбадәтләребезне үтәп калыйк.

Шулай ук, мөселман кешесе һәр әйбергә аек акыл белән килә. Ул болай гына бер әйбергә дә ышанмас, сукырларча иярмәс. Үзенең динен өйрәнеп, галимнәр фикеренә колак салыр. Шуңа да бер генә бәйрәмдә дә ул дине куйган кысалардан чыкмас. Бигрәк тә бу көннәрдә йолдызнамәләр турында сүз арта: телевидение, радиолардан гороскопка карап, кешеләргә бу елның «нинди булачагын» әйтәләр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә күрәзәчелек, сихерчелек — олы гөнаһларга илтә торган гамәлләр, дип килә. Аллаһы Раббыбыз хәтта ки иртәгәсе көнне дә яшерде. Миллиардлаган чакрым ераклыкта урнашкан йолдызларның безгә нәрсәдер турында сөйли дигәненә ышанырга кирәк түгеллеген акылы булган һәр кеше

аңлый. Шуңа күрә бу әйберләрдән ерак булыйк, якыннарыбызга матур итеп нәсыйхәтләр бирик. Бу көннәр шушындый темаларга сөйләшү, аңлату көннәре була ала. Үзенә күрә өстебездәге бер бурычны — якыннарыбызга динебезне матур итеп, аңлаешлы итеп аңлату вазифабызны да — башкара алабыз.

Шул ук вакытта күп кешедә бәйрәмнәрдә хәмер кулланыла. Әгәр бәйрәмдә, мәҗлестә хәмер кулланучылар булса, үзең эчмәсәң һәм башкаларның эчүенә битараф булып калсаң да, син дә шул гөнаһны башкарган кебек буласың. Бу — динебезнең бер кагыйдәсе. Каракның берәр нәрсә урлавын күргәч, минекен түгел, кешенекен урлый бит яки, урласыннар, ул кеше болай да бай, дип дәшми калсак, без дә шул гамәлне кылган, ягъни гөнаһка катышкан, булып чыгабыз.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем. Без көн саен эштә, балаларыбызны, якыннарыбызны бик аз вакыт күрәбез. Дәүләтебез, эштәге отпусклардан кала, һәр кешегә бер вакытта шушындый озын яллар бирә икән, димәк, бөтенебез бер вакытта буш дигән сүз: очрашулар планлаштырыйк, күрешик. Табигатькә чыгыйк. Кичләрен дәресләргә йөрик. Шөкер, Раббыбыз безгә күпме форсатлар биргән. Файдаланып калырга онытмыйк. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», — дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

# Нәсыйхәт

# Ата-ананың хаклары һәм аларны үтәү әдәпләре

Аллаһы каршындагы иң саваплы эшләрнең берсе — әти-әнигә изгелек кылу. Ата-анага итагать кылуның ни дәрәҗәдә мөһим булуы Аллаһы Тәгаләнең мондый аятьләреннән күренә:

**«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек** [кылырга] **әмер итте».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:23

**«Миңа һәм** [шуннан соң барлыклар арасыннан яратылыш сәбәбең булган] **ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту — Миңа** [булачак]**».**

«Локман», 31:14

Мәшһүр галим Суфьян бине Гояйнә биш вакыт намаз укучы кеше шул рәвешле Раббысына рәхмәтен күрсәтә, ә шул биш намаздан соң әти-әнисе өчен дога кылучы аларга карата рәхмәтен күрсәтә, дип әйткән.

Хәдистә: «Балаларыгыз да сезгә карата мәрхәмәтле булсын өчен, ата-анагызга изгелек кылыгыз», — диелгән. Шулай ук сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әти-әнисенә итагать кылмаучы кеше җәннәткә кермәс». Башка бер хәдистә болай диелә: «Җәннәтнең хуш исен йөз ел кадәр ара ераклыгыннан сизеп була. Бу хуш исне әти-әнисенә итагать кылмаган һәм туганлык җепләрен өзүче кеше генә тоя алмас».

Әти кешенең хакына караганда, әниләрнең хакы ике тапкыр артыграк. Әниләрне тыңлау, аларга изгелек кылу фарыз булып тора. Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән** [бу көчсезлек чоры авырга узуы белән башланып, нифасы беткәнче дәвам итә]**».**

«Локман», 31:14

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килгән дә, болай дип сораган:

— Йә Расүлуллаһ! Минем әнием бик нык картайды һәм инде аның акылы җиңеләйде. Мин аны үз кулымнан ашатам, аркамда күтәреп йөртәм. Минем шуны беләсем килгән иде: мин аның каршында булган бурычымны үтәдемме?

— Юк, син әле әниең алдындагы бурычыңның йөздән бер өлешен дә үтәмәдең, — дип әйткән Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Теге кеше бик гаҗәпләнгән:

— Ий Расүлуллаһ! Нишләп мин бурычымны үти алмадым соң?

— Әниең син көчсез вакытта сиңа ярдәм итүчең иде. Ул сине син яши алсын өчен тәрбияләгән. Ә син исә аны тизрәк үлүен теләп тәрбиялисең. Һәм шулай да син аңа изгелек эшлисең, — дигән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

Риваятьләр буенча, Муса пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләгә ялварган: «Аллаһым, җәннәттә минем күршем кем булачак? Миңа шул кешене күрсәтче!» Аллаһы Тәгалә: «Фәлән шәһәрдә бер ит сатучы яши. Җәннәттә синең күршең шул булачак», — дип хәбәр иткән һәм бу ит сатучының кыяфәтен, буен тасвирлаган. Муса галәйһиссәлам шунда ук шушы шәһәргә юнәлгән, әлеге ит сатучының кибетен эзләп тапкан. Үзенең кем икәнлеген хәбәр итмичә, Муса галәйһиссәлам ит сатучыда кунып чыгарга теләвен әйткән. Ит сатучы аны кабул иткән. Кичкә кадәр алар кибеттә булганнар. Кич җиткәч, ит сатучы кәрҗиненә бер ит кисәге салып, кунагы белән өенә кайткан.

Өендә ит сатучы бу иттән тәмле аш әзерләгән. Аның өенең бер почмагында тагын бер бик зур кәрҗин торган. Ит сатучы шуны ачкач, аның эченнән бик карт, ябык һәм зәгыйфь карчык чыккан. Ит сатучы аны үз куллары белән ашаткан. Соңыннан киемнәрен алыштырып, юып киптергән. Шуннан соң ит сатучы бу карчыкны кабат кәрҗингә салып, кәрҗинне элеп куйган. Шушы

бар вакыт дәвамында карчыкның иреннәре селкенеп торган. Моны күзәтеп утырган Муса галәйһиссәлам: «Бу зәгыйфь карчык кем?» — дип сораган. Ит сатучы: «Бу минем әнием. Ул бик картайды, көчсезләнде. Ул хәтта утырып тора да алмый. Эштән кайту белән, әүвәл мин аны ашатам. Аның хаҗәтләрен үтәп бетермичә, ашарга-эчәргә утырмыйм», — дип аңлаткан.

Муса пәйгамбәр: «Аның иреннәре һәрвакыт селкенеп торды. Ул нидер сөйлиме?» — дип сораган. Ит сатучы: «Әниемне караганда, ул һәрвакыт: «Ий Раббым! Улымны җәннәттә Муса галәйһиссәламнең күршесе ит!» — дип дога кыла», — дигән. Муса пәйгамбәр ит сатучыга: «Сиңа сөенечле хәбәрем бар! Мин — Муса пәйгамбәр һәм җәннәттә синең күршең булачакмын», — дип әйткән.

Әти-әнигә тавыш күтәрергә, кычкырырга ярамый, алар белән тыныч тавыш белән, әкренрәк итеп сөйләшергә кирәк. Аларның Ислам шәригатенә каршы булмаган бар таләпләрен үтәргә тырышырга кирәк. Хәтта ата-ана мөселман булмаса да, аларны барыбер тыңларга кирәк. Имам әл-Газали күпчелек галимнәребез шул фикердә булган, дип язган. Әмма ата-ана Ислам тыйганнарны таләп итсә, бу мәсьәләдә аларга буйсынырга ярамый.

Балалар ата-анасына карата итагатьле һәм әдәпле булсын өчен, ата-ана да аларга ярдәм итәргә тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Баласына үзенә карата итагатьле булырга ярдәм итүче атаны Аллаһы Тәгалә ярлыкасын», — дип әйткән. Ягъни балага начар мөнәсәбәттә булып, аны итагатьсез булырга мәҗбүр итмәскә кирәк.

*«Шир‘атуль Ислам. Ахляк и адабы Ислама» китабыннан*

*(С. Ализадэ, «Хозур» нәшрият йорты)*

# Истигъфар кылуның әдәпләре

Мөселманның һәрдаим истигъфар кылып торуы сөннәт санала. Хәзрәти Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай ди: «Һәр авыруның үз шифасы бар. Гөнаһларның шифасы — истигъфар».

Башка бер хәдистә болай диелгән: «Көненә ике истигъфар да кылмаган кеше үз-үзенә карата золым (гаделсезлек) кыла» (Әбү Давыд). Галимнәр бу иртән һәм кич истигъфар кылу дип аңлаткан.

Һәрдаим истигъфар кылып тору зур гөнаһларны кечкенәгә әйләндерә, кайгы-хәсрәттән арындыра, ризыкны арттыра.

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр кеше үзен истигъфар кылырга тиешле дип тапса, таныса, Аллаһы Тәгалә аны мохтаҗлыктан азат итәр, кайгы-хәсрәттән коткарыр һәм бу кешене ул көтмәгән дә җирдән ризыкландырыр (Әбү Давыд, Ибне Мәҗә).

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«Мин әйттем: «Раббыгыздан ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Ул —** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче.** [Истигъфар кылыгыз, җитмеш ел дәвам иткән корылык һәм кытлыктан соң Раббыгыз] **Күкне өстегезгә** [чиләктән койган кебек] **мул яуган бер хәлдә җибәрер. Маллар һәм ир балалар белән сезгә ярдәм итәр** [һәм киң мөмкинлекләр бирер], **сезнең** [файдалануыгыз] **өчен бакчалар үстерер һәм сезнең өчен** [ургылып аккан] **елгалар булдырыр».**

«Нух», 71:10–12

Хәсән әл-Басри исемле мәшһүр галимгә бер кеше килеп, корылыкка һәм ярлы булуына зарланган. Галим аңа истигъфар кылырга киңәш иткән. Башка кеше килеп, фәкыйрьлегенә зарланган. Галим аңа да истигъфар кылырга

киңәш иткән. Шулай ук җирләре уңдырышсыз булуга һәм нәселләре артмауга зарланучы кешеләргә дә Хәсән әл-Басри шушы ук киңәшен биргән. Шуннан Рабиг бине Сабих исемле кеше аннан: «Хәсән, сиңа кешеләр төрле моң-зарларын сөйләде. Син барысына да бер киңәш бирдең. Моның хикмәте нидә соң?» — дип сораган. Җавап итеп Хәсән әл-Басри югарыда китерелгән Коръән аятьләрен укып күрсәткән.

Сәхабәләрнең берсенә бер кеше мөрәҗәгать иткән: «Минем байлыгым күп, әмма балаларым юк. Раббым миңа балалар бирсен өчен, син миңа бер киңәш бирче». Сәхабә аңа һәрдаим истигъфар кылырга киңәш иткән. Шуннан соң бу кеше көн саен җиде йөз мәртәбә истигъфар кыла башлаган. Аллаһы Тәгалә аңа ун бала биргән.

Хөзәйфә исемле сәхабә радыяллаһу ганһе болай дип сөйләгән: «Мин бик еш балаларымны әрли идем, телемне тыя алмый идем, аларны рәнҗетә идем. Моннан котылу өчен, мин Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә мөрәҗәгать иттем. Ул миңа: «Син кайда йөрисең? Ник истигъфар кылмыйсың? Ий Хөзәйфә! Мин көненә йөз мәртәбә истигъфар кылам. Минем өммәтемнән сайлап алынган кешеләр ниндидер яхшылык күрсә, сөенәләр. Ә әгәр дә алар берәр начарлык күрсәләр, алар шунда ук истигъфар кылалар», — дип әйтте» (Имам Мөслим, Әбү Давыд).

## Истигъфар догалары

Тәүбә истигъфарга кадәр кылынырга тиеш. Тәүбә — ул кылынган гөнаһның әшәкелеген күргәннән соң, диндә мактала торган әйберләргә кайту.

Истигъфар дип Аллаһының мәгъфирәтен, ярлыкавын сорауны атыйлар. Кылынган гөнаһның начарлыгын аңлап һәм алга таба аны кылудан баш тартып кына ярлыкау сорарга була.

Рабигъ бине Хәйсәм болай дигән: «Сезнең берегез дә кылган гөнаһына үкенмичә (тәүбә итмичә) һәм башка аны кабатламаска сүз бирмичә, «әстәгъфируллаһ» дип әйтмәсен, чөнки бу сүз ялган һәм гөнаһ булачак».

Истигъфар кылучы мондый дога кыла ала:

أَسْتَغْفِرُ اللَّهَ الَّذِي لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ وَأَتُوبُ إِلَيْهِ

**Укылышы:** «Әстәгъфируллаһәл-ләҙии ләә иләһә иллә һу әл-хәййәл-каййүүм вә әтүүбү иләйһ».

**Мәгънәсе:** «Аллаһыдан ярлыкау сорыйм, Аннан башка гыйбадәткә лаек зат юк, Ул мәңге Тере, һәрнәрсәгә Тереклек бирүче, Аңа тәүбә кылам».

Бу дога турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу истигъфар догасын кылучының бар гөнаһлары ярлыканыр…»

Имам әл-Бохариның җыентыгында килгән хәдистә иң көчле истигъфар догасы булып әлеге дога атала:

اللَّهُمَّ أَنْتَ رَبِّي لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ، خَلَقْتَنِي وَأَنَا عَبْدُكَ، وَأَنَا عَلَى عَهْدِكَ وَوَعْدِكَ مَا اسْتَطَعْتُ، أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ، أَبُوءُ لَكَ بِنِعْمَتِكَ عَلَيَّ، وَأَبُوءُ لَكَ بِذَنْبِي فَاغْفِرْ لِي، فَإِنَّهُ لَا يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا أَنْتَ

**Укылышы:** «Аллаһүммә әнтә раббии ләә иләһә иллә әнт, халәкътәнии вә әнә габдүк, ә әнә галәә гаһдикә вә вәгъдикә мәстәтагътү, әгуҙү бикә мин шәрри мәә санәгътү, әбү-ү ләкә бинигъмәтикә галәййә, вә әбү-ү бикә биҙәнбии фәгъфирлии, фәиннәһү ләә йәгъфируҙ-ҙунуубә иллә әнт».

**Мәгънәсе:** «Аллаһым — Син минем Раббым. Синнән башка гыйбадәткә лаек зат юк. Син мине бар кылдың һәм мин — Синең колың. Көчем җиткән чаклы Сиңа биргән вәгъдәмдә торырга тырышырмын. Кылган гөнаһларымның зыяныннан Сиңа сыенамын. Миңа биргән бөтен нигъмәтләреңне таныймын, кылган бөтен гөнаһларымны таныймын. Гафу ит мине, чынлыкта, Синнән башка гөнаһларны гафу итүче зат юк».

*«Шир‘атуль Ислам. Ахляк и адабы Ислама» китабыннан*

*(С. Ализадэ, «Хозур» нәшрият йорты)*

# Йорт салуга караган әдәпләр

Бу эштә чаманы белү сөннәт булып тора. Йортның биеклеге якынча 3 метр булырга тиеш, кемдер 3,5 метр дип әйткән. Әмма беренче фикер дөресрәк. Өйнең киңлеге исә анда яшәячәк кешеләр санына карап билгеләнер, аның гаиләнең ихтыяҗларын канәгатьләндерүе мөһим. Чамадан тыш (зур йорт) төзегән кешеләр Кыямәт көнендә бар артык әйберләрен үз өсләрендә күтәреп кубарылырлар.

Йортны анда Аллаһыга гыйбадәт кылу, кояш, яңгыр һәм җилдән ышыклану нияте белән салырга кирәк. Ә нияте андый булмаган кеше өчен Кыямәт көнендә йорты авыр йөк булыр. Йортны салганда бик күп акча сарыф итмәскә тырышырга кирәк. Бу эштә су һәм балчыкка артык акча сарыф итүдә хәерлелек юк.

Мөхәммәд бине Сәммак рахимәһуллаһи Харун әр-Рәшиднең зур сарай салуын күреп, болай дигән:

— Син (төзелеш өчен кирәк булган) балчыкны олыладың һәм динне кимсеттең. Әгәр сарайны үз акчаңа саласың икән, син исраф кыласың. Әгәр кеше акчасына саласың икән, син гаделсез кешеләрдән. Ә Аллаһы Тәгалә гаделсезлек кылучыларны яратмый.

## Өйдә бәрәкәт булсын дисәң

Хәдистә: «Сурәтләр булган өйгә фәрештәләр керми», — дип әйтелгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сурәтләр төшерелгән япмалар эленгән өйләргә керми торган булган.

Ишегалдын, бакча һәм өй янында урамны да чисталыкта тотарга кирәк. Чисталык — иманнан. Өйнең әйләнә-тирәсен чисталыкта тотсаң, бу байлык һәм муллык сәбәбе булачак.

Әлеге гамәлләр ризыкның киң булуына сәбәп булып тора: өй янындагы бакчаны чисталыкта тоту, матур итеп язу, матур итеп сөйләшү, савыт-сабаны юу, күркәм сүзләр әйтү, тәхәҗҗүд намазын уку, иртәнге намаздан соң мәчеттә берникадәр вакыт утырып тору, «әл-Инширах» һәм «әл-Вакыйга» сүрәләрен уку.

Ризыкны арттыра торган иң көчле гамәлләрнең берсе — намазларны бар тәртипләрен үтәп һәм хошуглык белән уку.

Өйгә кергәндә һәм чыкканда, Аллаһының исемен зикер итеп, «бисмилләһ»не әйтергә кирәк. Өйгә кергәч, хуҗалар өйдә булса, сәлам бирергә кирәк. Өйдә берәү дә булмаса, өч тапкыр «әл-Ихлас» сүрәсен укырга киңәш ителә. Сәлам бирү һәм Коръән аятьләрен уку бәрәкәтне арттыра.

Хәзрәти Җәбир радыяллаһу ганһе тапшырган: «Әгәр кеше йортка кергәндә яки ашый башлаганда «бисмилләһ»не әйтсә, шайтанның кәефе кырылыр һәм ул дусларына: «Безнең өчен бу йортта азык юк һәм безгә монда кунарга да язмаган», — дип әйтер. Ә әгәр кеше Аллаһыны зикер итмичә ашый башласа, шайтанның кәефе күтәрелер һәм ул: «Бу йортта безгә ризык та, сыеныр урын да бар», — дияр».

Төн җиткәч, өйнең ишекләрен «бисмилләһ» әйтеп бикләргә кирәк. Тәрәзә пәрдәләрен ябарга, утны (ризык пешерү өчен һәм яктылык өчен) сүндерергә кирәк. Ачык урыннарда һәм өйдә ялгыз гына йокларга киңәш ителми.

Шулай ук шундый киңәш бирелгән: «Әгәр берегез, өйдә булып, төнлә тышта таныш булмаган тавышлар ишетсә, өеннән чыкмасын».

Йорт салуда сөннәтләрнең берсе — аерым юыну бүлмәсе, бәдрәф, аерым тәһарәт алу урыны булдыру һәм шулай ук кунаклар өчен бүлмә булдыру. Хәдистә болай диелгән: «Һәр нәрсәнең зәкяте билгеләнгән. Йортның зәкяте — ул кунаклар өчен бүлмәләр (булуы)».

Өйдә хуш исләр килеп торсын өчен, махсус ислемайлар куллану хуплана.

# Өйдә эт асрау турында

Ихатада ау яки йортны саклау өчен эт тотарга мөмкин. Әмма аны өйнең эченә кертергә ярамый. Хәдистә: «Эт булган йортка фәрештәләр керми», — дип әйтелгән. Шулай ук фәрештәләр сыртлан, арыслан, барыс һәм башка төрле ерткыч хайваннар булган өйләргә кермиләр. Бу Имам Әбү Йосыф рахимәһуллаһи фикере.

Мәшһүр галим Вәһб бине Мөнәббиһтән тапшыралар: «Адәм галәйһиссәлам җиргә төшкәч, Иблис ерткыч хайваннарга: «Менә бу — сезнең дошманыгыз. Аны тизрәк үтерегез!» — дип әйткән. Ерткычлар җыелып, эткә: «Арабызда син иң кыю хайван, бу эшне син башкар», — дигәннәр.

Бу хакта белгәч, Адәм галәйһиссәлам бик гаҗәпләнгән. Шунда ук Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам пәйда булып: «Ий Адәм, тизрәк этне башыннан сыйпа», — дигән.

Адәм галәйһиссәлам этне башыннан сыйпаган, һәм эт аңа ияләшкән, койрыгын болгап, аның янында басып торган. Моны күргән башка хайваннар шундук таралышканнар. Эт Адәм галәйһиссәлам янында калган. Шул вакыттан алып бүгенге көнгә кадәр эт кеше янында яши».

*«Шир‘атуль Ислам. Ахляк и адабы Ислама» китабыннан*

*(С. Ализадэ, «Хозур» нәшрият йорты)*

# Күрше хакы

Зур мәсьәләләрнең берсе — яхшы күрше булу. Хәдистә болай диелгән: «Өй сатып алганда, яхшы күрше сайла. Юлга чыкканда, яхшы юлдаш эзлә». Күршеләрне хөрмәт итү, аларга ачык йөзле булу — сөннәт гамәлләр.

Гайшә анабыз тапшырган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җәбраил галәйһиссәлам миңа күршеләргә хәерлелек кылырга киңәш итте, мин хәтта күрше күршесенең варисы булачак, дип уйладым». Күршеләр белән мөмкин кадәр мәрхәмәтле булырга, аларны яратырга һәм хөрмәт итәргә кирәк, аларга яхшылык кылырга тырышырга кирәк. Күршең ач була торып, тук килеш йокларга ятарга ярамый. Аллаһы Тәгалә биргән ризыкны күршеләрең белән бүлешү тиешле. Мөселман күршесенә уңайсызлыклар тудырмас, аны кирәкмәгәндә борчымас, күршесе канәгать булмаган гамәлләр кылмас. Имам әл-Бохари китергән хәдистә: «Күршеләрен үз золымыннан сакламыйча торып, берәү дә Аллаһыга ихлас иман китерүче булмас», — диелгән.

Күршең мөселман булмаган очракта да, аңа бүләкләр бирергә кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Күршеләр өч төрле була: бер хакы булган күрше, ике хакы булган һәм өч хакы булган күрше. Бер хакы булган күрше — ул мөселман булмаган һәм туганың булмаган күрше. Ике хакка ия булганы — мөселман булган күрше. Ул мөселман хакына да, күрше хакына да ия. Ә өченче хакка да ия булган күрше — ул мөселман һәм туганың булган күршең. Аның мөселман хакы да, күрше хакы да, туган хакы да бар».

Имам Зөһри (Аллаһының рәхмәтендә булсын) болай дип сөйләгән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килеп, күршесенә зарланган. Шуннан соң Пәйгамбәребез галәйһиссәлам игълан итәргә кушкан: «Ий кешеләр! Игътибарлы булыгыз! Кырыгынчы өйгә кадәр — күршеләрегез!» Моны сөйләгәндә имам Зөһри куллары белән ишарәләп,

дүрт якка күрсәткән: «Кырык бу якка һәм кырык бу якка, кырык шул якка һәм кырык теге якка». Шуңа күрә элекке чорда яшәүче кайбер мөселман кардәшләребез өенең һәр ягында урнашкан кырык йортка бәйрәмнәр вакытында бүләк итеп корбанлыклар һәм кием җибәрә торган булган. Һәм шулай ук шушы йортларда яшәүчеләргә ярдәм итә торган булган.

Рөхсәтсез күршеңнең өенә керү тыелган. Аның коймасын нәҗесләү, этенә таш яки таяк ату, үтенеч белән килгән күршең алдында ишекне ябып кую — болар барысы да күршеләргә карата гаделсезлек кылу булып тора.

Күрше балаларына карата мәрхәмәтле булырга, ачык йөз белән сөйләшергә, алар белән уйнарга, башларыннан сыйпарга тиешле. Бу күршеңә яратуыңны һәм хөрмәтләвеңне күрсәтү булачак. Күршең биргән хәтта кечкенә генә бүләккә дә рәхмәтле булырга кирәк. Очрашканда, күршеләргә ачык йөзле булып, ягымлы итеп сөйләшергә тиешле.

Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе болай дигән: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа болай дип әйтә иде: «Аш куйганда, суын күбрәк сал. Шуннан соң бөтен күршеләреңне барлап чык та, кемгә кирәк дип тапсаң, шуңа бер тәлинкә ашыңны бүлеп бир».

Күршең бурычка акча сорап керсә, бирергә тырышырга кирәк. Күршең авырганда, аның хәлен белергә кер. Аңа кайгы килсә, кайгысын уртаклашып, аңа терәк-таяныч булу тиешле. Ә шатлыклы хәбәр килсә, кереп сөенечен уртаклашырга. Хәдистә болай диелгән: «Дин кардәшенең кайгысын уртаклашкан мөселманга Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә миһербанлык киемнәре кидерер». Кайгы уртаклашу кыенлык килгән кешегә нык, сабыр булуны теләүне күз уңында тота.

Күршесе бакыйлыкка күчсә, мөселман һичшиксез аның җеназасында катнашыр. Әгәр күршесе ерак сәфәргә чыгып китсә, ул аның өен, балаларын карап, саклап торыр. Мөселман күршесенең җиренә терәп биек корылмалар төземәс, чөнки бу кояшны каплый һәм җилне кертми. Әгәр күршесе рөхсәт бирсә, ул очракта төзи ала. Бакчасында уңыш җыйгач, мөселман бер өлеш

яшелчә-җимешләрен күршесенә тәкъдим итәр яки ул күрмәгәндә генә ишеге янына китереп куяр. Өйне сатарга җыенганда, беренче чиратта аны күршеңә тәкъдим итәргә кирәк.

Тәкъва, диндар күршегә ия булу — зур бәхет. Хәдистә: «Бер тәкъва мөэмин аркасында Аллаһы Тәгалә күршедәге йөз мең өйне кайгылардан коткара», — дип әйтелгән.

Бер кешенең өен тычканнар баскан. Дусты аңа өенә мәче алырга киңәш иткән. Бу кеше: «Әгәр мин мәче тотсам, бу тычканнар күршемә качып, аны җәфалап бетерер. Үземә теләмәгән әйберне мин күршемә дә теләмим», — дигән.

Гомәр радыяллаһу ганһе: «Күршеләренең, дусларының һәм туганнарының ышанычына лаек булган кешедән шикләнмәгез», — дип әйткән.

*«Шир‘атуль Ислам. Ахляк и адабы Ислама» китабыннан*

*(С. Ализадэ, «Хозур» нәшрият йорты)*

# Тәмугның баскычлары

Адәм балаларының бу дөньядагы гамәлләре төрле булган кебек үк, аларның җәннәттәге һәм тәмугтагы дәрәҗәләре дә төрле булачак. Изге гамәлләрне савабы ягыннан дәрәҗәләргә бүлеп булган кебек, гөнаһлы гамәлләрнең дә, авырлыгына карап, төрле дәрәҗәләре бар.

Коръәни Кәримдә «җәһәннәм» сүзе 77 мәртәбә очрый һәм кәферләрне, мөшрикләрне, залимнәрне һәм Аллаһының кануннарын үтәмәүчеләрне җәзалау урыны буларак тасвирлана. Шулай ук тәмугны билгеләү өчен Коръәндә башка сүзләр дә кулланыла. Аларның кайберләре тамугның дәрәҗәләрен һәм аларда булачак җәзаны атый.

Тәмуг төрле баскычлардан, дәрәҗәләрдән тора. Аларның һәркайсына төрле дәрәҗәдәге газаплар хас. Бу хакта Коръәни Кәримдә болай диелгән:

**«Һичшиксез, җәһәннәм — аларның барысына да вәгъдә ителгән урын. Аның җиде капкасы бар, һәрбер капка өчен алар арасыннан аерылган бер төркем бар».**

«Әл-Хиҗр», 15:43–44

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшырган: «Җәһәннәмнең җиде капкасы (җиде дәрәҗәсе) бар».

Тәмугның баскычлары (дәрәҗәләре) өстән аска таба урнашкан һәм өске дәрәҗәсендәге газаплар, аскы баскычларындагы газаплар белән чагыштырганда, йомшаграк, җиңелрәк булачак.

Тәмуг баскычларының атамалары мондый: Җәһәннәм, Ләза, әл-Хутамә, әс-Сәгыйр, Сәкар, әл-Җәһим, Һавия.

1. Җәһәннәм — тәмугның иң югары һәм газаплары иң җиңел булган баскычы. «Җәһәннәм» сүзе киң мәгънәдә гомумән тәмугны белдерсә дә, тар мәгънәсендә ул — фәкать өске баскычның атамасы гына. Галимнәр

фикеренчә, бу баскычка гөнаһлы мөселманнар эләгәчәк, ә гөнаһларыннан пакьләнеп беткәч, алар җәһәннәмнән җәннәткә чыгарылачак, һәм бу баскыч бушап калачак.

Җәһәннәмгә кертелгәндә, бу баскыч әһелләре көчле салкынлык тоячак, шуңа күрә ул «җәһәннәм» дип аталган да.

Бу баскычтагы газаплар, коточкыч куркыныч булсалар да, — тәмугта мөмкин булган иң җиңел газаплардыр. Бу хакта Язид бине Әбү Мәлик радыяллаһу ганһе болай дигән: «Тәмуг уты җиде өлештән тора. Аның өске өлеше, аскы өлеше аңа зыян салмасын өчен, Аллаһы Тәгаләгә сыена».

2. Тәмугның икенче баскычы «Ләза» дип атала. Бу сүз Коръәни Кәримдә бер тапкыр («әл-Мәгариҗ / Баскычлар» сүрәсенең 15 нче аятендә) очрый һәм кешенең тән әгъзаларын өзеп ала торган утны белдерә. Ләза уты Аллаһының диненнән йөз чөергәннәрне үзенә чакырачак.

3. Хутамә сүзенең мәгънәсе — вату, тар-мар итү, кисәкләргә җимерү. «Әл-Хутамә» атамасы Коръәннең «әл-Һүмәзә / Яла ягучы» сүрәсендә килеп, «йөрәкләргә кадәр үтәчәк» утны белдерә. Ягъни бу ут юлындагы бар киртәләрне җимереп — кеше гәүдәсендәге бөтен әгъзаларны ашап бетереп — иң азакта аның үзәгенә җитәчәк. Бу баскычтагы кеше күз яшьләре корыганчыга кадәр елар, ә аннан соң аның күзләреннән кан, соңыннан эрен агар.

4. Сәгыйр сүзенең тамыры — «сәгър» фигыле, Коръәннең 17 аятендә «яндырырга» мәгънәсендә очрый. Әс-Сәгыйр баскычы «әл-Мүльк / Хөкемдарлык» (ягъни «Тәбәрак») сүрәсендә искә алына. Аңа Аллаһы Тәгалә җибәргән пәйгамбәрләргә ышанмаучылар эләгәчәк, диелә.

Әс-Сәгыйрдә 300 урын бар, һәр урында — 300 йорт. Һәр йортта еланнар, чаяннар, богаулар, зынҗырлар һәм элмәкләр кебек 300 төрле газап бар. Бу баскычта шулай ук Кайгы коесы урнашкан.

5. Сәкар сүзенең тамыры өтеп алырга, бик көчле утта кыздырырга мәгънәләренә ия. Бу сүз Коръәндә дүрт тапкыр очрый, шуларның өчесе —

«әл-Мүддәссир / Төренгән» сүрәсендә. Бу баскычның уты анда эләгүчеләрнең тиреләрен, итләрен тулаем сөяккә кадәр яндырачак.

6. Җәһим сүзе Коръәндә кат-кат янып бетүче, кызган ут, дөрләп янган ут мәгънәләрендә килә. Алтынчы баскычның атамасы Коръәндә 26 мәртәбә очрый. Әл-Җәһим әһелләре — Аллаһыга көферлек кылып, Аның аятьләрен ялган дип табучылар. Бу дәрәҗәнең бер очкыны Җир шарыннан да зуррак, дип искә алына.

7. Һавия сүзенең тамыры өстән аска төшәргә; тирән чокыр, упкын мәгънәләренә ия. Коръәни Кәримдә Һавия уты бер генә тапкыр («әл-Карига / Ишек каккан» сүрәсендә) очрый һәм болай тасвирлана:

«[Ул – соң дәрәҗә] **Кызган ут** [җәһәннәмнең иң аскы каты булган бу урынга баштүбән ыргытылган гөнаһлылар җитмеш елдан соң гына төбенә төшеп җитәчәкләр]».

Аллаһы Тәгалә безне тәмугның бөтен баскычларыннан сакласын! Әмин!

*«Семьдесят пять вопросов об Аде» китабыннан*
*(Г. Накышчы, «Хозур» нәшрият йорты)*

# Җәннәтнең дәрәҗәләре

Төрле дини текстлардан билгеле булганча, җәннәт әһелләренең дәрәҗәләре төрле булачак. Бу хакта Коръәни Кәримдә берничә мәртәбә искә алына. Мәсәлән:

> **«Һәркем өчен** [яхшылык-яманлык] **кылганнарына карата** [җәһәннәмдә һәм җәннәттә] **дәрәҗәләр бар. Синең Раббың аларның ни кылганнарыннан гафил** [һәм хәбәрсез] **түгел».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:132

Тәфсирләрдә искә алынганча, мөэминнәр үзләренең дәрәҗәләре белән аерылып торалар. Алар җәннәткә Аллаһының рәхмәте буенча гына керсәләр дә, җәннәттәге дәрәҗәләре аларның гамәлләре буенча билгеләнәчәк. Бу хакта Гата радыяллаһу ганһе: «Гамәлләренә күрә мөэминнәр җәннәтнең төрле дәрәҗәләрендә булачак», — дип әйткән.

Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшыра: «Җәннәттә йөз дәрәҗә бар, аларның һәрберсе арасында йөз еллык ара».

Шулай ук Әбү Сәгыйть әл-Ходри радыяллаһу ганһе тапшырган мондый хәдис билгеле: «Дөреслектә, җәннәттә йөз дәрәҗә бар, һәм аның бер дәрәҗәсе җирдәге бар үлчәмнәрне үз эченә сыйдыра».

## Җәннәтнең иң югары баскычы

Җәннәтнең иң югары баскычы — Вәсилә дәрәҗәсе. Хәдисләрдән билгеле булганча, бу баскыч фәкать бер кеше өчен каралган, һәм сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы кеше булырга өметләнәм, телим, дип әйткән. Ул болай дигән: «Аллаһыдан минем өчен Вәсилә сорагыз. Дөреслектә, бу дөньяда минем өчен Вәсилә сораган кешегә мин Кыямәт көнендә шәфәгать кылырмын». Башка бер хәдистә азан вакытында

мөәзин артыннан азан сүзләрен кабатлап, соңыннан Пәйгамбәребез өчен Вәсилә сорарга кирәклеге хәбәр ителә. Мондый мөселман Кыямәт көнендә Пәйгамбәребезнең шәфәгатенә ирешәчәк.

Димәк, Вәсилә дәрәҗәсе Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен яратылган, ә башка мөселманнар өчен җәннәтнең иң югары баскычы ул — Фирдәвес җәннәте. Гобадә бине әс-Самит мондый хәдис тапшыра: «Җәннәттә йөз дәрәҗә бар, һәм ике дәрәҗә арасындагы ераклык күк белән җир арасына тиң. Иң югары дәрәҗә ул — Фирдәвес дәрәҗәсе. («Мөхәммәд» сүрәсендә искә алынган) Җәннәтнең дүрт елгасы Фирдәвестән ага башлый. Аның өстендә Аллаһының Гареше урнашкан. Һәм Аллаһыдан сораган вакытта Фирдәвес җәннәтен сорагыз».

## Җәннәтнең ничә капкасы бар?

Хәдисләрдә искә алынганча, җәннәтнең сигез капкасы бар. Мәсәлән, хәзрәти Сәһл бине Сәгъд радыяллаһу ганһе мондый хәдис тапшырган: «Җәннәтнең сигез капкасы бар» (имам әл-Бохари).

Башка бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Тиешенчә тәһарәт алып, соңыннан шушы доганы укыган кешегә җәннәтнең сигез капкасы ачылыр, һәм ул теләгән капкасыннан җәннәткә керер:

أَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ،
اللَّهُمَّ اجْعَلْنِي مِنَ التَّوَّابِينَ وَاجْعَلْنِي مِنَ الْمُتَطَهِّرِينَ

«Әшһәдү әлләә иләәһә илләә-ллааһу вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә әшһәдү әннә мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһ, аллаһүммә-җгальнии минәттәввәбинә вәҗгальнии минәл-мүтәтаһһириин».

**Мәгънәсе:** «Шәһадәт китерәмен: Аллаһыдан башка гыйбадәткә лаек зат юк, Аның тиңдәше юк, һәм Мөхәммәд галәйһиссәлам — Аның колы һәм

расүле. Аллаһым, мине тәүбә кылучылар һәм пакьләнүчеләр рәтеннән кыл» (имам әт-Тирмизи).

Бу тормышта кылган гыйбадәтләренә күрә, кешеләр җәннәткә төрле капкалардан керә алыр. Мәсәлән, намаз кылучылар — намаз капкасыннан, ураза тотучылар «Әр-Раййән» капкасыннан керерләр.

Хәдисләргә нигезләнеп, Йосыф бине Сәгыйд әл-Мәлики исемле галим җәннәт капкаларының мондый атамаларын китергән:

1) «Әр-Раййән» капкасы — ураза тотучылар өчен;

2) намаз капкасы;

3) зәкят капкасы;

4) Аллаһы юлында тырышлык куючылар капкасы;

5) «Тәүбә» яки «Рәхмәт» дип аталган капка;

6) ярлыкау капкасы;

7) риза вә канәгать булучылар капкасы;

8) җәннәткә хисапсыз керүчеләр өчен капка.

Җәннәт капкаларының зурлыгына килгәндә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: «Җәннәт капкаларының киңлеге кырык ел җәяү үтелә торган арага тиң» (имам Әхмәд). Ә башка бер хәдистә аларның киңлеге Мәккә белән Бусра шәһәре (Сүриядә) арасындагы ераклыкка тиң диелгән. Вә бу хакта башка хәдисләр дә билгеле.

## Җәннәт әһелләре турында кайбер хәдисләр

Әбү Сәгыйть әл-Ходри радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен тапшыра: «Дөреслектә, сез офыкта көнчыгышка яки көнбатышка юнәлгән якты йолдызга ничек карасагыз, җәннәт әһелләре югарырак дәрәҗәдәге бүлмәләрдә яшәүчеләргә шулай карар. Берәүләр башкаларыннан шул дәрәҗәдә югары булыр». Аннан: «Йә Расүлуллаһ, бу бүлмәләр пәйгамбәрләр йортлары булып, алардан башка ул

дәрәҗәләргә беркем дә ирешә алмасмы?» — дип сораганнар. Ул: «Юк, Аллаһы белән ант итәмен, алар Аллаһыга иман китереп, Аның пәйгамбәрләренә ышанган кешеләр өчен», — дип җавап кайтарган.

Гали радыяллаһу ганһе тапшыра: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Дөреслектә, җәннәттә эченнән — тышы, ә тышыннан эчләре күренеп тора торган сарайлар бар». Шунда бер гарәп кешесе: «Анда кем яшәячәк?» — дип сорады. Пәйгамбәребез: «Алар кешеләр белән мәрхәмәтле булучы, мохтаҗларны ашатучы, өстәмә (нәфел) уразалар тотучы һәм башкалар йоклаган вакытта Аллаһы ризалыгы өчен тәхәҗҗүд намазын укучылар өчен», — дип әйтте».

Үбәй бине Кәгъб радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребездән салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый хәдис тапшырган: «(Җәннәттә) аңа йортлар салынуын һәм югары дәрәҗәләр булдырылуын теләгән кеше аңа золым китерүчеләрне гафу итсен, дошманнары белән яхшы мөгамәлә корсын һәм аның белән араларны өзечүгә яхшы карасын».

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе мондый күркәм хәдис тапшырган: «Җәннәткә керүче беренче төркем әһелләренең сурәтләре тулган айга тиң булыр, ә алардан соң керүчеләр якты йолдызлар сыман булырлар. Аларның калебләре бер калебтәй булыр, һәм алар арасында каршылыклар да, нәфрәт тә булмас».

## Җәннәт әһелләренең киемнәре нинди булыр?

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Тәкъвалык ияләре, һичшиксез,** [үзләре теләмәгән һәртөрле нәрсәдән имин булган] **ышанычлы урындалар. Җәннәтләр эчендә елгалар янында.** [Бер-берләре белән аралашу мәҗлесләрендә] **Кара-каршы** [утырган] **хәлдә атластан һәм парчадан** [тегелгән бик кыйммәтле киемнәр] **киенерләр».**

«Әд-Духан / Төтен», 44:51–53

Күпчелек тәфсир галимнәре (мөфәссирләр) фикеренчә, бу аятьтә искә алынган гарәп «сүндүс» сүзе юка ефәкне, ә «истәбракъ» дигән сүз калын ефәкне (парча) белдерә. Кайбер мөфәссирләр фикере буенча, икенче сүз тыгыз ефәкне аңлата.

Башка аятьтә Аллаһы Тәгалә бу ефәкнең яшел төстә булуын искәртә:

**«Алар анда диваннар өстенә утырып, беләзекләр белән бизәнәчәкләр, юка һәм калын ефәк-парчадан яшел киемнәр киячәкләр».**

«Әл-Кәһф / Мәгарә», 18:31

Ә башка аятьтә җәннәт әһелләре болай тасвирланган:

**«... Андагы киемнәре исә — ефәк».**

«Әл-Хаҗ», 22:23

Монда бер бик мөһим мәсьәләгә игътибар итәргә кирәк. Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу дөньяда ефәк киемнәр кигән ир-ат аны ахирәттә кимәячәк» (әл-Бохари).

Беренче карашка, бу хәдиснең мәгънәсе алда китерелгән «әл-Хаҗ» сүрәсенең 23 нче аятенең мәгънәсенә каршы килә кебек. Монда кешенең шундый соравы туарга мөмкин: «Җәннәткә лаек булган, әмма дөньялык тормышында ефәк кием кию кебек гөнаһ кылган ир-атның хәле ничек булыр соң?»

Кайбер мөселман галимнәре моңа болай дип җавап бирә: «Бу кеше җәннәт бакчаларына керер, әмма аның киемнәре башка тукымадан булыр, ефәктән булмас». Ә күпчелек галимнәребез фикере буенча, Аллаһы Тәгалә мондый ир-атны гафу итәр һәм җәннәтенә кертер. Димәк, гөнаһларын гафу иткәч, Аллаһы аны җәннәтнең ефәгеннән дә мәхрүм итмәс.

Җәннәт әһелләре беләзекләр белән бизәнер. Коръәни Кәримдә аларның алтыннан, көмештән һәм энҗедән булуы әйтелгән. Аллаһы Тәгалә инде искә алган аятебездә болай дип әйтә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы иман китергәннәрне һәм** [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек] **изге гамәлләр кылучыларны** [агачлары һәм сарайлары] **асларыннан елгалар аккан җәннәтләргә кертәчәк. Алар анда алтын беләзекләр һәм энҗеләр белән бизәндереләчәк...»**

«Әл-Хаҗ», 22:23

Монда алтын белән энҗе искә алынса, башка аятьтә беләзекләрнең көмештән ясалуы хәбәр ителә:

> **«Өсләрендә — юка һәм калын ефәктән ямь-яшел киемнәр. Алар көмеш беләзекләр белән бизәнер. Раббылары аларга пакь эчемлек эчерер».**

«Әл-Инсан / Кеше», 76:21

Җәннәттәге бизәнү әйберләренең күплеге, төрлелеге һәм кыйммәте турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә болай дип әйткән: «Чынлыкта, Аллаһы Тәгаләнең шундый фәрештәсе бар, ул мәхлуклар яратылган көннән башлап Кыямәт көненә кадәр җәннәт әһелләре өчен бизәнү әйберләре ясый. Әгәр бу зиннәтләрнең бер кисәге генә җиргә эләксә, ул (үзенең балкышы, матурлыгы белән) кояш нурларын уздырыр иде» (Ибне Әбү Шәйбә).

Аллаһы Раббыбыз барчабызга җәннәт ефәкләренә киенеп, зиннәтләре белән бизәнергә насыйп итсен!

## Җәннәт әһелләренең хезмәтчеләре булырмы?

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә җәннәт бакчаларында мөэминнәрне хезмәтчеләре көтә дип хәбәр итә. Бу хакта болай диелгән:

> **«Мәңге яшь яшүсмерләр** [хезмәт күрсәтеп] **алар тирәсендә әйләнеп йөриячәк».**

«Әл-Вакыйга», 56:17

Имам әл-Куртуби рахимәһуллаһи китергәнчә, әлеге аятьтә кулланылган «мүхалләдүн» сүзе хакында хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дигән: «Бу – мәңге яшь калачак, беркайчан да үлмәячәк хезмәтчеләр». Имам Мөҗәһид, Кальби һәм Мөкатилләр әйткәнчә: «Бу хезмәтчеләр үсмиләр, картаймыйлар һәм аларның кыяфәтләре үзгәрми».

Янә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Алар тирәсендә мәңге яшь** [һәм чибәр булган] **яшүсмерләр** [хезмәт күрсәтеп] **әйләнеп йөриячәк. Син аларны күргәч, аларны чәчелгән энҗе дип санарсың».**

«Әл-Инсан / Кеше», 76:19

**«Гүя** [кабырчыгында] **саклаулы энҗе шикелле** [ак, пакь һәм саф булып буйга җиткән] **яшь егет хезмәтчеләр исә алар тирәсендә** [сырышып] **әйләнеп йөрер».**

«Әт-Тур / Тур тавы», 52:24

Бу аятьләрнең беренчесендә искә алынган җәннәт хезмәтчеләре, җәннәт әһелләренә тырышып хезмәт күрсәтүләре сәбәпле, чәчелгән энҗе бөртекләренә тиңләнгән. Ә икенче аятьтә, саф вә пакь булулары сәбәпле, алар кабырчык эчендә сакланган энҗе белән чагыштырыла.

Бу яшь хезмәтчеләр кемнәр икән соң? Кайбер галимнәр фикеренчә, алар — мөшрикләрнең балалары. Башка галимнәр бу – балигълыкка ирешкәнче үлгән мөселман балалары дигән фикердә булган.

Ә башка фикер буенча, җәннәттәге хезмәтчеләр — һур кызлары кебек үк, Аллаһы Тәгалә тарафыннан җәннәттә хезмәт күрсәтү өчен махсус барлыкка китерелгән мәхлуклар.

*«Девяносто девять вопросов о Рае» китабыннан*

*(Г. Нәкышчы, «Хозур» нәшрият йорты)*

# Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?

# ИЮНЬ–СЕНТЯБРЬ

## Лаеш мөхтәсибәтенең Сокуры авылында яңа «Мәдинә» мәчете ачылды

Ике катлы мәһабәт бина 283 $м^2$ тәшкил итә. Мәчет янында төзекләндерелгән чишмә бинасы бар. Имам-хатыйб итеп Марат хәзрәт Гайнетдинов билгеләнде.

## Саба мөхтәсибәтендә мохтаҗ гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өчен җәйге бәйрәм узды

Саба мөхтәсибәте 1 июньдә — Халыкара балаларны яклау көнендә — Саба Җәмигъ мәчете җирлегендә районның социаль яклау идарәсе белән берлектә мохтаҗ гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар өчен җәйге бәйрәм уздырды. Бәйрәмдә катнашкан 30 га якын бала арасында тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр, әби-бабай тәрбиясендә үсүчеләр дә бар иде. Алар мәйданда төрле уеннарда катнашты. Балаларга район иганәчеләре ярдәме белән әзерләнгән бүләкләр тапшырылды.

## Әлмәттә Корбан бәйрәме алдыннан балалар арасында Коръән укучылар бәйгесе узды

Әлмәт мөхтәсибәтендә 14 яшькә кадәрге балалар һәм яшүсмерләр арасында Коръән укучыларның район бәйгесе узды. Чарада Әлмәт шәһәреннән һәм Әлмәт районыннан 70 ир бала һәм кыз бала катнашты. Иң яхшы укучыларны ике номинациядә сайлап алдылар, ә «Өч җүз» номинациясендә җиңүче ир балага бәрәнгә сертификат бүләк иттеләр.

## Мөфти Яшел Үзәндә 5 нче төзәтү колониясендә җәза үтүчеләр белән очрашты

Зөлхиҗҗә аеның 7 нче көнендә (3 июньдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе Илдар хәзрәт Баязитов, Яшел Үзән районы мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллин белән Яшел Үзән

районы Түбән Вязовые бистәсендә урнашкан 5 нче төзәтү колониясендә булды, Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе урынбасары эчке хезмәт полковнигы Илназ Фәхриев һәм колония башлыгы — эчке хезмәт подполковнигы Рөстәм Сәләхиев белән очрашты. Җитәкчеләр төзәтү колониясендә Корбан бәйрәмен үткәрүгә кагылышлы оештыру мәсьәләләре турында фикер алышты.

Аннан Камил хәзрәт колониянең «Әл-Фатихә» мәчетендә иректән мәхрүм ителгәннәр белән аралашты. Биредә даими рәвештә Ислам нигезләре буенча дәресләр, рухи әңгәмәләр, вәгазь кичәләре үткәрелә һәм хәтта Коръән уку бәйгеләре оештырыла. Җомга намазына 200 ләп мөселман йөри. Рамазан аенда мәчеткә килүчеләр саны 250 гә җитә, чөнки аларның күбесе изге айда ураза тоталар.

## Мөхтәсибәтләр Корбан гаете уңаеннан бәйрәм чаралары оештырды

Корбан бәйрәме уңаеннан Татарстан Республикасы авылларында һәм шәһәрләрдә шәһәркүләм балалар һәм гаилә бәйрәмнәре үтте. Нәзарәт мөхтәсибәтләре аларны мәчет янәшәсендә генә түгел, паркларда, скверларда һәм стадионнарда үткәрде. Балалар һәм өлкәннәр өчен биредә спорт чаралары, уеннар, конкурслар, мастер-класслар әзерләнде, аттракционнар, батутлар, хәләл ярминкәләр эшләде, балаларның чыгышлары һәм мөнәҗәтләр яңгырады.

Мисал өчен, Казанда «Корбан Фест» 10 мең кешене җыйса, Яр Чаллыда гаилә бәйрәме «Нур-Ихлас» һәм «Тәүбә» мәчетләрендә 3 меңнән артык кеше катнашында үтте. Лаеш мөхтәсибәтендә дә Корбан бәйрәменә иҗади яктан бик якын килделәр: Корбан бәйрәменең матурлыгын күрсәтү һәм халыкны Исламга тарту өчен, биредә мәчетләргә экскурсияләр оештырдылар, пылау белән сыйладылар, балалар арасында рәсем бәйгесе үткәрделәр, батутлар һәм аттракционнар куйдылар. Нәзарәтнең Алабуга, Зәй, Арча, Питрәч, Әтнә, Тукай, Теләче, Биектау, Балык бистәсе, Әлки, Менделеевск, Лениногорск, Буа һ.б. мөхтәсибәтләрендә бәйрәмнәр үтте.

## Кукмарада реставрациядән соң тарихи Мәчкәрә мәчете ачылды һәм Рәис катнашында Корбан гаете үтте

Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә (6 июньдә) бөтен дөнья мөселманнары бөек бәйрәм — Корбан гаетен билгеләп үтте. Бу уңайдан Татарстан Республикасының барлык мәчетләрендә иртәдән үк бәйрәм чаралары башланды. Җөмһүриятебездә төп бәйрәм тантанасы Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Кукмара районының Мәчкәрә авылында реставрацияләнгән тарихи беренче Җәмигъ мәчетендә узды. Гаеткә килгән мөселманнар, бәйрәм вәгазен тыңлап, Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә намаз укыды. Камил хәзрәт вәгазен Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең саубуллашу вәгазенә багышлады. Тарихи мәчеттән бәйрәм чараларын «ТНВ Татарстан» һәм «ТНВ Планета» телеканалы аша турыдан-туры эфирда карарга мөмкин булды.

1791–1793 елларда төзелгән беренче тарихи Җәмигъ мәчете — Мәчкәрә мәчете — Гает көнендә комплекслы реставрациядән соң тантаналы рәвештә ачылды. Бу мәчет төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты һәм Татарстанда иң борынгы кирпеч авыл мәчетләренең берсе булып тора. Ул классицизм элементлары булган Петербург бароккосы стиле белән аерылып тора. Мәчет XVIII гасыр ахырында беренче гильдия сәүдәгәре Габдулла Габделсәләм улы Үтәмешев тарафыннан төзелгән.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Корбан бәйрәме хөрмәтенә 500 аз керемле гаиләне корбан ите белән тәэмин итте

Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Татарстанда Корбан бәйрәме көннәрендә, гадәттәгечә, мохтаҗлар өчен бик күп хәйрия башлангычларын тормышка ашырды. Аларга, дине һәм милләтенә карамастан, ярдәм күрсәтелде. Әлеге ярдәмне аз керемлеләр һәм күпбалалы гаиләләр, авырулар, балаларын ялгызы тәрбияләүче әниләр, өлкән яшьтәгеләр һәм социаль яктан якланмаган башка кешеләр алды. Бәйрәм тантаналары чорында 221 баш терлек корбанга китерелде: бу 4 тоннага якын корбан ите дигән сүз.

Быел «Зәкят» хәйрия фонды атна дәвамында 500 аз керемле гаиләгә 1,5 тонна корбан ите таратты. Шулай 300 кг ит Татарстандагы 6 социаль учреждениегә җибәрелде. Калган ит, Фондның социаль проектларына тоту өчен, туңдырып куелды. Моннан тыш, «Зәкят» хәйрия фонды Корбан бәйрәме хөрмәтенә аз керемле, күпбалалы, тулы булмаган 10 гаиләдә тәрбияләнүче укучыларга 400 000 сумга ноутбуклар бүләк итте. Корбан бәйрәме көннәрендә шулай ук авыру һәм мохтаҗ 12 кешегә акча җыелды.

## Татарстанда Корбан бәйрәме ничек үтте?

2025 елда республикада Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре күзәтчелегендә корбан чалу гамәлен башкару өчен 35 махсус мәйданчык, шул исәптән Казанда 17 мәйданчык оештырылды. Корбан чалу урыннарында барлык корбанлыклар санитария тикшерүен һәм ветеринария күзәтчелеген үтте. Корбан бәйрәме көннәрендә биологик калдыклар эшкәртелеп урнаштырылды.

Татарстан Республикасында махсус оештырылган 35 урында, Казанны да кертеп, барлыгы 11 507 баш мал чалынды, шуның 58 е — эре мөгезле терлек. Казанның үзендә 17 корбан чалу урынында 5 800 баш хайван чалынды.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре арасында беренчелек Авиатөзелеш һәм Яңа Савин мөхтәсибәтендә: биредә 2623 баш сарык корбанга чалынды. Аннан соң Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәте (1825), Яр Чаллы мөхтәсибәте (1234) һәм Әлмәт (800) мөхтәсибәтләре килә. Казанда иң күп мал чалган урыннар булып «Казан нуры» (2253), «Мәрҗани» (370) һәм «Гадел» (360) мәчетләре, шулай ук башкаланың Бертуган Петряевлар урамы, 6 адресы буенча урнашкан «Корбан-бәйрәм» комплексы (500) тора. 2025 елда Татарстан районнарында һәм Казанда махсус корбан чалу урыннарында, Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан чалынган корбаннарны да исәпкә алып, барлыгы 11728 баш мал корбан кылынды.

## Бөгелмәдә Татарстан мәчетләре командалары арасында мини-футбол буенча республика турниры узды

Зөлхиҗҗә аеның 18 нче көнендә (14 июньдә) Бөгелмә шәһәрендә Татарстан Республикасы мәчетләре командалары арасында мини-футбол буенча республика турниры узды. Чара Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына һәм Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Каһарманнар елына багышланды.

## Саба мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Зөлхиҗҗә аеның 18 нче көнендә (14 июньдә) Саба мөхтәсибәтенең Урта Нырты авылында яңа мәчет ачылды. Мәчет район халкы һәм иганәчеләр тырышлыгы белән төзелгән. Анда 50 кеше сыйдырышлы ир-атлар намаз залы, тәһарәт бүлмәләре урнашкан; мәчет инженерлык челтәрләренә: электр энергиясе һәм җылыту системаларына тоташтырылган.

Мәчетнең имамы булып Кукмара мәдрәсәсен тәмамлаган Элмир хәзрәт Арикиев билгеләнде. Хәзерге вакытта Саба мөхтәсибәтендә 61 мәчет эшли.

## КИУның Коръән хафизлар әзерләү үзәге шәкертләре «Төхфәтел-әтфәл» һәм «Мөкаддимә әл-Җәзария»гә иҗазәтләр алды

Зөлхиҗҗә аеның 21 нче көнендә (17 июньдә) Казан ислам университетының Коръән хафизлар әзерләү үзәгендә иҗазәтләр тапшыру тантанасы узды. Бу иҗазәтләр «Төхфәтел-әтфәл» һәм «Мөкаддимә әл-Җәзария» буенча белем бирү мөмкинлеге бирә. Тәҗвид буенча шигъри формада язылган әлеге классик хезмәтләр бар Ислам дөньясында хафизлар тарафыннан яттан өйрәнелә. 22 шәкерткә — «Төхфәтел-әтфәл» буенча, 10 шәкерткә «Мөкаддимә әл-Җәзария» буенча иҗазәтләр тапшырылды. Мондый иҗазәтләр биредә 2010 елдан тапшырыла.

## Мөфти «Камил» мәчетендә Мөселман аксакаллары шурасы Генераль секретаре белән очрашты

Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның «Камил» мәчетендә Мөселман аксакаллары шурасы Генераль секретаре судья Мөхәммәт Габделсәлам белән очрашты. Ул Казанга Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашу өчен килде.

Очрашуда шулай ук кулъязма Коръәнне әзерләү комиссиясе әгъзасы шәех Мәэмүн әр-Рави, БИАның визит-профессоры Сәйф әл-Әсри, Мөфтинең Ислам финанслары буенча киңәшчесе Рөстәм хәзрәт Нургалиев, ТР Рәисе ярдәмчесе Марат Гатин, «Туган авылым» сәүдә-күңел ачу комплексы җитәкчеләренең берсе Радик Абдрахманов һәм башкалар катнашты.

Алар кунакка татар-мөселман мәдәнияте һәм татар өммәтенең тарихи һәм хәзерге казанышлары турында сөйләделәр. Мәсәлән, Камил хәзрәт аңа — «Казан басмасы»ның репринт басмасын, ә Радик Абдрахманов дүрт телдә чыгарылган «Туган батыр» әкият китабын тәкъдим итте.

## Татарстан хаҗиларының барысы да туган илгә исән-имин кайтып җитте

Зөлхиҗҗә аеның 27 нче көнендә (23 июнендә) Казанга Татарстан хаҗиларының Казандагы «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Түбән Кама шәһәренең Җәмигъ мәчетенең икенче имамы Булат Баһаветдинов җитәкчелегендә 100 кешедән торган соңгы төркеме (2 төркем) кайтты. Алар Татарстандагы «ДУМ РТ Хадж» рәсми хаҗ операторы аша «Стандарт» программасы буенча хаҗ кылды.

2025 елда «ДУМ РТ Хадж» рәсми операторы аша Татарстаннан 1800 кеше хаҗ кылды. Хаҗ вакытында аларны шәригать хокукын һәм гарәп телен белгән тәҗрибәле җитәкчеләр һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан беркетелгән 20 табиб озатып йөрде.

## Мөфти Мамадыш районында 17 нче колония-поселениедә җәза үтүчеләр янында булды

Мөхәррам аеның 7 нче көнендә (2 июльдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мамадыш районы Дегетле авылында урнашкан 17 нче колония-поселениедә булды. Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе урынбасары эчке хезмәт полковнигы Элдар Аллахвердиев һәм колония башлыгы — эчке хезмәт полковнигы Раил Сәгыйтов — белән очрашты.

17 нче колония-поселениегә сәфәре барышында Татарстан Мөфтие колония мәчетендә иректән мәхрүм ителгәннәр белән аралашты. Мәчет Ислам динен тотучыларның барысын да сыйдыра: монда аларның саны 35 ләп исәпләнә. Биредә Ураза гаете һәм Корбан гаете уздырыла, җомгалар укыла, даими рәвештә Ислам нигезләре буенча дәресләр, рухи әңгәмәләр үткәрелә.

## Әлмәт һәм Алабуга мөхтәсибәтләрендә махсус хәрби операциядә якыннарын югалткан гаиләләр өчен Корбан ашлары узды

Әлмәт һәм Алабуга Җәмигъ мәчетләрендә махсус хәрби операциядә якыннарын югалткан гаиләләр белән очрашулар — Корбан ашлары — узды. Анда тол хатыннар, сугышчыларның әти-әниләре һәм балалары катнашты. Күркәм гадәт буенча, мәҗлесләрдә Коръән аятьләре укылды, вәгазь сөйләнеп, үгет-нәсыйхәтләр җиткерелде. Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм һәлак булучылар өчен догалар кылынды.

## Татарстан мөселманнарыннан махсус хәрби операция зонасына чираттагы гуманитар йөк тапшырылды

Изге мөхәррам аенда Татарстан мөфтияте делегациясе махсус хәрби операция зонасында Луганск юнәлешендә алгы сызыкта хезмәт итүче солдатларга чираттагы гуманитар ярдәм тапшырып кайтты. Шулай ук Дебальцево госпиталенә дарулар, медицина кирәк-яраклары бирелде. Моннан тыш, Татарстанның көньяк-

көнчыгыш төбәге казые, Ютазы районы имам-мөхтәсибе Марат хәзрәт Мәрданшин Татарстан солдатлары хезмәт итүче «Алга» һәм «Батыр» батальоннарында булды, әлеге батальоннарның имамнары һәм хәрбиләре белән очрашулар үткәрде. Шулай ук 90 нчы танк батальонында булып, командирларга һәм солдатларга Татарстан Мөфтие исеменнән рәхмәт хатлары тапшырды.

Республика мөселманнарыннан җыелган гуманитар ярдәмнең гомуми авырлыгы 2 тоннадан артып китте. Бу юлы махсус хәрби операция зонасына 8 күчереп йөртелә торган электр станциясе һәм аларны эшләтү өчен кояш панеле, 4 планшет, дизель генераторы, бензин белән эшләүче пычкылар, фонарьлар, рацияләр һәм аларга батарейкалар; коры ризык, томалап пешерелгән хәләл сыер ите (тушенка), чәкчәк; термослар, маскировка челтәрләре; дарулар һәм стерильле бинтлар, аптечкалар, авыртуны басучы препаратлар; кесәгә сыешлы 700 дога китабы җибәрелде.

Гуманитар йөкне әзерләүдә Татарстанның көньяк-көнчыгыш казыяте — Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай һәм Ютазы районнары мөселманнары актив катнашты. Шулай ук Саба, Кукмара һәм Буа районнарында яшәүчеләр, Марат хәзрәт җитәкчелегендә изге җирләрдә булган хаҗилар төркеме дә кушылды. «Алтын групп» һәм «АртСтрой» төзелеш компанияләре зур өлеш кертте — алар сәфәр өчен машина һәм ягулык-майлау материаллары бирде.

## Дин әһелләре һәм татар җәмәгатьчелеге Вәлиулла хәзрәт Якуповны искә алды

Мөхәррам аеның 23 нче көнендә (18 июльдә) Казанда танылган татар дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Апанай мәчете имам-хатыйбы Вәлиулла хәзрәт Якуповны (1963–2012) искә алу чаралары узды. Быел 19 июльдә аның фаҗигале төстә арабыздан китүенә 13 ел тулды.

Иртәдән бер төркем дин әһелләре, Вәлиулла хәзрәтнең якын дуслары һәм фикердәшләре Казан шәһәре Самосырово бистәсендә урнашкан мөселман зиратында Вәлиулла хәзрәтнең кабере янына җыелды, Коръән укып, аның рухына дога кылды. Аннан соң искә алу чаралары «Апанай» мәчете каршындагы курслар

уза торган бинада «Россиядә совет чорында Ислам: фидакарь шәхесләр» темасына түгәрәк өстәл утырышы белән дәвам итте.

## Азнакайда Россиякүләм VIII «Әсләм» ачык Коръән укучылар бәйгесе узды

Мөхәррам аеның 24 нче көнендә (19 июльдә) Азнакай мөхтәсибәтендә ир-атлар арасында Коръәнне яттан белү буенча Россиякүләм VIII ачык бәйге үтте.

Конкурста Россиянең төрле төбәкләреннән һәм Татарстаннан 70 тән артык кеше катнашты. Аларга шәех Мәэмүн әр-Рави (ул Коръән хифзы буенча 10 кыйраәт белгече, Фарсы култыгы илләрендә Коръән буенча бәйгеләрдә баш хөкемдар һәм жюри рәисе, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел дәвамчысы, Изге Коръән Дубай халыкара премиясе (DIHQA) Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы, Казанда кульязма Коръән әзерләү буенча комиссия әгъзасы) җитәкчелегендәге мәртәбәле жюри бәя бирде.

Ачык бәйгедә җиңүче булып Казаннан Әхмәд Шәһмәмәдов танылды, ул «Коръәнне тулысы белән яттан белү (хифз)» номинациясендә беренче урынны яулады. Аңа гомрәгә юллама бүләк иттеләр.

## Әлки мөхтәсибәтендә Иске Үргәагар авылы мәчетенең 120 еллыгын билгеләп үттеләр

Сафәр аеның 1 нче көнендә (26 июльдә) Әлки районының Иске Үргәагар авылы мәчетенең 120 еллыгына багышланган тантаналы чара узды. Бу мәчетнең тарихы шунысы белән игътибарга лаек: аның ишекләре совет чорында да дин тотучылар өчен ачык булган.

Тантанада Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты: Коръән укып, үгет-нәсыйхәтләрен бирде, мөселманнар тормышында мәчетләрнең мөһимлеген ассызыклады. Авыл халкына тирән рәхмәтен белдереп, танылган шәхесләргә, шул исәптән мәчетне саклап калучыларга рәхмәт хатлары тапшырды.

Кунаклар һәм мәхәллә кешеләре юбилей тантанасыннан соң, мәчеткә кереп, Камил хәзрәт җитәкчелегендә өйлә намазын укыды.

## Болгарда XX Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узды

20–27 июль көннәрендә Шәһре Болгарда XX Бөтенроссия мөселман яшьләре форумы узды. Җыен Диния нәзарәте тарафыннан Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды белән берлектә Болгар ислам академиясе теләктәшлегендә уздырылды. Быел Форумда Россиянең 18 төбәгеннән 130 кеше катнашты.

Файдалы һәм кызыклы программа кысаларында фикерле яшьләр социаль проектлау күнекмәләрен үзләштерде һәм социаль стартапларны оештырырга өйрәнде: алар идея рәвешендә яки грант алырлык әзер проект булырга мөмкин. Яшь мөселманнар мастер-класслар, шәхси үсеш буенча тренинглар, өйрәтүче чараларда катнашты. Белем бирү һәм өйрәтү чараларыннан тыш, Форум программасы тарих белән таныштыруны, шулай ук танылган дин әһелләреннән лекцияләр, төрле интеллектуаль, мәдәни һәм спорт чараларын үз эченә алды.

Форумда иң яхшы социаль проект идеяләре сайлап алынды һәм грантлар белән бүләкләнде. Иң перспективалы стартапларның 17 авторы үз башлангычларын уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен финанс, мәгълүмати һәм консультацион ярдәм алды. Форумда проектларны яклау тәмамланганнан соң, катнашучыларга 30 меңнән 100 мең сумга кадәр грант сертификатлары тапшырылды.

## Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин рәислегендә республикада мәчетләр төзүнең концептуаль мәсьәләләре буенча эшлекле киңәшмә узды

Сафәр аеның 5 нче көнендә (30 июльдә) Казан шәһәренең Галиев мәчетендә Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин рәислегендә республикада мәчетләр төзүнең концептуаль мәсьәләләре буенча эшлекле киңәшмә узды. Аерым алганда, Аллаһы йортлары архитектурасында татар милли үзенчәлекләрен саклау турында сөйләштеләр. Җыелыш башында Мөфти хәзрәт хәзерге татар мәчетләренең

тышкы яктан милли төсмере аз булуын һәм, гомумән, татар мәчетләренә хас үзенчәлекләрне киң һәм һөнәри җәмәгатьчелектә аңлау юклыгын билгеләп үтте. 1100 елдан артык Ислам динен тоткан татар халкының дини корылмалар төзүнең уникаль мәдәниятен торгызырга һәм сакларга кирәк. Камил хәзрәт республикадагы мәчетләрнең үз йөзе булырга һәм, проектлаган вакытта, теләсә нинди архитектура формаларын: хай-тек, классицизм һ.б. тормышка ашырганда, татар милли үзенчәлекләре сакланырга тиешлеген ассызыклап үтте. Билгеләнгән мәсьәләләр буенча Нигезләмә эшләргә кушты.

Киңәшмә барышында әйтелгән фикерләр Диния нәзарәтенең Татарстан Республикасында мәчетләр төзү турында Нигезләмәсен эшләгәндә файдаланылачак, шулай ук гамәлдәге «Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте имамхатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә» дигән документка кертеләчәк.

## Алабугада җәядән ук ату буенча «Туган Батыр» IV Бөтенроссия турниры узды

Сафәр аеның 8 нче көнендә (2 августта) Алабугада җәядән ук ату буенча «Туган Батыр» IV Бөтенроссия турниры узды. Ярышлар тарихи урында — федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты булган Алабуга шәһәрчегендә — оештырылды. Быел турнир Татарстан Республикасы Рәисенең гражданлык җәмгыятен үстерү буенча гранты ярдәмендә үткәрелде. Анда Татарстаннан, Башкортстаннан, Әстерхан, Омск һәм Кемерово өлкәләреннән 100 дән артык укчы катнашты.

Рәсми ачылыштан соң хәзрәтләр, аксакаллар, турнирда катнашучылар, кунаклар һәм алабугалылар әлеге тарихи җирлектә борынгы Ак мәчет урынында Камил хәзрәт җитәкчелегендә җәмәгать белән өйлә намазын укыды һәм Бөек Ватан сугышында, махсус хәрби операциядә һәлак булучылар рухына багышлап, шулай ук туган җиребезнең иминлеге өчен дога кылды. Турнир башланырга берничә көн кала, Алабуга шәһәренең барлык мәчетләрендә Ислам динендә иң олуг гыйбадәтләрнең берсе булган Коръән хатем кылу башланды.

Коръән хатеме 2 нче августта Татарстан Мөфтие катнашында дога кылу белән тәмамланды.

## «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗ гаиләләрдәге ир һәм кыз балалар өчен рухи-мәгърифәтчелек курслары оештырды

«Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗ гаиләләрдәге ир һәм кыз балалар өчен рухи-мәгърифәтчелек курслары оештырды. Күпбалалы, аз керемле һәм тулы булмаган гаиләләрдән 30 ир бала «Хәйдәр» өлгергәнлек үзәгенең алты көнлек палаткалы сменасында булып кайтты. Смена Югары Ослан районының Ташевка авылы янындагы территориядә әзерлекле педагоглар һәм тәҗрибәле остазлар командасы җитәкчелегендә узды. Бу вакытта 14 кыз өчен курслар, фонд базасында оештырылып, 12 нче августка кадәр дәвам итте.

## Әгерҗе мөхтәсибәтендә Саклау җыены үтте

Сафәр аеның 15 нче көнендә (9 август) Әгерҗе районы Саклау авылында мөселманнар җыены үтте. Ул дәүләт саклавына алынган, тарих-архитектура истәлеге, районда хәзергәчә сакланып калган бердәндер таш мәчет — Саклау мәчете — янында үткәрелде. Быелгы җыен программасының төп өлеше танылган хәзрәтләрнең вәгазьләрен тыңлау, мөнәҗәтләр башкару, Саклау авылының тарихи мәчетендә өйлә намазы уку һәм дога кылу, җәмәгать белән Коръән ашында катнашудан торды.

## Татарстан мөселманнары Лисичанск һәм Рубежное балаларына якынча 1 млн сумлык гуманитар ярдәм тапшырды

Сафәр аеның 17 нче көнендә (11 август) Диния нәзарәте Луганск Халык Республикасының Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендәге мохтаҗ гаиләләрдәге балаларга гуманитар ярдәм тапшырды. Якынча 900 000 сумлык, гомуми авырлыгы 700 кг булган гуманитар йөк «Бердәм Россия» партиясенең Татарстан

Республикасындагы вәкилләренә Луганск Халык Республикасына илтү һәм Лисичанск шәһәре хакимияте тарафыннан мохтаҗлар арасында бүлү өчен тапшырылды.

Гуманитар ярдәм җыюда Диния нәзарәтенең барлык мөхтәсибәтләреннән мөселманнар катнашты. Диния нәзарәтенең гуманитар йөге 210 балага исәпләнгән. Аларга гигиена кирәк-яраклары, балалар әйберләре: пеленкалар, памперслар, кремнар, дымлы тастымаллар, кер юу порошоклары, манежлар, караватлар, коляскалар, кием-салым, урын-җир, шулай ук балалар ризыклары (боткалар, сөт продуктлары, боламыклар, соклар, катнашмалар) һәм башкалар тапшырылды.

## Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә «Бал бәйрәме» узды

Сафәр аеның 18 нче көнендә (12 август) Казанда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә ел саен уздырыла торган «Бал бәйрәме» булды. Мәртәбәле кунаклар җаен шәкертләрне умартачы һөнәренә өйрәтү барышы белән таныштылар. Мондый гамәл мәдрәсәдә шәкертләрне умарта үрчетергә һәм умартачылык продуктлары алырга өйрәтергә мөмкинлек бирә. Бу киләчәктә яшь имамнарга өстәмә керем китерерлек күнекмә дә булып тора.

## Чүпрәле мөхтәсибәтендә «Мунчәли укулары» узды

Сафәр аеның 22 нче көнендә (16 августта) Чүпрәле мөхтәсибәтендә XVIII «Мунчәли укулары» фәнни-гамәли конференция үтте. Әлеге чара Россиядә һәм Татарстанда игълан ителгән Ватанны саклаучылар елы, Татарстан мөфтияте тарафыннан игълан ителгән Каһарманнар елы уңаеннан оештырылды һәм һиҗри исәп буенча агымдагы 1447 елда билгеләп үтеләчәк Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгына багышланды.

## Казанда татар абыстайлары-остазлары форумы узды

Сафәр аеның 26 нчы көнендә (20 августта) Казанның Мәрҗани мәчетендә III татар абыстайлары-остазлары форумы узды. Ул һиҗри буенча 1447 елда Аллаһы Илчесе

салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгына багышланды. Форумны Мөфтиятнең хатын-кызлар белән эшләү бүлеге һәм Татарстан Мөслимәләр берлеге оештырды.

«Бүген мөслимә: рухият, гаилә кыйммәтләре, ватанпәрвәрлек» чарасына Татарстан Диния нәзарәтенең барлык мөхтәсибәтләреннән мөслимәләр берлекләре җитәкчеләре, Казан мәчетләре баш абыстайлары, Мордовия, Ульяновск һәм Мари Ил төбәкләреннән актив мөслимәләр — 100 гә якын кеше җыелды.

Рәсми чыгышлардан соң форум дискуссия мәйданчыклары һәм мастер-класслар эше белән дәвам итте. Панель дискуссияләр «Мөслимә тормышында рухилык», «Мөселман мәдәниятендә гаилә кыйммәтләре», «Ватанпәрвәрлек һәм мөселманлык» темалары буенча эшләде. Форум барышында шулай ук мөслимәләр җәмгыятьтә очраша торган көнүзәк мәсьәләләр турында да фикер алыштылар. Форум нәтиҗәләре буенча резолюция кабул ителде.

## Кукмара районында быел беренче Мәүлид һәм «Мәчкәрә укулары» узды

Рабигыль-әүвәл аеның 1 нче көнендә (24 августта) Кукмара мөхтәсибәтендә «Мәчкәрә укулары» төбәкара фәнни-гамәли конференция үтте. Ул Татарстанда Мәүлид ае кысаларында уза торган чараларны башлап җибәрде. Чарага Татарстан казыйлары, аксакаллары, имам-мөхтәсибләре, дин әһелләре һәм җәмәгать эшлеклеләре, шулай ук җирле мөселманнар — 300 дән артык кеше җыелды. Мәртәбәле кунаклар һәм конференциядә катнашучылар арасында җитәкчеләр, тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр, педагоглар, махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның гаилә әгъзалары бар иде.

IX Мәчкәрә укуларында «Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рухи мирасы — бәхеткә юл» дигән тема буенча фикер алыштылар. Конференциядән соң Мәчкәрә авылындагы тарихи Беренче Җәмигъ мәчетендә Мәүлид ән-Нәби уздырылды: хәзрәтләр вәгазьләр сөйләде, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә атап нәшидләр әйтелде. Аннан, өйлә намазы укылып, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм Ватан иминлеге өчен дога кылынды.

## Кукмара мөхтәсибәтендә яңа мәчет ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 1 нче көнендә (24 августта) Кукмара районының Балыклы авылында яңа «Ихлас» мәчете ачылды. Ул 1994 елдан бирле эшләгән иске мәчет урынында төзелгән. 150–200 кеше сыйдырышлы яңа мәчет төзелешенә «Урал» оешмасы җитәкчесе Газинур Хәбибрахманов зур өлеш керткән.

Мәчетнең беренче катында ир-атлар өчен 200 кеше сыйдырышлы иркен намаз залы, имам бүлмәсе урнашкан. Аскы катта мәчет каршындагы курслар өчен уку сыйныфлары, хезмәткәрләр өчен бүлмә, ашханә урнашкан. Мәчет электр белән яктырту һәм җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтырылган. Уңайлы тәһарәтханәсе бар. Мәчетнең имам-хатыйбы булып Кукмара мәдрәсәсен тәмамлаган Фәиз хәзрәт Минһаҗев эшли.

## Казанда Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгына багышланган шәһәркүләм Мәүлид узды

Рабигыль-әүвәл аеның 6 нчы көнендә (29 августта) Казанда Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең туган көненә багышланган шәһәркүләм Мәүлид бәйрәме узды. Быел тантана бөек юбилей — һиҗри буенча Аллаһы Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгы — белән истәлекле. Шуңа күрә Диния нәзарәте беренче тапкыр республика җитәкчелеге, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» Префектурасы ярдәмендә аны аеруча зур итеп һәм Республика көне чаралары кысаларында оештырды. Мәүлид бәйрәмен хөрмәтләп Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов килде.

Мәүлидтә катнашучылар өчен иң көтеп алынган мизгел булып хаҗга һәм гомрәгә юлламалар уйнату булды. Бәйрәмдә олы һәм кече хаҗга юлламалар алу өчен барлыгы җиде сертификат тапшырылды. Бүләк уйнатуда Мәүлидкә килгән 4 мең мөселман катнашты — бәйрәмгә шуның кадәр билет өләшкәннәр иде.

Мәүлидне оештыручылар төрле яшьтәгеләр өчен бай дини-мәгърифәтчелек программасы әзерләде. Фестивальнең махсус кунаклары буларак Россиядә иң танылган нәшид башкаручы «Нәшидүл Ислам» төркеме җырчылары чыгыш яса-

ды. Шулай ук бәйрәм сәхнәсендә Мәүлид турында театральләштерелгән тамаша күрсәтелде, халык яраткан хәзрәтләр вәгазьләр сөйләде, ә танылган татар артистлары һәм коллективлар дини кануннар кысаларында чыгыш ясады. Балалар өчен викториналар узды: аларга бүләкләр бирелде.

Шулай ук Мәүлид мәйданчыкларында Halal Market ярминкәсе эшләде. Моннан тыш, Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды аз керемле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнүче 200 укучыга портфельләр тапшырды. Бу акция быел унынчы тапкыр узды.

## Яр Чаллыда яңа «Изге ай» мәчете ачылды

30 августта, Татарстан Республикасы көнендә, Яр Чаллы шәһәренең 71 нче комплексында «Изге ай» мәчетен ачу тантанасы булды. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев истәлекле вакыйгада катнашучыларны Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләде. Ул мәчетләрнең мөселманнар тормышындагы мөһимлеге һәм аларның фазыйләтләре турында вәгазь сөйләде, мәчет төзелешендә катнашучыларга рәхмәт белдерде.

Мөхтәрәм кунаклар һәм мәхәллә халкы өйлә намазы алдыннан «Изге ай» мәчетенә кереп намаз укыды. Яр Чаллыдагы «Изге ай» мәчете Зөфәр Мисбах улы Насретдинов җитәкчелегендә төзелгән. Хәзер шәһәрдә 16 мәчет эшли.

## Белем көне алдыннан Казанда «Әтиләр» мәчете каршында Мәгърифәтчелек үзәге ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 8 нче көнендә (31 август), Белем көне алдыннан, Казанның Кояшлы бистәсендә «Әтиләр» мәчете каршында Мәгърифәтчелек үзәге ачылды. Хәзер бистәдә белем бирү, Исламны өйрәнү, шулай ук җәмәгать белән дини йолалар үткәрү өчен уңайлы урын барлыкка килде. Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, тантанада катнашып, мөселманнар өчен белем алуның әһәмияте, үзәк төзелешендә катнашучыларга бирелә торган әҗер-саваплар турында сөйләп үтте. Бу эштә катнашучыларга тирән рәхмәтен белдерде.

Моңарчы мәчет каршындагы курслар «Әтиләр» мәчетендә үткәрелгән иде, яңа уку елыннан алар Мәгърифәтчелек үзәгенә күчерелде. Яңа үзәктә берьюлы 51 укучыга белем алырга мөмкинлек бар.

Ике катлы һәм мансардалы 600 $м^2$ мәйданлы таш бинада 3 уку сыйныфы, мөгаллимнәр өчен 2 кабинет, 5 ярдәмче бүлмә һәм актлар залы урнашкан. Актлар залын ифтарлар үткәрү өчен дә файдаланырга мөмкин. Шулай ук ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым тәһарәтханәләр, мөгаллимнәр бүлмәсе, кухня, кер юу бүлмәсе бар, бинага керү юлында махсус җайланма (пандус) урнаштырылган.

## Болгарда Мәүлид ән-Нәби үтте

Рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көнендә (4 сентябрьдә) — Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәкъ туган көнендә — Болгарның Ак мәчетендә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең туган көненә багышланган Мәүлид ән-Нәби үтте. Ак мәчеттәге тантанага имам-мөхтәсибләр, аксакаллар, остазлар һәм шәкертләр, махсус хәрби операция ветераннары җыелды.

Мәүлид ән-Нәби бәйрәменең күркәм бизәге булып татар мәкаме белән мәшһүр «Мәүлид» касыйдәсен башкару торды. Аны Татарстанның атказанган артисты Марсель Вәгыйзов җитәкчелегендә иҗат төркеме башкарды.

Мәүлид барышында махсус хәрби операция ветераны Илгизәр Миңнуллин Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатлар өчен махсус хәрби операция зонасына гуманитар йөкләр илткән өчен Мөфти Камил хәзрәткә һәм Нәзарәткә рәхмәт белдерде. Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Мәүлид уңаеннан махсус хәрби операция ветераннарына күчтәнәчләр — азык-төлек җыелмалары — тапшырды.

Мәүлид тәмамланганнан соң, Татарстан Мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов рәислегендә республикада мәчетләр төзегәндә татар милли үзенчәлекләрен саклау мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл узды. Анда катнашучылар Татарстанда мәчетләр төзү концепциясе, намаз уку бүлмәләренең һәм йортларының эшчәнлеге буенча фикер алышты.